ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№9 (321) – СЕНТЯБРЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Үзеңнеке читкә әйләнгәч

Уңыш кәрҗине

Замандашлары Исхакыйны ничек хәтерли

— ИДАРӘ ИТӘР ӨЧЕН, МӘГЪЛҮМАТЛЫ БУЛЫРГА КИРӘК

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фаридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Галина Зәйнуллина, Катерина Котова,
Ксения Сёмина, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото: ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов
Фото: Рамил Гали

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1000 данә,
рус телендә: 2500 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-2513
Басарга кул куелды: 25.09.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры: Гүзәл Подольская

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

КҮЗЛӘРЕҢӘ СОКЛАНЫРГА РӨХСӘТ ИТ...

Алтын, җете, зирәк, тын, серле... бу сыйфатларның барысы да аңа туры килә. Көзгә. Ул тагын безнең белән. Күз явын алырдай сулып барган көннәре, тынлыкка тоташтырып, сизелер-сизелмәс кыштырдап, сабыр гына хушлашуы – барысы да шундый таныш... Әмма без беләбез: көзен үлгән бар матурлык язда кабат әйләнеп кайтачак. Шулай булган һәм булачак бу җирдә. Яңарасы булгач, нигә ел саен шулкадәр тантаналы итеп хушлаша соң ул безнең белән? Мөгаен, безне вакытның күз иярмәс тизлегеннән, заманның котылгысыз шаукымыннан курыкмаска өндәр өчендер. Югыйсә, без бит яшәргә дә өлгерми калабыз шикелле тоела. Бар да әйләнеп кайтачак, кабат яңарачак. Ничә кабат йокыга талса да, уяначак, янәсе. Шуңа да артык ашыкмаска, тукталып калып, тынлыкка хушланырга, матурлыкка сокланырга өлгерик. Җәйме, кышмы, язмы, һәр көне рәссам киндеренә ягылырга лаеклы көзебезме. Ә калганы – мәшәкать һәм ыгы-зыгы гына. Дөньяның артыннан куып тоткан беркем дә юк әле. Тоттырмый ул барыбер!

Тукталып тор – кара, соклан көзгә! Бер мизгелгә генә булса да!

СЕЗНЕҢ КӨЗДӘН ӘСИР РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **900 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Иван Кузнецов, «Долгая поляна». 1986 ел.

СЕНТЯБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Кире элемтә феномены.
Татарстан Президенты бюрократия белән көрәштә социаль челтәрләрнең роле турында

6. «Санта-Барбара» бер якта торсын,
яки Алимент түләмәүчеләрне ни көтә

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

14. Эссе җәйнең кайнар икмәге.
Уңыш өчен гадәттән тыш вазгыять режимында барган көрәш

20. Бәрәңге һәм зур сәясәт турында.
Президентлар белән аралашкан фермер хакында

22. Кыр уңганнары.
Уңыш ничек табыла

30. Уңыш кәрҗине.
Үзебездә үскән җиләк-җимеш һәм яшелчә

34. Редакция кухнясы.
Укытучылар нәрсә ярата

38. Еракка – империя чикләренә...
Ни өчен Чирмешән районы туристлар өчен чын хәзинәләр сандыгы

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

46. Өч айга сузылган бәхет.
Узган җәй хәтергәниләр белән кереп калды

54. Тарих битләрен актарганда.
«Бөек бола» һәм Туктамыш хан

58. Кече ватан патриотлары.
Гаяз Исхакыйны замандашлары ничек истә калдырган

62. Кинобум. Дәвамы бармы?
Казан мөселман киносы фестивале ниләр күрсәтте

66. Юбилей.
Данил Салихов: «Мин һәр язучы өчен җаваплы»

84. Татар авыллары.
Ак әбиләр авылы

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

05.09

Сергей Кириенко, РФ Президенты Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары, – мәдәниятара диалоглар буенча Казан форумы ачылышында:

– Мондый диалог Татарстан территориясендә инде йөзләрчә ел бара. Бу җирдә төрле тарихи вакыйгалар булып үткән, әмма менә берничә гасыр инде Татарстан Россия Федерациясендә генә түгел, гомумдөнья киңлегендә дә төрле халык һәм конфессия вәкилләренең тату яшәү үрнәге булып тора. Безнең планетаның аерым нокталарында мондый күршелек кайчагында конфликтлар һәм хәтта фаҗигале бәрелешләр сәбәбенә әверелсә, без Татарстанда һәм гомумән Россиядә бөтенләй башка мисал күрәбез. Бу – база кыйммәтләре, база мөнәсәбәтләре мәсьәләсе.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

03.09

Челестино Мильоре, архиепископ, Ватиканның Россиядәге апостоллар нунцие, Казанга килгән чагында:

– Күренеп тора, Казан – искиткеч шәһәр. Беренчедән, монда ЮНЕСКО карамагындагы объектлар бар, икенчедән, монда шулай ук табигать матурлыклары да, сәнгать әсәрләре дә күп. Мине ике нәрсә аеруча илһамландырды – Казан Мәрьям Анасы образын күрү, һәм шулай ук Татарстандагы бөтен диннәрнең татулык символын чагылдырган Барлык диннәр храмының булуы.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

10.09

Камил Сәмигуллин, Татарстан мөфтие, Россиядә беренче мөселман телеканалы «Хузур ТВ»ны тәкъдир иткәндә:

– Аллаһы Тәгалә юлына, аның диненә чакыручыдан һәм игелекле эшләр кылучыдан да яхшырак кеше була аламы?! Мондый юнәлештәге телевидениегә мөнәсәбәт бердәй генә түгел, ниндидер нюанслар булырга мөмкин, чөнки без һәммәбез дә төрле. Соң, әйдәгез, стереотипларга каршы бергәләп көрәшик, чөнки безнең һәркайсыбыз – вәгазьче.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстан Президенты **НИ ӨЧЕН** Инстаграмда бик актив

Алименттан качучыларга **КЕМ** көрәш ачкан

– КЕМ БЕЛӘНДЕР ИДАРӘ ИТӘР ӨЧЕН, МӘГЪЛҮМАТЛЫ БУЛЫРГА КИРӘК

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов – бүгенге көндә мәгълүматның роле, бюрократия белән көрәштә социаль челтәрләрнең файдасы һәм Инстаграмда үзенең активлыгы турында.

– Кем беләндер идарә итәр өчен, мәгълүматлы булырга кирәк. Мәгълүмат күп булган очракта, аны дөрес итеп эшкәртү, файдалану мөһим. Идарә системасы кире элемтә булмаганда эшләмәячәк. Элемтә өзелгәндә без урыннарга ниндидер директивалар, күрсәтмәләр юллыйбыз, тик дөрес эшлибезме-юкмы икәнлеген белмибез. Бер яктан караганда, әлбәттә, социаль челтәрләрдә тәнкыйтьләгәндә, үгет-нәсыйхәт биргәндә күңелле түгел. Әмма бу – гаять көчле кире элемтә. Безнең профессиональлегебез әлеге кире элемтәдән дөрес итеп файдалануда чагыла. Мин әлеге барлык мәгълүмат, күңелгә бик ошап бетмәсә дә, тулысынча каралырга тиеш дип саныйм.

«Халык контролендә» беренче яртыеллыкта гына да 30 меңнән артык мөрәҗәгать пәйда булды. Алар төрле юнәлешләргә карый – төзекләндерү, дәваханәләр, мәктәпләр, юллар. Һәм бу әйбәт –



Фото: Рамил Гали, «Татар-информ» МА.

аларның 70 процентка якынын без эшлибез. Арада инвестицияләр таләп итә торганнары да бар, аларын үзебезнең инвестицияле программаларыбызга кертәбез. Ни генә дисәк тә, **без әлеге сигналларны кабул итәбез, туплыйбыз һәм теге яисә бу проблеманың халыкның күпмедер өлеше өчен мөһим икәнлеген аңлыйбыз.**

Гомумән, **электрон хөкүмәт һәм электрон хезмәтләр күрсәтү системалары эшне күпкә җиңеләйтә, гадиләштерә, бюрократизмны киметә һәм кире элемтә булдыра.** Элек ничек иде бит – газеталарның безне мактаган чаклары, тәнкыйтьләгән чаклары бар иде. Бу – шулай ук кире элемтәнең бер формасы. Безне мактаучылар ниндидер эйфория тудыралар иде.

Бүген халык белән эшләү бөтенләй икенче. **Кешеләр үз фикерләрен белдерәләр, һәм бу «Халык контроле» генә түгел. Мин теркәлгән социаль челтәрләрдә мондый мөрәҗәгатьләр күп. Һәм мин әлеге сораулар өчен җавап бирүче коллегаларымнан һәрвакыт мөрәҗәгатьләрне теркәүләрен сорыйм.** Мәгълүматны алу гына түгел, аны исәпкә кую һәм процесска контрольлек итү дә мөһим. Мин мондый аралашудан баш тарткан коллегаларымны да беләм. **Ләкин без – җәмгыятьнең бер өлеше һәм, ошыймы-ошамыймы, без аннан аерым яши алмыйбыз.**

Ни өчен Инстаграмга фотоларны еш элэмме? Минем карашымча, бик матур һәм күркәм нәрсәләр һәм вакыйгалар бар. Минемчә, бу фотолар мине социаль челтәрләр аша күзәткән кешеләргә дә кызык була ала. Барысын да урнаштырып өлгерә алмыйм, булдыра алган җирдә эләм. Мәсәлән, мәктәп ачылышы, балалар бии. Бу начармыни? Мөмкинлегем булганда, фото яисә кечкенә генә берәр ролик элеп куям.

Мин бит үземнең әллә кемлегемне расларга яисә тагын шундый берәр нәрсә күрсәтергә теләмим. Безнең илдә башка беркайда да булмаган ничаклы урыннар бар, гаҗәеп вакыйгалар булып тора. Безнең Камчатка, Сахалин, Магадан, Байкал һ.б.лар бар. Анда да кешеләр нормаль яши. Алар чит ил инвесторларын көтмиләр, үзләре заводлар төзиләр. Мәсәлән, мин шаккаттым: Итуруп һәм Шикотян утрауларында менә дигән мәктәпләр, балалар бакчалары бар, юллар төзелә, эш урыннары ачыла. Мөгаен, бу аларга бик җиңел бирелмидер, әмма алар илебезнең чын патриотлары. Һәм мин россиялеләрнең, татарстанлыларның кайдадыр бик еракта, бездән 8 сәгать очарга кирәк булган якларда да, Россия кешеләренең бик матур итеп яшәүләрен күрүләрен телим. Араларында татарлар да күп.

Безнең илебез бик матур, һәм мин кешеләр игътибар итсен өчен әлеге матурлыкны күрсәтергә тырышам. Чит илләргә генә йөрмәсеннәр, Россиядәге күркәм урыннарга да барсыннар. ▪

Андрей Кузьмин белән «Галстуксыз әңгәмә». «Татарстан-24».

ҮЗЕҢНЕКЕ ЧИТКӘ ӘЙЛӘНГӘЧ...

20 мең татарстанлының үз балаларына 3 миллиард сумнан артыграк бурычы бар икән! Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов министрлык һәм идарәләрне алимент түләмәүчеләргә каршы сугыш игълан итәргә чакырды. Нәтиҗәдә Татарстанда махсус ведомствоара комиссия төзелде, суд приставлары исә үз линияләрен эшләтеп җибәрде. Вакыйгалар барышын безнең хәбәрчебез күзәтте.

Автор:
Катерина Котова

МАХСУС КОНТРОЛЬ

Алар яшьли өйләнешә. Ул чакта Регинага унтугыз яшь тула, булачак гаилә башлыгы исә – бер елга өлкәнрәк. Әмма бәхетле гаилә тормышы башланырга да өлгермичә тәмамлана. Ир аяк терәп эчә, аннары тузына. Регина берничә тапкыр китеп карый, әмма кабат кайта – кызы хакына гаиләне сакларга тырыша. Тик барысы да юкка булып чыга: ир кеше күп дигәндә бер атна түзә дә, тагын эчүгә сабыша. Аерылышалар, Регина шул чакта ук алиментка бирә. Ата кешенең бурычлары 2009 елдан бирле җыела һәм хәзер миллион (!) сумга якынлашкан.

Регина белән без алимент түләтүгә кагылышлы кабул итү барышында таныштык. Аны ТР хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова суд приставлары хезмәте һәм Казан район хакимиятләре вәкилләре белән берлектә үткәрде. Әлеге абруйлы комиссия вәкилләре җиде хатын-кызга, шул исәптән Регинага да, алимент түләтүне үзләренең шәхси контроленә алды.

– Аерылышкан ирем кызым белән аралашмый, ул исә үзенең һәр туган көне саен аның телефоннан шалтыратуын көтә иде, – дип сөйли Регина. – Берьюлы түзмәдем, үзенә шалтыратып карарга тәкъдим иттем. Әмма минем элеккеге каенанам оныгына улының номерын бирмәде. Каенанам белән гел аралашып яшәдек, элегрәк ул минем яклы иде, әмма алимент түләүне дәгъвалый башлагач, мөнәсәбәтләр үзгәрде... Күптән түгел кызым алименттан баш тартуымны үтенде, тик мин үз сүземдә калам, чөнки әлеге акча баламны укытыр өчен кирәк булачак бит!

Сүз уңаеннан, мондый бердәм кабул итү көне бөтен республикада үткәрелде. Октябрьдә дә булачак. «Безнең бурыч – башлаган эшебезне азагына кадәр җиткерү», – диде Эльмира Зарипова. Суд приставлары Регинаның ирен дә бар яклап кысканнар. Эш бирүчесен табып, ир-атның хезмәт хакы ни өчен яшәү минимумыннан да азрак булу белән кызыксынганнар. Аның чит ил паспорты һәм машина йөртү таныклыгы булуын ачыклаганнар. Бүген ир-ат чит илгә чыга, автотранспорт белән идарә итә алмый. Киләсе адым – административ, әгәр инде анысы да ярдәм итмәсә, җинаять җаваплылыгына тарту.

– Катлаулы очрак, һәм без аны махсус контрольгә алабыз, – дип ышандырды Регинаны Татарстан Республикасы баш суд приставы урынбасары Әнвәр Зарипов.

БИК КҮҢЕЛСЕЗ ВАКЫЙГА

Суд приставларының Яңа Савин районы буенча бүлегендә башкаручы пристав Эльвира Әхмәтҗанова рейдка әзерләнә. Хәзерге вакытта аның шәхсән үзендә 365 башкару кәгазе бар. Кайберләрендә бурыч 800 мең сумнан артып киткән. Хәсрәтаталарның күбесе балаларына туганнан бирле алимент түләмәгән. Хәер, әтиләр генә дә түгел...

– Бу очракларның кайсы сезнең өчен иң күңелсезе? – дип сорыйм мин Эльвирадан. –Алимент түләмәүче ана, – ди ул уйлап та тормыйча. – Бер хатынның өч сабые да балалар йортында тәрбияләнә, ә үзе яңа фатирда өч мәчесе белән яшәп ята. Балаларына исә түләми. Ни өчен түләмәвен аңлатып та бирә алмый. Мөлкәтенә арест салдык – яхшы телевизор, суыткыч, микродулкынлы мич... Суд аша аны административ җаваплылыкка тарттык, мәҗбүри хезмәткә хөкем иттек. Нәтиҗәдә ул алимент түли башлады. Әлбәттә, бөтен бурычын да түгел, тик аз булса да түли бит!

Эльвира Әхмәтҗанова әйтүенчә, унбиш тәҗрибәсендә кадәр иректән мәхрүм итү һәм мәҗбүри хезмәт – нәтиҗәле чаралар. Кайберәүләр, рәшәткә артында утырып чыккач һәм үз гомере хакында бераз уйлангач, кирәкле нәтиҗә ясый: үз балаңа ярдәм итәргә кирәк икән. Аннары бурычлыга, алимент түли башлар өчен, тагын ике ай бирелә. Шуннан соң да түләмәсә, җитдирәк җаваплылыкка тарталар. Әйтик, бу айда Эльвира Әхмәтҗанова контролендәге ике кешегә карата инде РФ ҖК ның 157 нче маддәсе («Балаларны яки хезмәткә яраксыз ата-ананы карап тотуга акча түләмәү») буенча җинаять эше ачыла. Тулаем республика буенча исә ел башыннан бирле 600дән артыграк шундый эш кузгатылган.

...Беренче адресыбыз – «бик күңелсез вакыйгага» мисал. Гөлнарага егерме тулып кына киткән, ул аналык хокукыннан мәхрүм ителгән, өч яшьлек улы исә балалар йортында тәрбияләнә. Алимент дәгъвалаучылар – опека органнары. Бурыч – илле мең сумга якын.

Соңгы кат. Сулдагы ишек. Бу рейдта Эльвира Әхмәтҗанованы суд эшчәнлегенең законда каралган тәртибен тәэмин итү бүлеге хезмәткәре озатып йөри. Ишектә звонок юк, шуңа Илдус шакый. Озак, катгый итеп шакый. Ниһаять, «Кем бар анда?» – дигән тавыш килә.

– Суд приставлары без! Гөлнара Илдаровна, ачыгыз әле ишекне, – ди Эльвира, һәм шуннан соң ишек артында тынлык урнаша. Приставлар әле һаман китми, көтә. Тавышка күрше хатыны чыга.

– Ачмыйлар алар сезгә...

– Ул, мөгаен, куркадыр, шуңа ачмый да, – ди Эльвира, күр-

Фото: Александр Гайнетдинов



Фото: Александр Ефремов

ше хатынына повестка кәгазен сузып. – Әмма бернинди куркыныч та янамый аңа, шуны җиткерегез әле үзенә.

– Кеше өйдә, тик керә алмыйбыз, – дип бу юлы Эльвира инде миңа мөрәҗәгать итә. – Ярар, тагын берничә тапкыр килергә туры килер әле!

– Сезгә бу эшегездә нәрсә җитми? Сезгә нәрсә дә булса чынлап ярдәм итәр идеме икән? – дип сорыйм мин Эльвирадан.

– Гомумведомствоара база кирәк! Мәсәлән, кеше үзенең паспортын алыштырырга килә, һәм шунда ук безгә шалтыраталар: «Бездә ул, килеп алыгыз!» – диләр. Яки менә бездә дөнья чемпионаты үтте. Полиция хезмәткәрләре никадәр кешенең документын тикшерде! Шул вакытта алар кулында алимент түләмәүчеләр базасы да булса, шунда ук безгә хәбәр итәрләр иде...

«САНТА-БАРБАРА» ЯЛ ИТӘ

Һәм менә Илдус тагын ишек кага. Инде китәргә җыенганда, бусагада йокысыннан уянып маташучы кыз пәйда була.

– Дима абый өйдә юк, – ди ул. «Дима абый» – алимент түләүдән качып йөрүче 43 яшьлек ир-ат. Аның 6 ел өчен бурычы 300 мең сумнан арткан.

Юлыбыз уңганга сөенеп, кыз артыннан коммуналь фатирга үтәбез. Безнең арттан ук ишек тагын ачыла – һәм эзләгән кешебез үзе пәйда була! Эләкте, димәк.

– Дмитрий Владимирович? Ни өчен алимент түләмисез? – дип каршы ала аны Эльвира.

– Ә минем шулкадәр акчам юк! – дип җавап кайтара Дмитрий.

Быел аны җинаять җаваплылыгына тартканнар. Ул мәҗбүри хезмәткә тартылган – эш хакының бер өлеше алимент түләүгә китеп бара. Әмма мондый зур бурычны каплау өчен бу гына җитми. Эльвира мөлкәткә арест салырга килгән.

– Менә чалбарымны алыгыз, футболкамны! Бөтенесе аңа!!! – дип кыза Дмитрий. – Мин бит аның белән язылышмаган, аның балаларын карарга...

Моннан алты ел элек Дима бер хатын белән танышкан. Нибары бер ай очрашканнар. Ул инде егерме ел буе язылышмыйча гына хатыны белән яши, ике кыз үстергәннәр, тиздән оныклары туачак. Улы барлыгын күптән түгел генә, алимент суммасы алты урынлы санга җиткәч кенә белгән. Экспертиза аның чыннан да малайның атасы булуын дәлилләгән.

– Алты ел буе берни дә белмәдем! Һәм менә бурыч килә. Бездә почта тартмалары юк бит, бәлки судка да чакырган булганнардыр. Тик мин бит бернәрсә дә белми яшәдем алты ел буе! Әгәр мине кешегә санасалар, мин акча да җибәрер идем. Ә бу бурычны принципиаль рәвештә түләмәячәкмен! – дип тузына ир.

Дмитрий мәҗбүри төзәтү хезмәтендә эшләгәндә, аның рәсми эш хакының 40 проценты алиментка күчеп бара. Әмма әлеге җиде айлык срок беткәч нишләргә? Инде берничә елдан бирле аның даими эш урыны юк – кайчандыр хөкемгә тартылган булганга, эшкә алырга теләмиләр, дип зарлана. Дөрес, балта остасы һөнәре булыша. Шабашкага йөреп акча эшли.

– Аның улым барлыгын белмәдем дигән әкиятенә ышанмагыз! – ди безгә урамга чыккач Эльвира. – Дмитрийны РФ Җинаять кодексының 157 нче маддәсе буенча җинаять җаваплылыгына тартканнар, аның эше белән прокуратураның сорау алу бүлеге шөгыльләнгән. Мондый һәр вакыйга – чын «Санта-Барбара»! Әйе, кайвакыт тормыш сериалдан да буталчыграк шул.

– 2016 елда алимент түләтүгә кагылган законнарга шактый үзгәреш кертелде, – дип аңлатма бирә Татарстан Республикасы баш суд приставы урынбасары Әнвәр Закиров. – Башкаручы приставның алимент түләмәүчеләрне җинаять җаваплылыгына тарту буенча гамәлләренең алгоритмы үзгәрде. Әгәр элегрәк приставлар аларны мондый җаваплылык турында ике, өч, кайвакыт исә дүрт тапкыр кисәтергә мәҗбүр булса, хәзер исә закон буенча алиментны ике ай гына түләмәү дә административ хокук бозу турында беркетмә төзүгә сәбәп була ала. Аннары исә суд карый һәм тиешле җәзаны билгели – мәҗбүри хезмәт, штраф яки административ арест. Әгәр моннан соңгы ике ай дәвамында бурычлы һаман да алиментын түли башламаса, пристав инде РФ Җинаять кодексының 157 нче маддәсендә күрсәтелгән җинаять составы билгеләре табылу хакында рапорт яза һәм җинаять эше ачу мәсьәләсе хәл ителә.

– Әмма биредә шунысын аңлау мөһим: безнең өчен бу – иң соңгы чараларның берсе, – дип төгәллек кертә Әнвәр Закиров. – Җинаять җаваплылыгына тартылу бурычлының биографиясен тапларга сәләтле. Гадәттә кешеләр хәлне моңа кадәр җиткермәскә тырыша.

Төзәтү эше вакыты тәмамлангач, суд приставлары Дмитрийга Мәшгульлек үзәгенә юллама бирәчәкләр. Анда аңа эш табарга булышачаклар. Рәсми эш урыны табу аның үз мәнфәгатьләре өчен дә бик кирәк. Эш шунда ки, әгәр кеше рәсми рәвештә эшкә урнашмаган икән, аның алимент буенча айлык суммасы Россия Федерациясендәге уртача хезмәт хакыннан чыгып исәпләнә. Бу исә, аз да түгел – күп тә түгел, 44 мең сум! Шунлыктан эрәмтамаклыкның яки соры хезмәт базарында эшләүнең һәр ае аның бурычын ай саен 11 мең сумга арттыра барачак. Җитмәсә, приставлар рәсми эшкә урнашудан качып йөрүчеләргә карата башка чаралар күрергә дә әзер...

...Эльвира бик арыган күренә. Бу гаҗәп тә түгел – мондый эш алҗыта шул. Нәрсә көч бирә соң?

– Без акча дәгъвалаучылар ягында да, алимент түләмәүчеләр ягында да түгел – без балалар мәнфәгатен кайгыртабыз. Аларның мохтаҗлык күрмәвен телибез. Беләсезме, төрле хәлләр була. Балалары бик начар шартларда яшәүче, әтиләре исә, хәлләреннән килсә дә, аларга булышмаучы гаиләләр дә бар. Без гаделлек урнаштырырга булышабыз.

ШӘХСИ ЯКЫН КИЛҮ

Алимент түләмәүченең уртача статистик портреты мондыйрак: гадәттә бу 30–42 яшьлек ир-ат. Татарстанда шундый 11 мең кеше исәпләнә. Болай да хафага төшерерлек статистиканы балаларына бурычлы хатын-кызлар тагын да күңелсезләндерә – аларының саны ике меңнән арта. Алимент түләмәүчеләрнең шак-

Суд приставларының августтагы эш нәтиҗәсе – республикада алиментлар буенча бурыч 16 миллион сумга кимегән.

тые – маргиналь кешеләр. Әмма, приставлар әйтүенчә, әлеге категориягә шактый мул тормышта яшәүче гражданнар да эләккәли. Нигездә бу аерылышкан парлар, үзара нейтраль мөнәсәбәтләрдә булсалар да, яхшы итеп аралашуны саклап кала алмаган очракта күзәтелә. Монда инде алимент түләмәүчеләр принципка бара. Әмма, приставлар әйтүенчә, алар һәр бурычлы кешегә шәхси якын килә, тәэсир итү чаралары да төрле. Кемдер – мөлкәтенә, кемдер транспорт чарасына арест салганнан соң уйлана башлый.

– Кайвакыт без бурычлы алиментчының автомобилен тиз арада таба алмыйбыз, – дип сөйләвен дәвам итә Эльвира Әхмәтҗанова. – Безгә ЮХИДИ хезмәткәрләре ярдәм итә. Менә кичә генә шалтыраттылар әле: машинаны законсыз парковкага эвакуацияләгәннәр, база буенча тикшергәннәр, аннан файдалану тыелган булып чыккан. Нәтиҗәдә без автомобильгә арест салдык. Аның хуҗасына нишләргәме? Ул аны бездән сатып алырга тиеш, югыйсә без сатуга куячакбыз. Алынган акча исә алимент буенча бурычны каплауга тотылачак.

Суд приставлары хезмәте инде берничә ел дәвамында законнардагы үзгәрешләр генераторы һәм башкаручысы булып тора. Әйтик, мәсәлән, махсус хокукны, ягъни автотранспорт белән идарә итүне чикләү алимент түләмәүчеләргә каршы көрәшнең иң нәтиҗәле чараларыннан берсенә әйләнде. Бүген алиментлар буенча башкару кәгазьләре кысаларында 2,8 меңнән артыграк кеше мондый хокуктан мәхрүм ителгән. Тагын бер үтемле чара – чит илләргә чыгуны тыю. Ул инде 15 мең алимент түләмәүчегә карата кулланылган.

Әмма, кызганыч ки, бурычлыларның барысы да адекват һәм социальләшкән түгел. Бурычлары бик зур булганнарның күпчелеге «яшеренүне» артыграк күрә. Быел законга тагын үзгәреш кертелгән – суд приставлары бүлеге эзләүчеләре алимент түләмәүченең торган җире һәм яшәү урыны турында бер ел буена белешмә таба алмаса, аны хәбәрсез юкка чыккан дип тану процедурасы гадиләштерелгән. Элегрәк бу процедура күпкә катлаулырак булган.

– Быел инде өч кеше хәбәрсез юкка чыгучы дип танылды, – ди Әнвәр Закиров. – Моңа охшаш хәлләрдә калучы дәгъвачыларның барысына да без тиешле аңлатмалар һәм судка мөрәҗәгать итү өчен гариза үрнәкләре җибәрәбез. Уңай хәл ителгән очракта аларга туйдыручыны югалту буенча пенсия билгеләнәчәк. Бу аларның финанс хәлен шактый яхшыртыр, дип уйлыйм.

Күптән түгел Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе «Баланңы исеңә төшер – алиментларыңны түлә» дигән акция үткәрде. Аның максаты – гражданнарга үзләренә йөкләнгән бурычны үтәмәүнең нәрсәгә китерәчәге турында мәгълүмат бирү. Ихтимал, алиментны берничек тә түләми калып булмау аларның кайберләре өчен ачыш булыр. Эшсезлек тә, каты авыру да, гариплек тә аларны түләүдән азат итми... Чөнки бала ул – гомерлеккә синеке, ата-ана аның турында һичшиксез кайгыртырга тиеш.

Әнвәр Закиров әйтүенчә, бүген суд приставлары хезмәте җәмгыятьнең хуплавына мохтаҗ. Чөнки алиментлар буенча бурычларның күплеге – лакмус кәгазе, җәмгыятьнең нинди хәлдә булуын күрсәтә торган тест ул.

– Ни өчендер бездә халык алимент түләмәүчеләргә битараф мөнәсәбәттә, – ди ул. – Без исә әлеге мөнәсәбәтне үзгәртергә телибез. Алимент түләмәүчеләр белән эшләү өчен республикада күптән түгел төзелгән ведомствоара комиссия суд приставлары хезмәте, эчке эшләр органнары, прокуратура, опека органнары, балигъ булмаганнар белән эшләү комиссияләре, шулай ук гаммәви мәгълүмат чаралары тырышлыгын берләштерергә тиеш. Без бурычларны түләтү проблемасын хәл итеп кенә калмыйча, алимент түләмәүнең оят эш булуы турында бөтен җирдә сөйләячәкбез. Без бергәләп балалар мәнфәгатьләрен кайгыртырга тиеш.

Фото: Александр Ефремов

ӘГӘР СЕЗ АЛИМЕНТ ТҮЛӘМИСЕЗ ИКӘН,

сезгә карата мондый мәҗбүри чаралар күрелергә мөмкин:

Хезмәт хакыгызны һәм банктагы яки башка кредит оешмаларындагы акчагызны тотып калу

Шәхси мөлкәткә арест салу һәм тартып алу
сезгә бурычыгызны түләү өчен 10 көн биреләчәк. Түли башламасагыз, мөлкәтегез аукционда сатылачак, шуннан кергән акча бурыч хисабына җибәреләчәк

Күчмә һәм күчемсез милекне теркәүне тыю

Россия Федерациясе чикләреннән чыгу хокукын чикләү
Әгәр алимент буенча бурычыгыз 10 мең сумнан артса, чит илгә чыга алмыйсыз. Суд приставлары үзегезнең бурычларыгыз турында мәгълүматны сәфәр чыгарга ким дигәндә бер атна кала тикшерергә киңәш итә

Махсус хокуктан (транспорт чарасы белән идарә итү хокукыннан) **файдалануны чикләү**

Административ җаваплылыкка тарту

Җинаять җаваплылыгына тарту –
югарыда санап кителгәннәрнең берсе дә сезне алимент түләргә мәҗбүр итә алмаган очракта

Истә тоту мөһим:
административ һәм җинаять җаваплылыгына тарту бурыч түләүдән азат итми

ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АША **ТОРГАН ЙОРТ**

– Абра-кадабра! – ди серле тавыш белән фокус күрсәтүче, божраның тимер чылбырыннан тартып. Ниндидер могҗизага буйсынып, божра белән чылбыр икесе ике кулга күчә. Тынгысыз бала-чага, чираттагы могҗизаны көтеп, артистны уратып ала. Янәшәдә әлкәннәр басып тора. Алар да көтә, ләкин чираттагы фокусны түгел, ә балаларының сәламәтләнүен. Сәламәтлек – монда, Роналд Макдоналд йортында, һәркем бер-берсенә тели торган изге теләк.



Роналд Макдоналд йортын, ягъни Казандагы Балалар республика клиник хастаханәсенең онкогематология, неврология һәм реанимация бүлекләрендә катлаулы яисә озакка сузылган дәвалану үтә торган балалы гаиләләр өчен бушлай кунакханәне төзү 2012 елда башлана. Инде бер елдан Йорт үзенең ишекләрен тәүге кунаклары өчен ача. Шуннан башлап ул сигез меңнән артык гаилә өчен икенче йортларына әверелә.

Бу урын чыннан да тылсымлы: биредә балаларның хыялларын чынга ашырырга ярдәм итәләр. Сәхнәдә яраткан башкаручың белән бергә җырлау, футбол буенча дөнья чемпионаты кырына легендар футболчы белән бергә чыгу, кулинарлык серләренә төшенү, үзеңнең күлмәкләр коллекциянне булдыру… Бу һәм башка могҗизалар мондагы балалар өчен чынбарлыкка әйләнде.

– Биредәге балаларның әти-әниләре, тулысынча көнкүреш мәшәкатьләрен онытып, бөтен көчләрен балаларының сәламәтлегенә бирсеннәр өчен тырышабыз, әниләр өчен хәтта махсус психология мәктәбе дә ачтык. Без гаиләләргә диагноз куюдан алып җиңүгә – тулысынча сәламәтләнүгә кадәр булган озын, катлаулы юлның һәр адымында булышырга омтылабыз. Ә безгә исә балаларыбызның һәр көнен якты, матур итәргә тырышкан игелекле кешеләр булыша, – ди Роналд Макдоналд йорты директоры Юлия Маркова.

Екатерина Мыслицкая, Роналд Макдоналд йорты Хәйрия фондының хәйриячелек проектлары менеджеры:
– Озакка сузылган дәвалану чорында бала өчен әти-әнисенең һәм якыннарының мәхәббәтеннән, кайгыртуыннан һәм ярдәменнән дә мөһимрәк берни юк. Без Татарстан җитәкчесенә һәм Балалар республика клиник хастаханәсе җитәкчелегенә әлеге уртак хыялыбызны чынга ашыру мөмкинлеге биргәннәре өчен рәхмәтле. Без биредәге шәп табиблар белән бергә гаиләләрнең үз өйләренә кайту көннәрен якынайтабыз.

Татьяна Ларионова, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары:
– Бу Йорт сабыйларда өмет уята, аларга көч, сәламәтлек бирә. һәм балаларының сәламәтләнүен күргән әлкәннәргә иксез-чиксез бәхет китерә. Мондый учреждение башка Казанда да, Татарстанда да, Россиядә дә юк.

Рафис Борһанов, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры:
– Без җәмгыятьнең кешегә йөзе белән борылуын күрәбез. Бирегә битараф булмаган, күренекле кешеләр килә, алар барысы да ярдәмгә ашыга. БРКХ коллективына һәм ярдәм кулы сузган һәркемгә зур рәхмәт. Ә балаларга – сәламәтлек телим, киләчәктә алар бер-берсе белән монда түгел, төрле спорт һәм бәйрәм чараларында очрашсыннар!

Фото: Александр Ефремов

Реклама

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанда икмәк буенча **КЕМ** беренче

Республикада яшелчәчелек **НИ** хәлдә

Укытучылар **НӘРСӘ** ашый

Чирмешән районында «хәзинәләр сандыгы» **КАЙДА** яшерелгән

ЭССЕ ҖӘЙНЕҢ КАЙНАР ИКМӘГЕ

Һава торышы һәм базар бәяләре, дөресрәге, аларның җилбәзәк тотрыксызлыгы... Мөгаен, авылда ныклы хуҗалык иткәннәргә менә шул сәбәпләр чыгымнарына күрә яхшы нәтиҗә алырга комачаулыйдыр да. Татарстан аграрийларын быел тегесе дә, монысы да ныклыкка сынап карады. Нәтиҗәсе нинди соң?

Автор:
Әскәр Сабиров

Узган елгы биш миллионлык рекордтан соң, быел басулардан җыеп алынган уңыш тыйнаграк күренә, әлбәттә. Ләкин бу көчле корылыкның ныклыкка сынавын һәм игенчеләребезнең профессиональлеген исәпкә алмаганда. Министрлар Кабинетында август аенда узган брифингта ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов болай диде: «Җәйнең яңгырсыз килүе һәм туфрактагы корылык аркасында республиканың 17 районында гадәттән тыш хәл режимы кертелде. Бу безнең өч ай дәвамында дым 70 миллиметрдан азрак булган, яңгыр яумаган районнар. Чагыштыру өчен мәгълүмат: күп еллар дәвамында уртача күрсәткеч 170 миллиметрны тәшкил итә...»

РЕКОРДЛАР ҺӘМ «ОЕШКАНЛЫКНЫҢ АЕРЫМ БЕР ИНДИКАТОРЫ» ТУРЫНДА

Гадәттән тыш хәл режимы фонында республика буенча бөртеклеләрдән уртача уңыш, ягъни гектарыннан 25,9 центнер, начар күрсәткеч түгел, әлбәттә. Гәрчә корылык барыбер үзенең кара эшен эшләсә дә. Хуҗалыкларга килгән зыян саналыр, билгеле, алдан ук чәчүлекләрен иминиятләштергәннәр югалтулары өчен компенсациягә исәп тотарга мөмкин. Табигый ки, моның өчен фаразланган һәм финанслар кертелгән уңышлылык һәм фактта җыеп алынган уңыш арасындагы аерманы тигезләргә кирәк булачак.

Ләкин барысын да начар һава торышына гына сылтау – акыллы гамәл түгел. Төп авыл хуҗалыгы ведомствосында ышаналар: хәтта бүгенге уңайсыз килгән һава шартларында да уңыш зуррак булырга мөмкин иде. Центнер һәм тонналарның алынып бетмәвенә китергән сәбәпләрнең берсен Марат Әхмәтов та билгеләп узды: «Әгәр минераль ашламалар кертү күләме узган елгы – гектарына 65 килограмм тәэсир итүче матдә дәрәҗәсенә генә җиткерелгән булса да, бөртеклеләр буенча күрсәткечләр күпкә югары-

Фотолар Рәфкать Бильданов, ТР Президенты, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы сайтыннан алынды

өчен рекордлы уңыш җыя алды: гектарыннан 32,5 центнер уңыш алып, 151 мең тонна ашлык (кукурузны исәпкә алмаганда) озатты. Зәй районында уңыш гектарыннан – 37,1 центнер! Әлеге фонда Бөгелмәнең гектарыннан 19 центнеры яисә Алабуганың 20 центнеры кызганыч тоела! Өстәвенә, әлеге ике аутсайдер район республика буенча иң аз яңгыр яуган җиде район исәбенә керми.

Кайвакыт үстерелгән икмәк эшне дөрес оештырмаудан да югала. Министрлар Кабинетында узган селектор киңәшмәсендә түбәндәге хәбәр яңгырады: Мамадыш, Югары Ослан һәм Әгерҗе районнарында борчак сугуны озакка сузганнар. Вак-төякме? Ничек карыйсың бит. Эш шунда ки: борчак җыеп алуны хәтта оптималь срокларда башкарганда да югалтулар шактый зур була. Ә инде җыеп алуга соңарып тотынганда – үстерелгән ярты уңыш югалырга мөмкин. Менә сезгә «вак-төяк»! Марат Әхмәтов билгеләп үткәнчә, «борчакны җыеп алу – оешканлыкның аерым бер индикаторы ул».

Хәер, агротехника турында җиткәндер. Гади татарстанлы уңыш турында базарда һәм кибетләрдә кайсы товарның нинди бәядән тәкъдим ителүенә карап фикер йөртергә ияләшкән бит.

БӘЯЛӘРНЕ ТИКШЕРИК

Тулаем Россия буенча бөртекләрнең уңышы узган ел белән чагыштырганда сизелерлек түбән кителүе турында хәбәр чыгуга, кайбер төбәкләрдәге икмәк ризыклары җитештерүчеләр үз продукцияләренә бәяләрнең арту мөмкинлеге турында сүз кузгатты. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында исә, аз дигәндә, яңа елга кадәр борчылыр сәбәп юк, дип исәплиләр. Беренчедән, Татарстанда җыеп алынган уңыш азык-төлек бөртекләре буенча республика ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерергә җитә. Икенчедән, икмәкнең үзкыйммәтендә онның бәясе артык зур түгел. Ниһаять, әгәр яңа елдан соң бөртек бәясе бераз күтәрелсә дә, хакимият 2016 елда кулланылган субсидияләү системасын кабатларга мөмкин. Шулай итеп икмәкнең 1 сортлы бодай оныннан пешерелгән «Сельский», «Дарницкий», «Белый» кебек социаль сортларына бәянең кинәт артуы көтелми.

«Икенче икмәк» базарында да хәлләр шактый имин тора. Әле август аенда, корылыкның иң котырынган вакытында, Марат Әхмәтов ТР Президентын: «Бездә бәрәңге һәм яшелчә сугарыла, шуңа күрә, җәй коры килсә дә, уңыш белән тәэмин итә алачакбыз», – дип ышандырган иде. Республикада башланып киткән рак булырга мөмкин иде. Кайбер районнардагы уңдырышлылык тагын бер мәртәбә әнә шуны раслый. Ашлама экономияләнә һәм янга калдырыла торган чыгымнарга керми. Киресенчә, югалтулар арта гына. Җитәрлек, балансты тукландыру – корылыкка каршы торуда төп чараларның берсе. Димәк, бу гарантияләнгән уңыш дигән сүз».

Уртача республика күрсәткечләрен күпкә арттыра алган хуҗалыклар мисалы моңа иң яхшы дәлил: үрнәк агротехника һәм эшне дөрес оештыру корылык китергән зыянны да капларга мөмкин. Мисал өчен, Актаныш районы яңгырсыз килгән елда да үзе

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТР авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов Буа муниципаль районына эш сәфәре вакытында.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Чүпрәле районы авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре белән.

авыл хуҗалыгы ярминкәләре министр тарафыннан ясалган фаразларның дөрес булуын күрсәтте. Киштәләрдә бәрәңге мул күренә, бәяләр узган елгы тирәсендә – килограммына 12 сумнан башлана. Былтыргы көз белән чагыштырганда, суган, кишер, кәбестә бәяләре дә артмаган.

Сыер ите, дуңгыз ите, кош ите, һәм йомырка җитештерүләренең сигез ай эчендә артуы базарның әлеге сегментында дулкынланулар китереп чыгармаска охшап тора. Сөт ризыклары өчен дә борчылмаска мөмкин. Татарстан традицион рәвештә сөтне Россиянең теләсә кайсы башка төбәгенә караганда күбрәк җитештерә, хуҗалыкларда сигез ай эчендә 883 мең тонна сөт савып алынган – бу узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, бер процентка югарырак.

Әлеге бер процентка ирешү шактый авырга туры килде – агымдагы елның беренче яртысында сөткә бәяләр төшкәннән соң, хуҗалыклар үзләренә зыянга эшләмәс өчен, терлекләрнең баш санын кыскарта башларлар дигән шик бар иде. Бәхеткә, вазгыятьне кулга алырга мөмкин булды – нигездә республика ягыннан терлекчеләргә финанс ярдәмен вакытында күрсәтеп өлгерү бәрабәренә. Әмма базарга арзанлы коры сөт чыгару аркасында натураль сөткә бәяләрнең төшүенә китергән борчулы нәтиҗәләр сизелә әле: МЭТ ите үстерелгәнгә караганда күбрәк сатылган, ягъни баш саны кими дигән сүз...

Бүгенге көндә сөтне сатып алуның уртача бәясе артты, ләкин ул узган елгыга караганда барыбер өч сумга түбәнрәк (агымдагы елның беренче кварталында аерма биш сум иде). Моның белән ничек көрәшергә? Әлбәттә, чималны арттыру юлы белән. Сөт җитештерү буенча лидер Татарстан аны эшкәртү тармагында җитди резервларга ия. Шуңа күрә алдагы елларда вазгыять үзгәрер дигән өмет бар. Казан, Яр Чаллы, Биектау һәм Касыйм сөт эшкәртү заводларында алып барылган модернизация җирле чималны тулы күләмдә үзебездә – Татарстанда эшкәртергә мөмкинлек тудырачак.

Билгеле булганча, Татарстанда эшләнгән май, сөт, башка сөт продуктлары нигездә яхшы сыйфатлы, чөнки алар натураль чималдан ясалган. Әмма проблема шунда: натураль продуктлар бәяләре ягыннан һәрвакытта да төрле алыштыргыч матдәләрдән җитештерелгәннәре белән көндәшлек итә алмый. Биредә инде һәркем үзе теләгәнчә эш итәргә хаклы: аңа тәмле, сыйфатлы, сәламәтлек өчен файдалы продукт кирәкме яисә арзанрак, ләкин сыйфат ягыннан шиклесеме.

Икенче яктан караганда, кешенең сайлап алу хокукы булсын өчен, билгеле бер муллык дәрәҗәсе сорала. Һәрхәлдә, ашламаларсыз, химикатларсыз һәм өстәмәләрсез үстерелгән, натураль чималдан ясалган органик продукция чит илләрдә башкаларына караганда күп мәртәбәләргә кыйммәтрәккә сатыла. Дәүләтебез кондициягә туры килмәгән ризыклар һәм төрледән-төрле фальсификатлар ясаучылар белән көрәштә активрак булганда, Татарстан авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре инде бүген үк органик продуктлар базарында яхшы акчалар эшли алыр иде.

Базар шартларында акча эшли белү яхшы уңыш үстерү кебек үк бик мөһим. Уңышны үстерү үзе генә җитештерүчегә финанс иминлеген гарантияли алмый, аны әле сатарга да кирәк.

БАЗАР ПАРАДОКСЛАРЫ ҺӘМ КОРЫЛЫК «ПЛЮСЛАРЫ» ТУРЫНДА

Былтыр җыеп алынган рекордлы уңыш Татарстан җитештерүчеләренә нииндидер күләмдә зыян да салды кебек. Түбән сатып алу бәяләре бөртеклеләрне планлаштырган бәядән сатып җибәрергә мөмкинлек калдырмады.



Нәтиҗә дә тагын да начаррак булырга мөмкин иде, күпләрнең Авыл хуҗалыгы министрлыгы киңәшен тыңлаулары ярдәм итте. Аграр ведомство җитештерүчеләргә ашлыкны көзен җыеп алуга түгел, бәяләр күтәрелгәч, билгеле бер дәрәҗәгә җиткәч сатарга киңәш биргән иде. Фараз дөрескә чыкты. Узган елгы ашлыкның шактый өлеше быелга кергәч, югарырак бәядән сатылды.

Быел бөртеклеләрне берничек тә үзкыйммәтеннән дә арзанракка сатарга туры килмәячәк. Инде бүген үк өченче классны бодайның бер тоннасына бәя сумнарда ун мең ярымга җитә, ә арпаның бер тоннасына тугыз-ун мең сум тәкъдим итәләр. «Бу бит яхшы бәя, ихтимал, ул алга таба да күтәрелә барыр», – дип кисәтә Марат Әхмәтов, тагын авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен сату белән ашыкмаска чакырып. Аның сүзләренә караганда, ашлыкны элеваторга алып бару, бушатуны исәпкә алып санаганда, аны сатуның үзкыйммәте якынча җиде мең сум. Ашлыкны сатудан көтелгән рентабельлек – егерме процент.

Парадокс, әмма хәтта явыз корылык та хуҗалыкларга өстәмә рәвештә акча эшләп алу мөмкинлеген бирә. Эш шунда: озакка сузылган эссе һава торышы хәтта силос өчен утыртылган кукурузга да өлгерү мөмкинлеге тудырды. Авыл хуҗалыгы министрлыгы, бөртек өчен туры килерлекләрен ачыклау максатыннан, кукуруз кырларына мониторинг үткәрергә тәкъдим итте. «Беренчедән, бу – сөтне арттыру чыганагы, икенчедән, 300 мең тонна кукурузны бөртеккә сугып, без терлек азыгына дип торган арпаны саклый алабыз, аның бер тоннасы бүген базарда 10 мең сум тирәсе тора, без арпаны сатып җибәрә алабыз», – диде Марат Әхмәтов күптән түгел генә узган видеоконференциядә, перспективалы операциянең асылын ачып.

Шул рәвешле конъюнктураны белү, базарны анализлау һәм стандарт булмаган карарлар кабул итү өстәмә керем алырга ярдәм итә. Ә бу авылда техник потенциалны яңарту, хезмәт хакларын арттыру, социаль инфраструктураны яхшырту мөмкинлекләре дигән сүз. Югары нәтиҗәләргә ирешкәннәрнең тормышларын яхшыртмаганда, күрсәткечләр үзләре генә бик аз нәрсәне генә аңлата бит.

БАРЫ ТИК ФАКТЛАР ГЫНА...

2019 елда ТР агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү максатларына **10,7 миллиард сум** бүленәчәк. Шулардан **5 миллиард сумы** – РФ бюджетыннан, **5,7 миллиард сумы** – ТР бюджетыннан.

Авылга дәүләт ярдәме (федераль үзәк белән уртак финанслау):

- Үсемлекчелек өлкәсендә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә, сөтчелек терлекчелегендә продуктлылыкны күтәрүгә, максатчан күрсәткечләргә ирешүгә субсидияләр
- Нәселле терлекчелеккә ярдәм
- Эш башлаучы фермерларга, гаилә фермаларына, а/х кулланучылары кооперативларына ярдәмгә грантлар
- Сугару чараларын үткәрүгә субсидияләр
- Авылны социаль яктан үстерү чараларына ярдәм
- Үсемлекчелек һәм терлекчелек өлкәләрендә иминиятләштерү
- Элиталы орлыкларга һәм күпьеллык үсентеләр утыртуга субсидияләр
- Үсемлекчелек һәм терлекчелек өлкәләрендә максатчан үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәмгә субсидияләр

Татарстан Республикасы бюджеты хисабына гына дәүләт ярдәме:

- Техник һәм технологик модернизацияләүгә субсидияләр
- Оешмалар мөлкәтенә түләнгән салым чыгымнары өлешен кайтаруга субсидия
- Әче туфракны известьләү буенча чаралар
- Татарстан Республикасында туфрак эрозиясенә каршы һәм кырны саклау өчен урман үсентеләрен утырту буенча чаралар
- Сугару эшләренә ярдәм
- Сугару объектларын техник яктан яңадан коралландыруга субсидияләр
- Шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга ярдәм күрсәтү чаралары
- Кадрлар белән тәэмин итү чаралары.

Татарстан Республикасында 38 республика программасы гамәлгә ашырыла, шуларның 30ы – авыл объектлары катнашлыгында.

Татарстанда 100 һәм 200 башка исәпләнгән сыер абзарларын капиталь ремонтлау, силос-сенаж траншеяләрен төзү, яшелчә-бәрәңге саклагычларын, машина-трактор паркларын, ашлык ындырларын капиталь төзекләндерү программалары гамәлгә ашырыла.

Авылда алып барыла торган мөһим инвестицияле проектлар арасында. Зәйдә 150 мең тоннага исәпләнгән элеватор комплексын, Актаныш, Бөгелмә, Баулы, Азнакай, Әлмәт, Әтнә, Балтач, Кукмара, Саба, Лениногорск, Балык Бистәсе, Тукай районнарында сөт комплекслары төзелешен атарга була.

2018–2019 елларда республиканың 15 эре шәһәрендә 18 авыл агросәнәгать паркын төзү планлаштырыла. Пилот проекты инде Зәйдә гамәлгә ашырыла башлады. Бинаның гомуми мәйданы – 1072 квадрат метр, анда сәүдә залы, ит, сөт, яшелчә җитештерүче һәм суытычлар булачак.

ЕЛ ӘЙЛӘНӘСЕ – «МАЙСКИЕ» ЯШЕЛЧӘЛӘРЕ

Аларның агропарктагы сәүдә урыны һәм ярминкә көннәрендә шәһәр буйлап йөри торган автокибетләре янында озын-озын чиратлар тезелә. Татарстанда «Майский» теплица комбинаты» ЖЧЖ үстергән кыяр-борычларны кетердәтә-кетердәтә кем генә ашамаган, сусыл помидор һәм яшел тәмләткечләрне кем генә татып карамаган икән! Бүген «Майский» – Европада яшелчәләрне өстәмә яктырту – теплицада яшелчә үстерүнең заманча технологиясен куллана торган иң эре комбинатларның берсе. Быел үз тарихында тәүге тапкыр комбинат яшелчә җитештерүдә 40 меңлек чикне узып китте.

«МАЙСКИЙ» ГЕОГРАФИЯСЕ

Әле иртән генә яшелчәләр теплицада үсеп утыра, ә төшке ашка инде казанлылар табынына китерелә. Агрокомбинат продукциясе бөтен Татарстанда сатыла, шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Киров, Екатеринбург, Пермь, Новосибирск, Чиләбе, Төмән, Сургутка һәм Россиянең башка шәһәрләренә дә җибәрелә.

Монда, әлбәттә инде, кыярлар – корнишоннар һәм озын кыярлар турында сүз бара. Аннары помидорлар – эре биф-томатлар, сливасыманнар һәм бик күпләр үз иткән төрле төсләрдәге черриләр. Баклажаннар һәм җете төсле татлы борычлар, салатлар, укроп, петрушка, сельдерей, редис, кинза һәм базилик. Әле тагын чәчәкләр һәм хуш исле, яңа гына җыеп алынган җиләкләр дә бар… «Майский» – Россиядә өчтән бер мәйданыннан күбрәк өлеше ел әйләнәсе яшелчә җитештерүгә көйләнгән бердәнбер теплица предприятиесе.

ХИМИЯГӘ – ЮК!

Продукциянең сыйфаты, аның уңышлылыгы, теплица хуҗалыгындагы җитештерүнең технологик күрсәткечләре бүген бер генә көндәшне белә, ул да булса Нидерланд яшелчәчеләренеке. Ә экологик күрсәткечләр ягыннан исә «Майский» яшелчәләре балалар туклануы өчен куелган таләпләргә җавап бирә. Комбинатта иң куркыныч матдәләр – агулы химикатлардан тулысынча котылганнар. Моңа үсемлекләрне корткычлардан биологик ысул белән – энтомофаглар ярдәмендә саклау бәрабәренә ирешкәннәр. Аларны шушында – үз биолабораторияләрендә үк җитештерәләр. Әйтик, быел монда үсемлекләрне саклау өчен инде бер миллион ике йөз меңнән артык тере инсектицид үстергәннәр, шулар белән агулы химикатларны бик уңышлы алыштырганнар. Файдалы бөҗәкләрдән гыйбарәт әлеге галәмәт зур гаскәр бүген, хәтта корткычлар булмаганда да, гел әзер тора. Биосаклау бик зур чыгымнар таләп итеп, химик саклауга караганда бермә-бер күбрәк акча тотылса да, хуҗалыкта моны үзен аклый дип санһйлар. Чөнки ахыр чиктә республика халкының сәламәтлеге турында сүз бара. Ә инде, билгеле булганча, саулыкка акча кызганмыйлар.

Фотолар «Майский» теплица комбинаты» ЖЧЖ тарафыннан тәкъдим ителде

Реклама

Илшат ГАНИЕВ, «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры:
– «Майский» теплица комбинаты – һәр нәрсә иң югары дәрәҗәдә оештырылган тиңе булмаган комплекс ул, дип бүген ышаныч белән әйтергә мөмкин. Үсемлекләрнең үсүе өчен шартлар тудырудан башлап предприятиенең лаеклы социаль сәясәтенә кадәр. Россиядә генә түгел, Европада да югары бәяләнгән, экологик яктан йөз процент куркынычсыз продукция җитештергән хәлдә, без эшчеләребезгә хезмәт һәм тормыш алып бару өчен бик яхшы шартлар булдыруыбыз белән дә горурлана алабыз.

Авыл хуҗалыгындагы башка барлык хезмәттәшләребез кебек, без дә бай тәҗрибәбезгә һәм һәр яктан республика җитәкчелегенең ярдәменә таянган хәлдә, үз юлыбызны салып, алга баруны дәвам итәбез. Бу юлның дөреслегенә ышанабыз. Үз якташларыңны сыйфатлы һәм экологик яктан чиста ризык белән сыйлаудан да яхшырак ни бар? «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖнең бар коллективы һәм шәхсән үз исемемнән барыгызны да һөнәри бәйрәм – Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне белән котлыйм. Билгеләнгән максатларга таба ышаныч белән атларга, яулаган уңышларны арттырырга насыйп булсын! Һәркемгә ныклы сәламәтлек, бәхет һәм игелек телим!



2018 елда «Майский»ның җитештерүчәнлеге **42 мең тонна яшелчәгә җитте.**

Соңгы биш елда натуралата хисапта җитештерү күләме **60% ка артты.**

Соңгы 5 елда теплицалар, кече энергетика объектлары төзелешенә, автотрактор паркын үстерүгә, социаль объектлар төзелешенә ясалган кертемнәр **4 млрд сумнан артып китте.**

БАРЫСЫ ДА ҮЗЛӘРЕНЕКЕ – УТЫ, СУЫ, ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ...

Комбинат үзенең максатчан программасы нигезендә тормышка ашырыга ирешкән аерым энергетик инфраструктура технологияләрне сизелерлек яңартырга һәм оптимальләштерергә, яшелчәләрне хәтта сезон тәмамланган чорда да җитештереп, көндәшлеккә сәләтле бәядән сатуны оештырырга мөмкинлек бирә. Комбинатның үзе төзегән энергетика үзәге – Россиянең агросәнәгать комплексы өчен тиңдәше булмаган мөһим проект. Чөнки теплицаларга хезмәт күрсәткәндә, җылылык һәм электр энергиясе башка теләсә нинди сәнәгать предприятиесенә караганда да берничә тапкыр күбрәк тотыла. Әлеге проектны тормышка ашыруда Татарстан җитәкчелеге һәм республика авыл хуҗалыгы министрлыгының да өлеше зур булды. Комбинат кирәкле энергия һәм җылылыкны бүген тулысынча диярлек үз энергия чыганагыннан ала.

ҮЗ ИЛЕБЕЗ ҖИТЕШТЕРҮЧЕЛӘРЕ ГЕНӘ

Әле 90 нчы еллар башында ук «Майский» чит ил товарларыннан баш тартуга юнәлеш ала һәм әлеге принципны акрынлап һәм эзлекле рәвештә барлык технологик һәм конструкция мәсьәләләрендә куллана. Импортны алыштыру эше бүген предприятиедә тулысынча тормышка ашырылган, дип әйтергә мөмкин. Автоматлаштырылган су сибү, макроэлементлар составын көйләү, тукландыру системалары һәм сугару өчен кабат кулланыла торган дренаж суны чистарту җайланмасы – болар барысы да Россиядә җитештерелгән.

ЛАЕКЛЫ ТОРМЫШ ШАРТЛАРЫ

Предприятиенең тотрыклылыгы, технологияләрнең камиллеге, продукциягә сорауның зур булуы һәм аның даими рәвештә сатылып торуы «Майский»га социаль юнәлешне дә актив үстерергә мөмкинлек бирә. Күпфатирлы йорт төзелеше бара, соңгы елларда күпфатирлы ике торак йорт, 40 балага исәпләнгән ясле-бакчалы янкорма белән 44 һәм 55 фатирлы ике тулай торак төзелгән. Волейбол, баскетбол мәйданчыклары, тренажёр залы булган каплаулы спорт комплексы эшләп килә. Хезмәткәрләр өчен ачык спорт комплексы да бар, анысында – футбол кыры, балалар мәйданчыгы, шугалак. Яшь гаиләләргә һәм пенсионерларга ярдәм күрсәтелә.

ФЕРМЕР БАР ИКӘН, ДИМӘК, АВЫЛ ДА ЯШИ...

Минталип Исмәгыйль улы Миңнеханов – алдына куйган максатына һәрвакыт ирешә торган булдыклы кешеләр токымыннан, моның өчен хәтта гомер буе башкаларның хәленнән килмәгәнне эшләргә туры килсә дә.

ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов (сулдан беренче) Тукай районында.

2000 елда «Вечерняя Казань» газетасында «Татарстаннан бәрәңге игүче фермер Путинның «борынына чирткән» дигән шаккаткыч башисем белән бер мәкалә басылып чыкты. Анда сүз шул хакта бара иде: РФ Президенты Владимир Путинның АКШ илбашы Джордж Буш белән тәүге очрашуына бер көн кала, ТР Бәрәңге җитештерүчеләр ассоциациясе (АСКАР) директоры Минталип Миңнеханов Америка президенты белән күрешү генә түгел, әңгәмә дә кора алган.

Бу хәл Оранджбург (Төньяк Каролина) каласында була. Россия фермерларының тәҗрибә алмашу программасы буенча шунда белем арттырырга килгән чаклары. Сайлаучылар белән очрашу вакытында АКШ президентының Россия фермерлары белән дә күрешәчәге билгеле булгач, авыл эшчәннәре делегациясе спикер сыйфатында бертавыштан Миңнехановны тәкъдим итә.

– Дж. Буш Россиядә демократия, хосусый милек үсеше белән кызыксынды, безне Америкада ничек каршы алулары турында сорашты. Мин чыннан да демократиянең үсеп килүен, бик күп шәхси предприятиеләр ачылуын раслап җавап бирдем. Безне яхшы кабул иттеләр, дидем, җирле фермерлар белән бик шәп аңлашуыбызны, уртак тел тапканлыгыбызны җиткердем. Иң югары даирәдә очрашу барышында да үзара тулысынча аңлашу булсын дигән теләк белдердем, – дип искә ала Минталип Миңнеханов.

Бүген дә, инде ике дистә ел чамасы узгач та, теләсә кайсы катлаулы эш белән җитәкчелек итәргә сәләтле кеше буларак, аңа карата халык ышанычы һич кимеми. Шушы егерме елга якын вакытта Миңнеханов Тукай районы фермерлары ассоциациясе идарәсенең алыштыргысыз җитәкчесе булып тора. Быел ассоциациянең берничә әгъзасы, авыл хуҗалыгы кооперативы оештырып, яшелчә саклау урыны, яшелчәләрне сатуга әзерләү һәм эшкәртү цехы төзи башлады. Алар Тукай районы продукциясе белән зур кибет челтәрләрен тәэмин итәргә ниятли, әле Татарстан территориясе белән генә чикләнеп калмаска да исәпли.

– Савыт-янчыкка салынмаган, юылмаган продукцияне супер – һәм гипермаркетлар кабул итми, ә эшкәртү цехында без яшелчәләрне юу эшен дә, киптерү, сортларга аерып, аннары капларга, капчыкларга бүлүне дә оештырып җибәрә алабыз, – дип сөйли Минталип Исмәгыйлович. – Әлегә кооперативыбызга дүрт фермер хуҗалыгы һәм сигез шәхси хуҗалык керде. Ләкин оешмабызга район авылларындагы башка җитештерүчеләрне дә актив җәлеп итәбез.

Җирле авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү өчен завод төзү проекты турында «Чаллы икмәге» ширкәте дә, «Тулпар» компанияләр төркеме дә уйланып йөрде, ләкин аны чын-чынлап тормышка ашыруга барып җитә алмадылар. Ә кооператив инде бинаның төп каркасын күтәреп тә куйды.

– Без цех өчен җиһазлар сатып алырга әзер, ләкин алар бик кыйммәт. Ә без билгеле бер суммадан артык акчаны чыгарып сала алмыйбыз, ник дигәндә, әйтик, бөртекле ашлык бәяләренә бәйле вазгыять хәзер тотрыклы түгел, ә техни-

Фото: Эльвира Абдуллина, Рафкать Билданов

Реклама

ка һәм ягулык-майлау материаллары кыйммәтләнә бара, – дип аңлата Минталип Миңнеханов. – Бу өлкәдә дәүләт ярдәме күрсәтү буенча республика программасына эләгергә өметләнәбез, ул акчалар бик урынлы ярап куяр иде. Гомумән, мин мондый проектларның мөһимлегенә ышанам, һәм аларга төрле югарылыктагы бюджетлардан ярдәм күрсәтелергә, тиеш дип саныйм.

Минталип Миңнехановның авыл хуҗалыгы өлкәсендәге карьерасында төрледән-төрле авырлыклар даими очрап тора. Ләкин кайчак хәтта аек акыл белән дә төшенеп булмый торган, һич саекмас оптимизм, үз җиреңдә яшәп, хезмәт итәргә көчле омтылыш-теләк башкалар инде күптән җиңелгән, кул селтәгән вакытта да аңа төшенкелеккә бирелмәскә, алга барырга ярдәм итә.

Балачакта ул, Кәкре Атау авылында (хәзер Нурлат районы) туып-үскән малай, төзүче булырга хыялланa, ләкин Чистай авыл хуҗалыгы механикасы техникумына укырга керергә туры килә. Минталип Чистайда берничә көн яшәр урын таба алмый интегә, автовокзал янындагы эскәмиядә төн кунып йөри. Ләкин техникумга гариза тапшырган сыйныфташлары арасында бердәнбер ул гына укырга керә.

90 нчы елларда Самара өлкәсендә һәм Татарстандагы зур-зур авыл хуҗалыгы предприятиеләре белән идарә эшендә саллы стаж туплаган ир-атны республиканың бәрәңге җитештерүчеләр ассоциациясенә җитәкче итеп чакыралар. Шактый тиз арада Татарстанда бәрәңге җитештерү күләмен арттыруга ирешәләр, икенче икмәкне Мәскәүгә һәм Мәскәү өлкәсенә җибәрүне җайга салалар. Шул рәвешле авыр кризис шартларында авыл халкы хезмәт хакы белән тәэмин ителә. Һәм шунда Казандагы хакимият бер тәкъдим белән чыга – республикадагы эре шәһәрләр тулысынча тәэмин ителмичә торып, бәрәңгене читкә сатуга рөхсәт бирмәскә. Әнә шулай итеп Мәскәүгә дип төягән тулы бер состав бәрәңге юкка чыга. Ә Миңнеханов шәхси эшмәкәрлек юлына китәргә карар кыла.

Шәхси хуҗалыкны аякка бастыру өчен, балаларына дип алынган фатирны, ике гаражны сатарга туры килә. Беренче ике елда техниканы мөмкин кадәр азрак кулланалар. Әйләнә-тирәдәгеләр Минталипка «булдыра алмаячаксың» ди. Ләкин ул чигенми, булдыра. Акрынлап Иске Ерыклы авылында ике ашлык амбары һәм бетон түшәлгән мәйданчык сатып ала. Минталип Исмәгыйлович, орлыкларының кыйммәтлелегенә карамастан, иң сыйфатлы, иң күп уңыш бирергә сәләтле сортларны гына үстерү карарына килә.

– Хәзер безнең 355 гектар җиребез бар, шуның 100 гектары – бәрәңгедә, калганында бөртекледәр игелә. Бәрәңге уңышы – гектарыннан 380, бөртеклеләрнеке гектарыннан 44 центнерга кадәр. Эшне инде гаилә белән генә тартып бара алмыйбыз, яллап эшләтергә дә туры килә. Ләкин яллы хезмәт – һәрвакыт зур җаваплылык ул. Ә без ел саен ниндидер яңа авырлыклар, кыенлыклар белән очрашып торабыз. Менә ашлык бәясе төште, һәм аның азмы-күпме керемләрәк югарылыкка күтәрелерме-юкмы икәнлеге билгесез…

Әле шул ук вакытта уңышны үстереп җыеп алу гына җитми, аны урнаштырырга да кирәк.

– Монда проблемалар һәркемдә бер чамарак. Без кибет челтәрләре белән эш йөртергә тырышып карадык. Алар иң түбән хактан бераз гына югарырак бәя тәкъдим итә, ләкин шуның һәрбәренә мин бихисап күп шартларга ризалашырга тиеш. Карышып маташу файдасыз, зур кибет челтәрләренә, асылда, аерма юк, алар чит ил җитештерүчеләренә яки элекке БДБ илләрендәге яшелчә үстерүчеләргә өстенлек бирә. Әмма шулай да бердәнбер көнне яңа санкцияләр бөтен импортны ябып куярга мөмкин, дип күз алдына китерегез әле. Ул чакта җирле авыл хуҗалыгы продукциясе җитмәскә дә мөмкин бит, чөнки һәркем никадәр сата алачагына ышана, шулкадәр күләмдә үстерергә тырыша. Ә фермерлар җирне бөтенләй ташлап китсә, авыл нишләр? – дип уйлана Минталип Миңнеханов.

Бәрәңге уңышының чирегенә якынын балалар бакчалары, мәктәпләр, хастаханәләр алып китә. Калганын фермер күпләп сатып алучыларга арзан бәядән озата. Табыш артыннан кумыйм, ди ул.

Инде менә күп еллар аңа, үз-үзләрен аямыйча, гаиләсе – хатыны, балалары ярдәм итә. Миңнехановлар – чып-чын фермерлар династиясе ул. 68 яшендә дә Минталип агай гел басу-кырда хезмәт куя, комбайн иярләгәненә дә унсигез ел – бөртекле ашлык уңышын җыю белән үзе шөгыльләнә. Җәмәгате Рәмзия КФХ эшчеләрен кайнар ризык белән тәэмин итә. Берничә югары белем алган балалары да хуҗалыкта эшли. Кызлары Лилия – баш бухгалтер, икътисадый һәм юридик мәсьәләләр – аның карамагында. Уллары Рәмис төзелеш белән шөгыльләнә, базаны киңәйтү, җитештерүне үстерү эшен җитәкли. Күптән түгел Миңнехановлар компьютер идарәле, автоматлаштырылган бәрәңге җыю комбайны сатып алган. Аны да Рәмис иярли. Җәен конвейерда оныклары Айдар һәм КФУның юридик факультетында беренче курста белем алучы Аделия булыша. Айдар быел мәктәп тәмамлый, тик инде хәзер үк комбайнчы ярдәмчесе булып эшләү серләрен белә.

– Гаиләм белән бик горурланам. Колачлы һәм катлаулы эшкә алынган кеше өчен гаилә – иң мөһим нәрсә. Иртәмесоңмы, проблемаларың белән күзгә-күз каласың, һәм шул чакта бары тик якын кешеләрең генә чын-чынлап таяныч була ала, – дип сөйли фермер. – Гомерем буе булдырган бар нәрсәне балаларыма һәм оныкларыма тапшырып калдырасым килә. Династия булганда, кемдер өчен тырышлыгыңны, көчеңне салып, киләчәккә кертемнәр ясап, кайсыдыр бер юнәлештә үсәр өчен максат-өметең бар дигән сүз. Һәр кылган эшеңдә тирән мәгънә барлыкка килә. Һәр фермер бу хакта уйларга тиештер дип саныйм.

КЫР **УҢГАННАРЫ**

Басу читендә бер-бер артлы тезелешеп килгән комбайннарны һәм алар артыннан баручы йөк машиналарын күзәтәбез. Эш тыгыз чакта (күзгә күннең минуты да кадерле!), механизаторның да, машина йөртүченең дә бер минут та вакыты булмаганда килдек. Игенчеләр, артыгын сөйләп тормыйча, үз тормышларын бер җөмләгә сыйдыра: «Монда тудым, монда үстем, укыдым, эшлим». Алар рекорд артыннан кумый, бәлки «урып-җыю» дип аталган әлеге урак өстендә онытылып торган гаиләләрен мул тормышта яшәтү өчен тырыша.

“ – ТУГАН ҖИРЕМДӘ ЭШЛӘЯЧӘКМЕН

Чирмешән районы «ИЛЬХАН» ЖЧҖндә механизатор Сафиннар кимендә икәү – атасы һәм улы. Безгә кичерәге – Айрат кирәк. Аны күрер өчен Югары Кәминкә авылы янындагы зур басуны урарга туры килде. Егет бүген үзенең Class комбайнында арпа суктыра. Җәй коры килгәнгә, сабаклар биек түгел, шуңа күрә комбайнчылар, урып-җыю вакытында ювелирларча эш йөртеп, игеннең бөртеген дә югалтмаска тырыша. Алар уңышның күләме куйган хезмәтнең сыйфатыннан да торуын яхшы аңлый.

Уңыш җыеп алынган кыр тыгыз сары келәмне хәтерләтә: сабаклар тәбәнәк итеп кырып алынган. Комбайнчының осталыгын машинадан төшкәч күрәбез: җир өстендә якынча 10 сантиметр биеклектә урылган кыр кала. Айратны, яшьлегенә карамастан, төпле, булдыклы булуы өчен хөрмәт итәләр. Үзе ул, елмаеп, этисеннән үрнәк алуы турында сөйли:

– Ул һәрвакыт нәрсәдер ясый, ремонтлый. Кырга эти белән 15 яшемнән чыктым. Башта аның ярдәмчесе булып йөрдем. Бөтен нәрсәгә эти өйрәтте.

Яшь комбайнчы 22дә генә әле. Ләкин, аның сүзләренә караганда, гомеренең зур өлешен басуда этисенең кул астында үткәргәндә профессиональ дәрәҗәсенә үсүнең әллә ни авырлыгы юк. Айрат инде аграр техникумны тәмамларга, армия сафларында хезмәт итәргә дә өлгергән. Хәзер мөстәкыйль эшли, алай гына да түгел, аның үзенең ярдәмчесе бар – Илдар Тукаев. Иртә таңнан кояш баеганга кадәр кырда эшләгәннән соң, егетләр өйләренә кайтып, эти-әниләренә булышырга да көч табалар. Кичләрен кызлар янына да барырга өлгерәләр – яшьлек бит...

– Авылда яшьләргә күңелсез, дибез, карьера үсеше дә юк, – дим.

– Алай булса, авылга кайтмас идем. Карьера? – ди Айрат, елмаеп. – Бөтен кешегә Казанда офиста утырырга димәгән бит. Мин үз юлымны сайладым инде. Авылда яшәп, җирдә эшләячәкмен. Техника яңа, шәп, акыллы, ә иң мөһиме – ышанычлы. Мондый техника белән эшләү рәхәт кенә түгел, файдалы да, ватыла калса – вак-төяк кенә. Үзем дә ремонтлап куя алам. Тик торырга вакыт юк, тик торуның югалтулары да зур – хуҗалык өчен дә, үзем өчен дә, аңлыйсыздыр. Кондиционер, борт компьютеры – машина уңайлы эш өчен бар нәрсә белән җиһазландырылган. Бүген авылда матур итеп эшләргә дә, яшәргә дә була, ышаныгыз. Шәһәр тормышы, бәлки, яхшырак-уңайлырактыр, әмма анда яшәү генә тамак туйдырмый. Армиягә дә авылдан киттем, һәм кайтканда мине монда эшем көтеп торачагына ышана идем. Менә сезнең шәһәрнең кай ягы яхшырак? Кая карама – ызы-зыгы. Ә без икмәк үстерәбез.

Автор:
Алсу Троицкая



Фото: Александр Гайнетдинов

“

– НОРМАЛЬ ЭШ ҺӘРВАКЫТ БАР

Әтнә муниципаль районы «ТАҢ» авыл хуҗалыгы кооперативында, кукуруздан тыш, бөртеклеләрне урып-җыю тәмамланган диярлек була. Әтнә игенчеләре, гектарыннан 33,2 центнер уңыш җыеп алып, республика күләмендә икенче урынны ныклап тотып торалар. Монда Таң» хезмәтчәннәренең өлеше дә зур. Без килгәндә алар эшләп тузанга баткан комбайннарын паркка китерделәр – «су процедураларына» әзерлиләр. Алар арасында хуҗалыкта урып-җыю буенча беренчелекне тоткан Илгиз Әкбаров комбайны да бар. Хуҗалыкның уртак уңышында аның өлеше 1750 тоннадан артык – гомуми санның биштән береннән артыгын тәшкил итә.

Камераны күргә, алдынгы комбайнчы әкрен генә:

– Вакытымны ремонтка уздырсам, яхшырак булыр иде, – дип куйды.

Башкалар, шау-гөр килеп, ул арада аны берничә минутка гына «Татарстан» журналының «фотомоделе» булырга кыстыйлар. Шул арада ял итеп алырга да була, югыйсә.

Илгиз Чембулат авылында яши икән. Күрше авыл гына. Авылда мәктәпне тәмамлаганнан соң, берничә ел тракторда эшләп ала. Аннан соң армия сафларында хезмәт итеп, туган колхозына әйләнеп кайта:

– Нинди генә тракторда эшләмәдем: «ДТ», «Беларус», «АТЗ»... Аннан комбайнга күчтем. Соңгы ун сезонда комбайн штурвалы артында утырам. «Палессе» комбайнында – дүртенче елым. Бөтенләй яңа машина алдым. Техника бер кулда гына булгач әйбәт ул. Җитешмәгән яклары була икән – үзеңнеке. Әлегә зарланырлыгы юк. Техник яктан, ихтимал, чит илдән кертелгәннәрдән калыша торгандыр, әмма уңайлылыгы буенча – юк, – ди ул.

– Бу комбайн хатын-кыз кебек игътибарны күбрәк таләп итә, – дип төгәллек кертәләр Илгизнең хезмәттәшләре.

– Берүзем, ярдәмчесез эшлим. Менә минем ярдәмчем – кабинада урнаштырылган компьютер. Эшемә вакытында һәм яхшы түлиләр. Үз хезмәтең өчен нормаль хезмәт хакы аласыңны, тикмәгә генә эшләмәвеңне белеп тору бик әйбәт. Хәзер август өчен 131 мең сум алачакмын. Тиздән бөртеккә кукуруз җыярга керешергә тиешбез, ә аннан соң, һәрвакыттагыча, «КАМАЗ»га күчеп утырырга исәп. Авылда эш һәрвакыт бар. Нормаль эш. Эшлисе һәм акча аласы килгән кеше өчен.



“

– АВЫЛДА БЕР КӨН БЕЛӘН ЯШӘМИЛӘР

Татарстанның атказанган механизаторы Исхак Нәҗипов белән без Яңа Чишмә районындагы Красный Октябрь поселогында урнашкан «Кулон» агрофирмасы кырларында очраштык. Урып-җыю чорында ул комбайнчы булып эшли, сезон ябылганнан соң – автослесарь. Аның тормышын шулай ук «үстерергә», «җыеп алырга», «сакларга» дигән сүзләрдән башка күз алдына китереп булмый... Барыбызга да яхшы таныш «Трын-трава» дип аталган совет кинофильмы кадрларын җанландыргандай, сүзгә кушыла:

– Элек ничек иде бит? Комбайн кабинасында эссе, ашлык кибәге биткә сылана, кием астына кереп кычыттыра, тузан арасыннан күзләр белән тешләр генә ялтырап күренеп тора. Эш көне тәмамланганда әниең дә танымаслык хәлгә киләсең. Ә хәзер менә минем «Акрос 580» комбайнын гына карагыз, рәхим ит – менә дигән күз күреме, кондиционер, бер кулың рульдә, икенчесе джойстикта – әкият бит, җиңел машина йөрткән кебек. Ак футболка киеп эшләргә була. Шулай да эшебезне җиңел үк дип әйтү бигүк дөрес булмас. Авыр. Менә бүген ярдәмчесез эшлим, мәктәптә укулар башланды чөнки. Берүземә генә эшләргә туры килә, тик түзәбез. Ну, мактанасым килми инде килүен... Ни дисәң дә, тәҗрибәм шактый зур. Урып-җыю вакытында 2–3 сәгать кенә йокларга туры килә. Торып чыгып киткәндә, өйдәгеләр әле йоклый, кайтканда инде яткан булалар, – дип елмая комбайнчы. – Әлегә менә икмәк өсте, бөртеклеләрне урып-җыябыз, ә ноябрь уртасына кадәр көнбагыш белән кукурузны җыеп аласы бар, шәхси хуҗалыкны хатыным алып бара, аңа рәхмәт – өйдәге бар эш аның җилкәсендә. Мин бу хуҗалыкта гомерем буе эшлим дияргә була. Мәктәптә укыганда ук Аксубай филиалында комбайнчы ярдәмчесе булып эшли башлаган идем. Гомерем буе – руль артында. «Нива», «Дон», «Нью Холланд», «Мега» комбайннарында эшләдем, менә хәзер – «Акрос»та.

Сезонына карап, 3 мең тонна икмәк урган чаклар да була. Бу ел узган еллар белән чагыштырганда начаррак килде, әмма зыян юк, киләсе елга куып тотармын, дип уйлыйм.

Мактаулы исемне нәрсә өчен бирделәр, дигән сорауга болай дип җавап бирде:

– Башкаларга караганда бераз яхшырак эшләгәнмендер, бәлки.

Аны бүтән хуҗалыкларга да чакырып карыйлар – булдыклы, ышанычлы механизатор кайда да кирәк. Акчасын да күбрәкне, хезмәт шартларын да яхшыракны вәгъдә итәләр. Нефтьчеләр янына да китәргә була, эш табу проблема түгел. Ләкин, комбайнчы сүзләренә караганда, күктәге торнага ышанып, бер көн белән яшәгәнче, булганның кадерен белү яхшырак:

– Авылда алай яшәмиләр, бер урыннан икенче урынга сикереп йөрү холкыма да туры килми. Пенсиягә дә озак калмады инде, әлбәттә, беркая да китмим. Авыл хуҗалыгы механизаторларына пенсиягә чыгу яшен арттырмаска вәгъдә итәләр, дип тә ишеттем. Менә шуннан белегез инде: авыр хезмәтме бу, җиңелме. Миңа үз эшем ошый. Яратмасам, күпме еллар биредә эшләмәс идем. Бәлки, ышанмассыз да, әмма иртән торуга, басуга чыгасы килә! Бункерга агып төшә торган ашлык тавышы гына да ни тора!..

“

– БЕРКЕМНӘН ДӘ КӨНЛӘШМӘС ӨЧЕН, ҮЗЕҢ ЭШЛӘ

«Кузангай» ҖЧҖнең «Чистай» Халык предприятиесе» комбайнчысы Фәргать Миңгалимов, иптәшләре белән бергә, бер кырда урып-җыюны тәмамлап, күрше басуга күчәргә җыена:

– Иртәгә сәгать ярым эчендә тәмамларга тиешбез. Сөенеп бетә алмыйбыз – урып-җыю вакытында быел һава торышы безнең яклы. Иртән торуга шатланам – көн бүген дә кояшлы, коры. Эшлә генә рәхәтләнеп! Тик торулар, җимерелүләр юк. Бар техника яңа, вагынтөяген ремонтласаң гына. Кичә кырга район башлыгы үзе килде, алдынгыларны котлады.

Мин үзем авылда туып-үстем, моннан ерак түгел, турыдан тугыз чакрымнарга җыела. Кышын, урап кайтканда – илле чакрымлар тирәсе. Дүрт Өйле дип атала. Бала чагымнан ир-атларның кырда эшләгәнен күреп үстем, ошады. Ул заманнарда урак өстендә бөтен малайлар комбайнчы ярдәмчесе булып эшлиләр иде.

Фәргать авыл тормышын сайлый. Озак еллар терлекчелектә хезмәт итә, эшеннән кыскартылгач, нәрсә эшләргә, кай якка юнәлергә, дип уйга кала. Уйлый торгач, яңадан комбайн штурвалы артына утыра:

– Гаиләне туйдыру минем өстә, дүрт бала үстерәбез. Яшь чакларны искә төшерергә туры килде, – дип елмая комбайнчы. – Шулай килеп чыкканга, бер дә үкенмим!

Әлеге хуҗалыкта Фәргатьнең хезмәт хакы башка комбайнчыларныкы кебек үк – эш башыннан, күпме эшләвеңә карап.

– Барысы да бик гади һәм дөрес: күпме икмәк урасың, шулкадәр хакын да аласың. Менә сиңа комбайн, ашлык һәм хезмәт хакы. Начар эшләү мөмкин түгел, файдалы түгел. Акча бит ул, өстәвенә, яхшы акчалар. Бер тонна җыеп алынган икмәк өчен – 90 сум. Машинага ягулык салалар, төшке-кичке аш белән сыйлыйлар, техника заманча. Кай җире начар? Узган атнада кече улымны алып килдем – комбайнымны күрсәтергә, аңа ноябрьдә биш яшь тула. Көне буе минем белән йөрде, тыны да чыкмады. Аннан авылда мактанган да әле, – дип көлә Фәргать.

Сезонны тәгәлләүгә, Фәргать тә, башка комбайнчылар да икенче эшкә тотына: кемдер – автослесарь, кемдер – токарь, кемдер – тракторист. Техниканы киләсе елга әзерли башлыйлар. Хезмәт хакы бу вакытта урып-җыю чорындагыга караганда, әлбәттә, кимрәк чыга, әмма гаиләнең тамагын туйдырырга җитә. Авылда бит, комбайнчыларның сүзләренә караганда, ихаталарында терлек-туар, кош-корт тотмаган кеше юк диярлек:

– Хатыным белән 5 сыер асрыйбыз. Ничек инде авылда яшәп, мал-туар асрамыйсың ди? Гөнаһ булыр! Мул тормышта яшисең килә икән – хезмәт ит! Беркемнән дә көнләшмәслек итеп яшә. Югыйсә, һәрвакыт үз тормышыңнан канәгать булмаячаксың! Т


Фото: Александр Гайну

4 4



УҢЫШ КӘРҖИНЕ

Сентябрь елның иң мул аедыр. Юкка гына бабаларыбыз: «Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер», – димәгән бит. Инде игеннәр җыелып, амбарларга кереп урнашты. Хуҗалыклар да бәрәңге, яшелчә уңышын алып бетерде. Ә аерым фермерлар, зур-зур агрохуҗалыклар басуында әле икенче икмәк, ягъни бәрәңгене, гомумән яшелчәләрне җыю эше дәвам итә.

Автор:
Руфия Фазылова

Бүген без соңгылары турында язарга булдык. Татарстанда яшелчә, җиләк-җимеш үстерүче берничә эре ширкәт бар. Алар ярты республиканы туйдыра. Биредә яшелчә, җиләк-җимеш үстерү ничек оештырылган, шуны күзәтеп, нәтиҗә ясадык.

Колачларга тырышкан тагын бер тема – алма бакчалары. Советлар Союзы чорында күкрәп үскән алма бакчалары бүген ташландык хәлдә. Аларның киләчәге нинди булачак? Кибет, базарларда үзебездә үскән алма бармы? Шушы һәм башка сорауларга җавап эзләдек.

БЕЗГӘ ҮЗЕБЕЗНЕКЕ... ҖИТӘ?

Санкцияләр белән бәйле, чит илдән җиләк-җимеш, яшелчә кертү чикләнгәч, дәүләт җитәкчеләре, аларны үзебездә үстерергә кирәклеген даими рәвештә ассызыклый башлады. Россия Премьер-министры Дмитрий Медведев быел да төбәкләрдә яшелчә, җиләк-җимеш үстерү буенча махсус программа эшләргә, бу эшне җайларга кушты.

Бер карасаң, Татарстанда башка төбәкләр белән чагыштырганда хәл уңайрак. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан алынган мәгълүматларга нигезләнсәк, Идел буе федераль округы төбәкләре арасында Татарстан ачык грунтта үстерелгән яшелчә мәйданнары буенча 3 нче урында тора. Шул ук министрлыкның җавабыннан күренгәнчә, республикада үскән яшелчә җирле халыкны туендырырга тулысынча җитә.

Быел Татарстанда яшелчә утыртылган гомуми мәйдан 2,4 мең гектарны тәшкил итә. (Тик монда бәрәңге культурасы кермәгән. Ул аерым бара, бу хакта соңрак). Шуларның 780 гектарында – кәбестә, 850 гектарында – кызыл чөгендер, 436 гектарында – кишер һәм 160 гектарда башлы суган үстерелә. Иң алдынгы рәттә – Арча муниципаль районы. (Бу район бәрәңге үстерү буенча да исемлекнең беренче урынында тора.) Белгечләр фикеренчә, Россия Федерациясенә каршы кертелгән санкцияләр авыл хуҗалыгы товары җитештерүчеләренә (җиләк-җимеш юнәлешендә дә) үсәргә мөмкинлек биргән. Һәрхәлдә, төбәкләрдә бу аермачык сизелә. Ел саен, ТР Министрлар Кабинеты карары нигезендә, федераль һәм төбәк бюджетларыннан җиләк-җимеш бакчалары утыртучы хуҗалыкларга субсидия бирелә. Аның суммасы – 50 меңнән алып 300 меңгә кадәр.

Тагын бер уңай күренеш – көзен һәм язын ярминкәләр оештырыла. Россиянең башка күп төбәкләрендә дә шулай ул. Ә ярминкә ике як – сатучы һәм сатып алучы өчен дә файдалы. (Быел Татарстанда 15 сентябрьдән башланып китте ул.) Отыш шунда: арадашчылар юк. Димәк, товарның бәясе дә, сыйфаты да (ул бит бакчадан, басудан туры ярминкәгә килә) ике як өчен дә кулай. Менә шуңа да шәһәр халкы кышлык яшелчәне, аерым җиләк-җимешне ярминкәдән алып калырга тырыша.

– Яшелчәләрне агрофирманың Яр Чаллы бүлегеннән сакларга дип кайтардылар, – диде Гөлсирә Ваһапова.

Фото: Александр Ефремов

АЛЫП БАРА, ЛӘКИН АЛЫП КАЙТМЫЙ...

Бу мәгълүм мәзәкне бәрәңгегә карата әйтәләр: «Миңа бик ышанма, алып барам, тик алып кайтмыйм», – дигән имеш. Тик «алып кайтмаса» да сугыш чорында халыкны ачлыктан бәрәңге коткарган. Бүген Татарстанда 2 мең гектардан артык мәйданда бәрәңге үсә. Лидерлар рәтендә – Арча районы. «Сервис-Агро» җәмгыятенең «Кырлай» һәм «Игенче» бүлекчәләрендә 1 мең 200 гектар җирдә бәрәңге игелә. 19 сентябрьгә мәйданның яртысы җыелып, саклауга куелган иде. Уңыш – яхшы гына түгел, рекордлы!

– Әлбәттә, эшне тулысынча тәмамламыйча, нәтиҗәләр турында әйтергә иртәрәк, – диде компаниянең баш агрономы Алмаз Сабиров. – Шулай да әлегә кадәр җыеп алынган уңыш буенча шунысы анык: безнең хуҗалыкта әле моның кадәр бәрәңге булганы юк иде. Гектарыннан уртача 410 центнер уңыш чыга. Узган ел бу сан 370 центнер булды.

Быел, чынлап та, бәрәңге уңышы хуҗалыкларда мул. Баш агроном моның сәбәбен берничә факторга бәйләде:

– Беренчедән, июнь, июль әллә ни эссе булмады. Юк дисәк тә, яңгырлар да яуды. Бәрәңге бик эссе елны яратмый, быел һава шартлары «мач» килде.

«Агро-сервис» оешмасында бәрәңге мәйданы бүленгән. Бер кырда «товар бәрәңге», икенчесендә «үсенте», ягъни чәчүлек бәрәңге үсә.

– Бәрәңгенең «Гала», «Королева Анна», «Ред Скарлет» төрләренә өстенлек бирдек, – диде агроном. – Төрле сортлар үстереп карадык. Безнең һава шартлары өчен менә шулар әйбәт дигән нәтиҗәгә килдек. Һәр өлкәдә яңалыклар кергән кебек, авыл хуҗалыгы тармагында да яңадан-яңа яшелчә сортлары барлыкка килә. Бәрәңге мәсьәләсендә дә шулай. Без бәрәңге үстерү буенча яңа алымнар кулланырга, яңа сортлар алып кайтырга тырышабыз.

Яңалык дигәннән, Алмаз Сабиров бер «сер» ачты: бактың исә алар кортка агу сипми икән. Сәбәбе бик гади:

– Әз бәрәңгене агулап утыртабыз, – ди баш агроном. – Нәтиҗәдә, бәрәңге тишелеп чыгуга ана корт аның үсентесен ашый да һәлак була. Колорадо корты «чылбыр реакциясе» белән үсә бит: башта ана корт күкәй сала, аннан балалар чыга. Нигездә, бәрәңгенең яфрагын корт балалары ашый. Ә монда ул күкәй салырга өлгерми кала.

– Агулап утырткан бәрәңге сәламәтлекккә зыянлы түгелме соң? – дим.

Белгеч баш кына какты:

– Нишләптер кешеләрдә ялгыш фикер яши: янәсе хуҗалык бәрәңгесенә караганда фермерларныкы күбрәк агулы. Зур ялгыш. Барысы да бик гади: бәрәңгене агулап җир астына күмгәннән соң, 35 көннән аның зарарлы матдәләре чыгып бетә. Ә бу вакытта бәрәңге әле яралып кына килә торган була. Димәк, зыяны бөтенләй калмый. Ә хуҗалыклар ничек эшли: бәрәңге тишелеп, чәчәк ата башлагач, кортка каршы агу сибә. Колорадо коңгызы-

PRESSA

– Былтыр алмалар биредә март аена кадәр торды, – ди склад мөдире Тамара Белоусова.

ның үрчегән вакыты нәкъ шул чорга туры килә. Ләкин ана корт барыбер кала, нәтиҗәдә ул яңадан күкәй сала. Кешеләр бәрәңгене янә агулый. Бу август башы да булырга мөмкин. Шуннан соң өч-дүрт атнадан бәрәңге алырга чыгалар. Ә агу тулысынча бәрәңгедән чыгып бетсен өчен 35 көн вакыт кирәк.

Бәрәңгене агулап утыртуның икенче файдалы ягы да бар: сибүче кешегә зыяны булмый. (Ни дисәң дә, сипкәндә зарарлы матдәләр авыз-борын, күзгә дә керә). Гадәттә, хуҗалыклар арт бакчасына сыер-бозавын, тавык-чебешен дә ябып куя. Димәк, бәрәңге агулаганда аларга да зарарлы матдәләр җил белән очып барып тияргә мөмкин.

Җәмгыятьтә бүген эшнең иң тыгыз мәле: бер төркем эшчеләр (мәктәп укучылары, студентлар да килә) бәрәңгене кырдан җыеп ала. Икенчеләре амбардан сеткаларга тутыра...

– Сентябрьнең җылы, кояшлы килүе безнең өчен янә бер бүләк, – ди Алмаз Сабиров. – Кайбер елны бәрәңге вак була, җыеп алырга һава шартлары да туры килми. Быел барысы да туры килде. Бәхет басты!

ХУҖАСЫЗ БАКЧА?!

Һәр районда диярлек ташландык бакчалар бар. Совет чорында анда яшелчә, җиләк-җимеш үскән. Ләкин система җимерелүгә, алар берәүгә дә кирәксез булып, ташландык хәлгә килде. Кәбестә, кишер басуларында котырып алабута үсеп утыра, ә алмагач, карлыган бакчалары корып, үзләрен кычыткан, «шайтан таягы» басты. Дөрес, барысын да димим, әмма ташландык бакчалар бездә шактый. (Аның төгәл санын исәпкә алучы да юк булып чыкты хәтта).

– Ташландык бакчаларны яңадан торгызырга план юкмы? – дип ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына рәсми хат юллаган идек. Менә нинди җавап килде:

– Алмагач бакчаларының җимеш бирү чоры чикләнгән: 20–25 ел. Дөрес тәрбияләгән очракта бакча 30 елга кадәр җимеш бирергә мөмкин. Ташландык бакчаларны төпләү, тәртипкә китерү бик кыйммәт булу сәбәпле, яңа мәйданнарда бакча утырту арзанрак чыга. Дәүләт тарафыннан 30 ел элек һәм алданрак булдырылган иске бакчаларны торгызуга ярдәм каралган. Тик бакчаларның төпләнгән елын һәм хуҗасын билгеләп булмау сәбәпле, бирелгән ярдәмне куллану да мөмкин булмады.

Гади генә итеп аңлатканда, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, кулына документ тотып: «Менә мин бу бакчаның хуҗасы, аны торгызырга телим», – дип килгән кеше булмаган. Кайчандыр дәүләтнеке саналган бакчалар, үзгәртеп кору чорында, аерым кешеләргә, агрофирмаларга бүлеп рәсмиләштерелгән. Ә хуҗаларга исә ул бакча кирәк түгел, беттекитте! Шулай булгач, бакчаларның кайчанга кадәр берәүгә дә кирәксез булып ятачагы да билгесез. Ни кызганыч...

Аның каравы, яңа бакчалар үстерергә теләүче тырыш кешеләр табылган. 2017 елда, интенсив бакчалар салу проекты нигезендә, Буа районыннан Дәүләтшин хуҗалыгына 8 гектар, Чүпрәле районыннан Хәйруллинга 11 гектар, Мамадыш районыннан Мостафин хуҗалыгына 30 гектар алмагач бакчалары утырту өчен субсидия бирелгән. Алар барысы да крестьян-фермерлык хуҗалыгы булып теркәлгән. Агымдагы елның язгы чорында Мамадыш районының Писцов крестьян-хуҗалыгы 40 гектар алмагач бакчасы утырткан. Көзге чорда тагын 90 гектар алмагач бакчалары утырту ниятләнә. Республикада җиләк-җимеш куаклары (кура җиләге, карлыган, крыжовник) мәйданнары да арта икән.

АЛМАЛАРЫ, ЧИЯЛӘРЕ...

Республикада иң зур җиләк-җимеш бакчалары – Югары Ослан районының «Заря» агрофирмасында. Ямбулат авыл җирлегенә карый ул. Бакчаларның гомуми мәйданы 432 гектар, шуларның 265 гектары җиләк-җимеш бирә. 2017 елда бу мәйданнарда 4 мең тоннадан артык уңыш җыеп алынган. Бүгенге көндә җыелган уңыш 400 тоннадан артык. Шуларның 97 тоннасы – алма белән груша, 11 тонна – төшле культура, 287 тонна – җиләк.

– Быел алма, груша уңышы узган елның яртысы кадәр дә юк, – диделәр «Заря» агрофирмасында. Алмагач бер ел алма бирә, икенче елны ял итә бит. Чия дә шулайрак. Аның каравы, кура җиләге әйбәт булган.

Без килгәндә биредә «урак өсте» иде: яшелчә, җиләк-җимешне Казанга әзерләп ятулары. Атна

БЕЛЕШМӘ МӘГЪЛҮМАТ:

«2018 елда агросәнәгать комплексында дәүләт ярдәме чаралары турында» (ТР МКның 17.01.2018 елгы 17 нче) карары нигезендә, хуҗалыкларга гомуми чыгымның 80 проценты күләмендә субсидия каралган. Бу – 1 гектарлы традицион бакчаларга 50 мең сумнан артык түгел, ә интенсив типтагы бакчаларга 1 гектарга 300 мең сумнан артык түгел.

саен өч-дүрт «КАМАЗ» машинасы ярминкәгә бара. Яшелчәләрне күз йомганчы алып бетерәләр икән. (Җәен җиләк-җимеш тә тиз сатылып беткән.)

– Бирегә тамыразыклар да үстерәсезме әллә? – дим яшелчә складында бәрәңге аралап ятучы ханымга.

– Юк, моны агрофирманың Яр Чаллы бүлегеннән сакларга дип кайтардылар, – диде Гөлсирә Ваһапова. Ул биредә хисапчы булып эшли икән. Тик ярминкәгә әзерләнергә кирәк булганлыктан, кәгазь эшен куеп торырга туры килгән.

– Тамыразыклар биредә узган ел язгы ярминкәләргә кадәр торды, – ди Гөлсирә ханым. – Быел бәрәңге, кишер уңышы әйбәт, яшелчәләр узган елга караганда күбрәк булыр, дип уйлыйм.

«Заря» агрофирмасында узган ел мең тонна яшелчә сыйдырышлы склад эшләгәннәр. Ике яклы ул: берсендә алмалар, икенчесендә кишер, бәрәңге, чөгендер кебек тамыразыклар саклана. Склад мөдире Тамара Белоусова алмалар саклана торган якка алып керде:

– Былтыр алмалар биредә март аена кадәр торды, – дип сөйләп китте ул. – Әлегә без складны җылытмыйбыз. Урамда температура минуска кадәр төшкәч, махсус электр мичен кабызабыз. Алма өчен иң яхшы температура – плюс ике градус.

– Алмалар кышка кадәр череп бетмиме? – дим.

– Узган ел әйбәт сакланды. Әлбәттә, без агач әрҗәләрне даими рәвештә тикшереп, карала башлаган алмаларны алып торабыз.

– Ә бәлки сез аларны берәр химикат белән эшкәртәсездер?

– Юк, басудан ничек кайтса, шулай складка керә. Аннан аерып, кәгазь әрҗәләргә салабыз. Быел алма уңышы начар булды, бәлки көзге ярминкәләрдә сатылып та бетәр әле.

Агрофирманың җиләк-җимеш үсә торган бакчаларын карап чыктык. Гаҗәп зур ул. Алма, груша, «виктория», кура җиләге, чия, карлыган, кара миләш – барысы да аерым утыртылган. Соңгысының уңышын җыеп кына яталар иде. Ямбулат авылында эшче көчләр җитмәгәнлектән, читтән дә кешеләр чакырганнар. Күрше авылдан килгән абый-апалар белән сөйләшеп тордык. Ел саен шулай килеп эшлиләр икән:

– Март аеннан эшли башлыйбыз, – диделәр. – Башта бакчаларны чистартабыз, агачларны корыган ботаклардан арындырабыз. Аннан җир эшкәртәбез. Шуннан җиләк, карлыган, чия, алма җыябыз. Бер-берсенә тоташып китә ул. Кара көзгә кадәр эш бетми…

Яздан көзгә кадәр бакчада эшләр өчен 30–40 кеше кирәк. Хезмәт хакы көнләп бара, 1100 сум. Эшчеләр өчен махсус тулай торак салганнар. Читтән килүчеләр шунда бушка яшәп, бушка туклана.

– Агрофирма үз хисабына 10 йорт салдырды, – диде Ямбулат авылы җирлеге башлыгы Марсель Әхмәтҗанов. – Яшь гаиләләр бирегә килеп төпләнсен, диләр. Тырыш кешегә авылда эш һәрвакыт бар. Монда элеккеге колхоз системасы кебек: агрофирма авыл юлын да, суны да карый. Тырыш кешеләргә Ямбулат яшәр өчен менә дигән урын. Казан да ерак түгел…

…Язманы тагын башка мисаллар белән дә дәвам итәргә булыр иде, әмма озынга китә. Әйтәсе килгән фикер шул: теләк булганда, яшелчә, җиләк-җимешне безнең шартларда рәхәтләнеп үстереп була. Сатып алучы да, әллә каян китерелгән җиләк-җимешкә караганда, үзебездә үскәнне алырга тырыша. Шулай булгач, бу юнәлештә эшләргә дә эшләргә безгә. Һәрьяклап отышлы бит: эш урыннары да бар, кулланучы экологик чиста азык-төлек ашый һ.б.



ТАТАРСТАН
Татарстан

Редакция кухнясы

УКЫТУЧЫЛАР КОМПАНИЯСЕНДӘ – КИЧКЕ АШ

Автор:
Руфия Фазылова

Сентябрь узып бара. Ә димәк инде көз иркенләп тәхетенә менеп утырды. Күренә дә: агачлар көннән-көн саргая, сизелерлек итеп суытты. Көзнең тагын бер билгесе – букчаларын асып мәктәп укучылары белем алырга китте. Ата-аналар әйтмешли, башланды!

Редакциябез кухнясында да көз «билгеләре» чагылсын дидек. Безгә бүген Татарстанның, алай гына да түгел, Россиянең иң яхшы укытучысы, төгәлрәк әйтсәк, «Ел укытучысы – 2017» Бөтенроссия бәйгесе җиңүчесе Алмаз Хәмидуллин ярдәм итә. Талантлы мөгаллим үз рецепты белән тутырылган татлы борыч пешереп күрсәтте.

«ЯШЕЛЧӘЛӘРГӘ ӨСТЕНЛЕК БИРӘМ»

Бу юлы редакциябез кухнясын бизәгән Алмаз Нуретдинович үзенең пөхтәлеге, булдыклылыгы, төгәллеге белән таң калдырды. Идәнгә ник бер яшелчә кисәге, чүп төшерсен. Тураган яшелчәләре линейка белән үлчәгән кебек – тип-тигез. Математиклыгы монда да чагыла.

Талантлы мөгаллим белән 2нче лицей-интернат ашханәсендә очраштык. Ул әлеге белем үзәгендә математика фәне укыта. Икенче елын гына эшләсә дә, коллективта зур абруй, ярату казанган. Укучылары турында әйтмим дә!

– Аш-су белән дуслыгыгыз ничек? Өйдә берәр нәрсә әзерлисезме? – дим мөгаллимгә.

– Бик яратып! – ди ул, елмаеп. – Бөтен ризыкларны да пешерә беләм. Мәскәү дәүләт университетында укыганда тулай торакта бәлешләр, өчпочмаклар да ясый идем. Төрле милләт студентлары арасында аш-су пешерү ярышлары да оештырып йөрдем. Һәр милләт егет-кызы үзләренең ризыкларын пешереп, аның әзерләү ысулларын сөйли иде.

Тик хәзер аш-су әзерләү белән бик мавыкмыйм. Вакыт юк. Хатыным пешергәнне ашыйм. Шулай да елларда берәр ят ризык әзерләргә тырышам. Төрек ашлары яратам. Яшелчә, җиләк-җимеш салатларын көн саен ашыйм. Алар файдалы да, тәмле дә.

Алмаз Нуретдинович башта эчлек әзерләргә керeште: кишерне уып, суганны турады да, табага салып, электр плитәсенә куйды. Тоз, борыч өстәде. Шуннан татлы борычларның башын пөхтә итеп кисеп, эчен чистартты.

– Монысы «капкач» булачак, табынга куйганда да матур, – дип, борычның өске өлешен дә куна тактасына тезеп куйды.

Иттарткычтан чыгарылган сыер ите әзер, дөге дә пешкән. Табада кишер белән суган кызганны гына көтәбез. Ул арада «Россиянең «Ел укытучысы – 2017» бәйгесендә иртән төшергән фотоларын күрсәтә:

– Иртәнге биштә коллегам белән велосипедта йөрибез. Бу вакытта Казан аеруча матур була, тынлык... Казансу өстендә томан күтәрелә, шул манзараны фотога да төшерәм, – диде.

АЛМАЗ ХӘМИДУЛЛИННАН ТУТЫРЫЛГАН ТАТЛЫ БОРЫЧ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:
1. Татлы борыч – 2 кг
2. Сыер ите – 1 кг
3. Суган – 2-3 баш
4. Кишер – 2 баш
5. Дөге – 0,5 кг
6. Тоз – чама белән
7. Борыч – чама белән
8. Сыек май – 2 аш кашыгы

Фото: Александр Ефремов

Редакция кухнясы

Талантлы кеше бөтен яктан да талантлы, диләрме әле? Алмаз Нуретдиновичка бу әйтем аеруча туры килә кебек. Көчле укытучы булу өстенә (Моның өчен ул көн саен үз өстендә эшли, тик ул хакта соңрак... – **Авт.**), ныклап футбол, волейбол белән дә шөгыльләнә. Кышка хоккей уйный башларга җыена.

– Мин үз алдыма гел яңа максатлар куям. Аларга ирешмичә туктамыйм, – ди ул.

«КӨЧЛЕ УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ АВЫР»

Кишер белән суган әзер булды. Алмаз Нуретдинович чын пешекчеләрчә эшкә керeште: җәлт кенә күлмәк җиңнәрен сызганып, чыгартылган иткә кишер белән суганны кушып, барысын бергә болгатты. Аннан пешкән дөгене дә кушып, тоз, борыч өстәп янә бутады.

– Ризыгыгыз төче икән, дип әйтә безгә килгән кеше, – дип сүзен дәвам итте мөгаллим. – Без исә иялләнгән. Артык тоз сәламәтлеккә зыянлы. Чәйне дә шикәрсез эчәбез. Аның урынына әнә күбрәк татлы җиләк-җимеш ашыйбыз. Организм өчен кирәкле шикәр күләмен шулай алып була.

Шуннан мөгаллим эчлекне алдан әзерләп куйган борычларга тутырды. Бик иплəп, пөхтә итеп.

– Болай борыч пешергәнегез бар идеме? – дим.

– Әлбәттә. Тиз дә, туклыклы да бит. Майлы, тозлы түгел, «дөрес» ризык.

– Кайберәүләр иткә кушасы дөгене пешереп тормый, кишер, суганны да кыздырмый. Сезнең рецепт үзгәрәк, ахры, – дим.

– Дөгене бүрттереп алгач, тутырылган борычыбыз тизрәк пешә. Ә кыздырылган кишер белән суган эчлекне сусыл, тәмле итә.

Борычларны тутырып, өстенә «капкачын» киерткәч, Алмаз Нуретдинович яшелчәләрне тирән табага тезде. Борычларның яртысы күмелерлек итеп су салды һәм пешерергә куйды.

– Егерме биш минуттан әзер була, – диде.

Ә безнең сөйләшүебезнең исә иң тәмле җире башланды. (Борыч әзерләү белән мәш килгән укытучыны сорауларым белән эшеннән бүлергә базмый торган идем.)

Алмаз Нуретдиновичның 2 нче лицей-интернатта икенче ел гына эшләве. Аңа кадәр алты ел буена Түбән Каманың 24 нче номерлы лицеенда математика укыткан. Мөгаллим үзе дә шул уку йортын тәмамлаган. БДИдан югары балл җыеп, МДУга укырга кергән.

– Югары курсларда укытучы булачагымны төгәл белә идем, – ди мөгаллим. – (Әнисе дә математика укытучысы. – **Авт.**) Шуңа да педагогик курсларларга йөрдем. Мәскәүдә бик дәрәҗәле белем бирү үзәгендә практика үттем. Эшкә дә чакырганнар иде, тик мин туган шәһәремә кайтырга булдым. 24 нче лицей Түбән Каманың иң дәрәҗәле уку йорты булып санала. Директорым чакыргач, каршы килмәдем.

– Алайса сез фәкать сәләтле, акыллы балалар белән генә эшләгәнсез? – дим. (Казан шәһәрендәге 2нче лицей-интернатка да зур сайлап алу конкурслары аша керәләр бит.)

– Әйе. Бәлки бу җиңел кебек тоеладыр: акыллы бала белән эшләү рәхәтрәк кебек. Чынлыкта исә сәләтле укучы белән эшләү бик зур җаваплылык сорый. Алар мәктәп программасын бер җөмләдән үк аңлый, ул материал гына алар өчен аз. Димәк, укучыларның белем дәрәҗәсен тагын да арттыру өчен яңа алымнар кирәк. Син аларга караганда, кем дигәндә, берничә тапкыр күбрәк белергә тиеш. Алар бик күп сораулар бирә. Җавап бирә алмасаң, укучы алдында дәрәҗәң төшә. Ә бу укытучы өчен иң куркынычы.

«БДИ УКУЧЫЛАРГА ЗУР МӨМКИНЛЕКЛӘР АЧТЫ»

2 нче лицей-интернатта малайлар гына белем ала. Элек ул төрек-татар лицее дип аталган. Соңгы елларда «сәләтле балалар өчен лицей» дип йөртелә. Алмаз Нуретдинович алты ел эшләгән Түбән Каманың 24 нче лицее да малайлар өчен генә.

– Кызларны математикага өйрәтеп булмый дип уйлавыгызмы? Ни өчен кыз балаларны да укытмыйсыз? – дим.

– Юк, алай дип һич кенә дә уйламыйм. Кыз балалар арасында да бик көчле математиклар булырга мөмкин. Малайлар гына укый торган белем йортында эшләвемнең сәбәбе: 24 нче лицей – Түбән Камада, 2 нче лицей-интернат Казанда иң яхшысы, минемчә. Шуңа да малайлар белән генә эшләргә туры килә.

– Малайлар белән кызларны аерып укытуга ничек карыйсыз?

– Уңай карыйм. Тик бу бөтен балаларны да аерырга кирәк дигән сүз түгел. Барыбыз да белә: балигълык яшенә җиткәндә кызлар – малайлар, малайлар кызлар белән мавыга башлый. Димәк, игътибарлары укудан читләшә. Нәкъ менә шуннан качу өчен аерым укыту яхшы. Аннан ир-атның холкында узышу, ярышу дигән нәрсә бар. Бергә укыганда, малайлар кызларның игътибарын алу өчен ярыша. Ә гүзәл затлар булмагач, уку өчен ярыша башлый.

Мөгаллимнең тагын бер фикере кызык тоелды. Менә нәрсә ди ул:

– Һәр укучыны да диярлек БДИны кимендә 80 баллга бирерлек итеп әзерләргә була. Бу фәкать укытучыдан тора!

– Ләкин бөтен укытучы да алай уйламый. Сезнең кебек укучылары даими рәвештә 100 балл җыйган мөгаллимнәр һәр мәктәптә юк бит... – дим.

– Килешәм, – ди. – Менә шул юнәлештә эшлибез. Укытучыларны яңача эшләргә өйрәтәсе иде. Без еш кына математика укытучылары белән төрле семинарлар, укулар оештырабыз. Мөгаллимнәр булган тәҗрибәләре белән бүлешергә тиеш. Чит илдә күптән шулай.

Алмаз Нуретдиновичның план, идеяләре искиткеч күп, аларны санап бетерә торган түгел. Мисал өчен, быел җәй көне математика юнәлешендә лагерьлар оештырганнар. БДИ, олимпиадаларга әзерли торган мобиль үзәк эшләгәннәр. Киләчәктә бу юнәлешне тагын да үстерергә җыеналар.

– Укытучының эше мәктәптә дәрес бирү белән генә чикләнергә тиеш түгел, – ди мөгаллим. – Мин, мәсәлән, укучыларым белән кич килеп футбол уйныйм, дусларча аралашам. Проблемалары булса, уртага салып сөйләшәбез. Дәрестән соң аңлашылмаган теманы яңадан аңлатып күрсәтәм. Безнең лицейда укытучыларга репетиторлык белән

шогыльләнү тыела. Һәм мин моны дөрес дип саныйм. Укучы белән укучы арасында акчага корылган мөнәсәбәт булырга тиеш түгел!

– БДИны күпләр тәнкыйтьли. Сезнең фикерегез ничек? – дим.

– Миңа калса, БДИ куркыныч әйбер түгел. Бары ата-аналар, аерым укытучылар аны күпертеп, әллә нинди куркыныч сынауга әйләндерә. Чынлыкта исә БДИның эшләре мәктәп программасына кертелгән биремнәр. Укучыга дөрес аңлаткан очракта, аны уртача укучы да рәхәтләнеп чишә ала. Совет чорындагы имтиханнар бүгенге таләпләргә туры килмәс иде. Заман белән укучылар да үзгәрә бит. Аннан, БДИ күп укучыларга зур мөмкинлекләр ачты. Илнең теләсә кайсы уку йортына барып белем алырга була хәзер. Элеккечә имтихан тапшырып керәсе булса, югары уку йортларында әшнәлек, ришвәт чәчәк атар иде. Миңа калса, укучының белемен тикшерү өчен әлегә БДИдан да яхшы ысул уйлап табылмаган.

«УКЫТУЧЫЛАРЫНА КҮРӘ – УКУЧЫЛАРЫ»

Алмаз Нуретдиновичка 31 яшь. Аның республика, Россиякүләм бәйгеләрдә җиңүләрен санарга бер бит кенә җитми! Бу җиде ел эшләү дәверендә! Күрәсең, XXI гасыр укытучысы шундый булырга тиештер дә. Дүрт телне камил белә: татар, рус, инглиз, төрек телләрен. Әле тагын бер ике чит тел өйрәнергә уйлый. Америка, Швейцария, Испаниягә барып, белемен күтәреп кайта. (Махсус программа буенча укый.) Быел да барган. Туктаусыз эзләнүдә. Дөресен әйтим, минем әлегә кадәр мондый укытучы белән аралашканым юк иде. Әмирхан Еники хикәясендәге кебек, «бу укытучы бәрәңге ашамыйдыр шикелле» тоелды.

– Тәмле исләр чыккан, – дип лицей ашханәсенә тагын берәү килеп керде. Директорлары – Ризванов Ирек Асафович икән. Шулай ук яшь, яңа гына утызны тутырган. (Коридорда да күзәттем: коллектив нигездә яшьләрдән тора.)

– Сездә яшьләр генә эшлиме әллә? – дим, Ирек Асафович белән танышкач.

– 80 проценты яшьләр. Бар, әлбәттә, азу ярган, бик тәҗрибәле мөгаллимнәр дә. Аларга карап үрнәк алабыз. Коллективка килгәндә, бездә укытучыларга тулы ирек! Кемнең нинди яңа идеясе, тәкъдиме бар, барысын да тормышка ашырабыз. Берәүне дә кысу юк. Хәер, аларны кысып та булмый. Безнең укытучылар көн саен төрле уку йортларына эшкә чакыру алып торалар. Мактанып әйтүем түгел: иң яхшы укытучылар коллективы бездә. Рейтинг буенча республикада беренче урында без.

Шуннан директор укытучыларның исемен атап, кайсы уку йортларын тәмамлаганнарын (күбесе чит илдә укыган, тәҗрибә туплаган), аларның уңышларын санады.

– Иң мөһиме – алар бүген дә һәркайсы үсештә. Нинди генә проектларда катнашмыйлар, берничә тел беләләр. Курыкмыйча әйтәм: лицейда чын профессионаллар эшли! Ә Алмаз Нуретдиновичның безне сайлавы коллективка янә бер дәрәҗә өстәде. Элек лицей гуманитар юнәлештә эшләсә, хәзер курсны төгәл фәннәргә алдык. Математика шуларның – иң төп нигезе. Технологияләр заманы бит, ә аның башында саннар, логик фикер йөртү тора. Шулай булгач, математиканы яхшы белү башка төгәл фәннәргә дә ишек ача.

Алмаз Нуретдиновичны да берничә тапкыр башка уку йортларына директор вазыйфасына чакырганнар икән. Баш тарткан ул.

– Беренчедән, укытучы буларак тагын да үсәсем килә, – ди мөгаллим. – Икенчедән, директор ул күбрәк оештыручы. Әле укытучы буларак эшлисе проектларым бар. 2 нче лицей-интернат мине тулысынча канәгатьләндерә, һәрхәлдә, әлегә.

...Борычыбыз әзер булды. Ирек Асафович укытучылар бүлмәсенә кереп авыз итәргә чакырды. Башта сәерсенгән идем, аннан гаҗәпләнмәдем. 2 нче лицейның мөгаллимнәре башка булган кебек, укытучылар бүлмәсе дә – үзгә. Бу күбрәк аш бүлмәсен хәтерләтә: тамак ялгап алыр өчен бөтен кирәк-яраклар да бар. Ашап-эчкәннән соң ятып ял итәргә дә була.

– Безнең киңәшмәләр чәй эчү кебегрәк килеп чыга, – диде директор. – Һәр укытучы план-идеяләре белән уртаклаша. Әйтерсең, гаилә кичке ашка җыелган...

Алмаз Нуретдинович, аңа хас булган пөхтәлек белән, борычларны тәлинкәләргә бүлеп чыкты. Шулай итеп, акыллы укытучылар компаниясендә кичке аш ашадык. Миңа калса, мондый кешеләр белән гади йомырка тәбәсе дә тәмле була. Итле татлы борыч турында әйтәсе дә юк!

1. Кисәбез!

2. Чистартабыз!

3. Уабыз!

4. Турыйбыз!

5. Салабыз!

6. Өстибез!

7. Болгатабыз!

8. Тутырабыз!

9. Тезәбез!

10. Алабыз!

НЫГЫТМАЛАР ҺӘМ АВЫЛЛАР

Чирмешән районы туристлар өчен – чын мәгънәсендә хәзинәләр белән шыплап тулган сандык ул. Ни генә юк ул сандыкта – Болгар кызларының беләзегеннән сәйләннәр дә, катып калып тораташка әверелгән үсемлекләр белән кабырчыклар да, Пугачев фетнәсе чорыннан калган мушкетлар да... Бу сандыктагы әйберләрнең тарихын күздән кичерер өчен бераз гына хыялыйлык кирәк тагын.

Авторлар:

Ксения Сёмина

Владимир Силантьев

ИМПЕРИЯ ЧИКЛӘРЕНӘ ЮЛ ТОТЫП...

«...Я глядел вослед Марьи Ивановны; она оглянулась и кивнула мне головой... В эту минуту раздался страшный визг и крики; мятежники бегом бежали к крепости. Пушка наша заряжена была картечью. Комендант подпустил их на самое близкое расстояние и вдруг выпалил опять. Картечь хватила в самую середину толпы. Мятежники отхлынули в обе стороны и попятились. Предводитель их остался один впереди... Он махал саблею и, казалось, с жаром их уговаривал... Крик и визг, умолкнувшие на минуту, тотчас снова возобновились. «Ну, ребята, – сказал комендант, – теперь отворяй ворота, бей в барабан. Ребята! вперёд, на вылазку, за мною!»

А. С. Пушкин «Капитанская дочка».

Александр Сергеевич атаклы повестендә сурәтләгәннәрнең барысының да чынбарлыкта ничек булганын үзебез күреп белер өчен, китапны да кыстырып, Чирмешәнгә юл тоттык... Авылны уздык та алагаем зур агач капка каршында тукталдык. Авыр ян капканы ачып җибәреп, Чирмешән ныгытмасына аяк басуга, шунда ук турыдан-туры XVIII гасырга эләктек.

– Ә менә монысы – Пугачев калкулыгы... Ә биредә без казу эшләре алып бардык – ныгытмадан елгага алып чыга торган яшерен юлны эзләдек, – дип сөйли Чирмешән тарихи-туган якны өйрәнү музее директоры Алмаз Закиров. Без аның белән ныгытма диварының иң югары валында басып торабыз. Моннан Чирмешәнне уратып агып яткан Чирмешән елгасы да, солдатлар белән «ландмилиционерлар» нигез салган авыл үзе дә җәйрәп күренеп тора. Ә соңгыларына исә ныгытмада хезмәт куючылары өстенә тагын тирә-яктан җирләр дә бүлеп биргәннәр.

1730 нчы елларда торгызылган һәм Россия чикләрен башкисәрләрдән сакларга тиеш булган Яңа Кама арьягы чик буе ныгытма линиясе системасында (Алексеевск исемле Самара ягы авылыннан алып Минзәләгә кадәр, барлыгы – 220 чакрым) балчык ныгытмалар берничә була. Шулар рәтендә Шешма белән Чирмешәннеке дә бар – алар бер-берсеннән 15 километр ераклыкта урнашкан. Икесе дә Чирмешән районына керә. Шешма ныгытмасы чак-чак кына калкып утыра. Ә менә Чирмешән ныгытмасы үзенең йөз-кыяфәтен яхшы саклый алган. Аның формалары матур һәм анык булып күренеп тора, дүрт почмаклы бу ныгытма югарыдан – очкычтан караганда да бик яхшы шәйләнә. Аның дивар-валларының биеклеге (100 х 100 метр) кайчандыр 10 метрга кадәр җиткән. Ныгытманың эченә рәхәтләнеп футбол кыры урнаштырырга мөмкин.

XVIII гасырның беренче яртысында ныгытма гарнизоны ногай һәм калмык-башкорт отрядларының һөҗүмнәрен кире кагарга тиеш булган. Әмма иң драматик хәлләр монда Пугачев фетнәсе күтәрелгәннән соң була.

«Югары вә гыйззәтле әфәнде генерал-майор Александр Иванович Миллерга. Сезнең тарафтан махсус юлланган кече яшьтәге Андрей Тимофеев безнең армиягә килде дә Сез, гыйззәтле әфәнде, һәм ныгытма эчендә булган барлык Сезгә ышанып тапшырылган команда да, императорыбызга тулаем буйсына һәм үзләрен аның колы исәпли, дип белдерде. Әгәр бу чыннан да шулай икән, гыйззәтле әфәндебез, бирегә обер-офицерны юлларга тиешсез, ә инде җирәнгеч-чиркангыч тапмасагыз, Үзегезнең дә килеп чыгуыгызны үтенер идек – бу очракта Сез император хәзрәтләренә элеккечә тугры хезмәт итүегезгә дә, аның колы булуыгызны да безгә үзегез җиткерә алыр идегез. Бөек император Сезне, монда килә калсагыз, аталарча мәрхәмәтеннән ташламас, алай гына да түгел, тагын да ныграк кайгыртучанлык күрсәтер иде...» – Пугачевның полковнигы Сәет Рәзмәмәтовның бу хаты 1774 елның 16 гыйнварында, чатнама салкын бер иртәдә, Чирмешән ныгытмасына китереп тапшырыла. Рәзмәмәтов әйтүе буенча, Оренбург, Уфа провинцияләре һәм башка кайбер калалар «аның император хәзрәтләренә», ягъни «Петр III»гә, аңлавыбызча, Пугачевка, инде үз теләге белән бирелде. Шулай ук 12 меңлек гаскәрнең Чирмешәннән ерак түгел, янәшәдә генә көтеп торуы турында да әйтелә...

Әмма баш күтәрүчеләрнең хатыннан Миллерның керфеге дә селкенми. Озакламый фетнәчеләрнең гаскәрләре тар-мар ителә, Рәзмәмәтов үзе, әсир төшеп, Казанның яшерен комиссиясенә тапшырыла. Анда ул шул елның февралендә үлә.

Фетнәчеләр белән Чирмешән ныгытмасы гарнизоны арасындагы тагын бер сугышны тасвирлый Александр Пушкин – үзенең «Пугачев фетнәсе тарихы»нда. «1744 елның маенда яисә июнендә капитан Фадеев Чирмешән елгасы ярында урнашкан Афонькино һәм Туарма авыллары янында Чирмешән ныгытмасына һөҗүм иткән бер өер башкисәрне тар-мар иткәннән соң, 200 гә якын фетнәчене куып җитеп, урынында үтерә дә, 25 кешене әсир итеп ала. Шул ук Фадеев Соленкино авылында (фаразлар буенча, Чирмешән ныгытмасыннан 5 чакрым ераклыкта урнашкан Салейкинода) явыз Пугачев гаскәренә килеп кушылган 3000 тирәсе башкорт барлыгын ачыклый, аларга һөҗүм ясау буенча тиешле чаралар күрә. Ике яктан да туплар ата башлый, ниһаять, барлык башкисәрләр дә качарга керешә. Яу барган урында 300 кеше ятып кала, шул исәптән – иң төп җитәкчеләре белән, ике чуен туп та...»

Әлеге ике чуен туп бүген дә Чирмешән ныгытмасына керә торган капканы саклап басып тора. Алар янынннан узгач, ныгытма диварына таба узасың, почмакка барып җиткәч, безнең экскурсиябез башланган урынга килеп чыгасың. Бирелә алагаем зур таш ята – берәүләр аның астында бүгенгәчә Пугачев калдырып киткән хәзинә ята, дип исәпләсә, икенчеләр шушы ташлар ярдәмендә танылган төбәкне өйрәнүче Николай Фроловның Чирмешәндәге иң биек ноктаны билгеләргә теләвен хәтерли... Сүз уңаеннан, Пугачев валы бу һәркемгә билгеле исемне йөртә генә, Пугачев монда үзе булмаган да. Җир асты туннеле дә табылмаган. Кем белә, бәлки Чирмешән ныгытмасы әле хәзергә кадәр серләрен генә ачып бетермидер...

Фотолар Чирмешән тарихи-туган якны өйрәнү музееннан алынды, автор һәм «Кочующие» командасы порталындагы фотолар кулланылды





Чирмешән ныгытмасы бүгенге көндә.



ПЛЕЙСТОЦЕНГА «БЕРЕККӘННӘР»

– Күрәсезме, әнә, эчендә битум, – ди Казан федераль университетының Геология музее директоры Владимир Силантьев, зубр баш сөяген миңа таба йөзе белән борып. Баш сөягеннән гудрон исе килә, ә эчендә чынлап та битум, әле һаман үзләнеп торуын дәвам итә.

Бу баш сөяге Түбән Карамалы авылыннан ерак түгел табып алына. Ул каты битум сеңгән ком катламында яткан булган. Монда, кечкенә генә үзәнлектә, берничә йөз мең ел элек, эсселек тәэсире нәтиҗәсендә, битум күлләре хасил булган. Аның көзгедәй өслегән хайваннар сулык дип белгәннәр, имеш.

– Ә аннан соң ни булганын бик шәп итеп Чехия рәссамы Зденек Бурианның һәм палеонтология профессоры Йозеф Аугустның рәсем-реконструкцияләре бик яхшы тасвирлый, – дип дәвам итә Владимир Силантьев. – Иң башта битум сыекчасында эре тояклы хайваннар катып кала, мәсәлән, бизон, аннары – җиңел табыш белән туенырга теләп кергән эре һәм вак ерткычлар, соңыннан инде – түшкәләрне чукырга дип очып төшкән кошлар һ.б.

Зубрлар, затлы һәм төньяк боланнары, аюлар, бүреләр, ак төлкеләрнең баш сөякләре, куяннарның, кыр тычканнарының, көртлекләрнең, үрдәкләрнең һ.б. җанвар, кош-кортларның сөякләре монда бик күп табылган – 1000ләп фрагмент һәм 400ләп төр. Үсемлек калдыклары да җитәрлек: нарат, артыш, каен, өянке, камыш серкәсе, орлыклары, яфраклары, җиләк-җимешләре. Әлеге фауна һәм флора объектлары плейстоценның соңгы чорына карый (моннан 115 мең ел элек башланып, 12 мең ел элек тәгәлләнгән). Болар барысы да Кармалка каберлекләреннән табылган.

Түбән Кармалка янындагы табылдыклар йөз мең еллар элек хайваннарның яшәү ареаллары ничек үзгәргәне турында сөйли. «Инде төре югалып бара торган һәм трансформация кичергән зубрдан кала, шулай ук юкка чыккан атны исәпкә алмаганда, каберлекләр урыныннан 700 чакрымга диярлек ак төлке ареалы чигенгән, сары кутәмәнең ареалы исә Монголия чикләренә таба меңләгән чакрымнарга чигенгән... Якын-тирәдә затлы боланны да оч-

Кармалка каберлегеннән табып алынган зубр баш сөяге Казан федераль университетының Геология музеенда саклана.

Түбән Кармалка авылы янында асфальтитның чыгып торган урыны. Нәкъ менә шуның кырыенда каберлеккә илтүче чокыр табыла.

Битум сеңгән аю баш сөяге. Түбән Кармалка авылы. Казан федераль университетының Геология музее.



Чехия рәссамы Эденек Буриан һәм палеонтология профессоры Йозеф Аугустның реконструкциясе.

Фото: www.900igr.net

ратып булмый хәзер, – узган гасырның 50 нче елларында Кармалы каберлекләрен беренчеләрдән булып өйрәнгән Н.Верещагин әнә шулай язып калдырган. Казып алынган биота (барлык организмнарның кушылмасы) борынгы Кама буеның плейстоцен азагында Көнбатыш Себернең көньягын хәтерләтүенә ишарә итә – монда да шулай ук нарат урманнары белән каен урынчалыклары шаулап утырган. Ә битумда табылган коңгызлар Үзәк Азия территориясендә яшәүчеләргә тәңгәл…

Вакыт җирле флора белән фаунаны бик нык үзгәртсә дә, битумны үзгәртмәгән. Ул һаман да җитәрлек күләмдә Кармалка комлыкларында табылып тора. Ә комлыклар үзләре – Шешма елгасы үзәнлегендә киң таралган Уфа һәм Казан яруслары катламнарының алагаем бер өлешен тәшкил итә.

– Битум күлләре геологларның игътибарын һәрчак җәлеп итә иде. Узган гасырның 40 нчы елларындагы тирәнтен бораулау әлеге Татарстанның көньяк-көнчыгыш районында гаять зур Ромашкино нефть чыганагын ачарга мөмкинлек бирде. Территория гамәли фән өлкәсендә дә зур кызыксынуга лаек. Бу Рус тигезлегендәге геологик яктан исәпләгәндә әле күптән түгел генә сыек нефть битумнарының көндезге өслеккә агып чыгып утырган урыннары. Сүз уңаеннан, хәзер «Татнефть» ГАҖ белгечләре Әшәлчә битум чыганагында бик тырышып эшли, ә ул структурасы буенча Кармалка ятмасына бик тә якын тора, – дип, нәтиҗә ясый Владимир Силантьев.

Түбән Кармалка янында табылган объектлар КФУның Геология музеенда һәм Татарстанның табигать байлыклары музеенда саклана. Тарихи чорга кадәр яшәгән хайван калдыклары яткан чокырны үзлегеңнән табу җиңел булмас. Каберлекне табудан соң узган ярты гасырдан артык гомер эчендә районның пейзажы күзгә күренеп үзгәргән. Асфальтитның чыгып торган урыны хәзер куаклар һәм болын үләннәре астында калган. Әмма алай да нык кызыксынучылар өчен координаталарны бирәбез: Түбән Кармалка авылының көньяк чигендә Урта елга чыганагының башын табарга кирәк булачак. Плейстоценга илтүче «ишекләр», дөресрәге, аларга ишарә шуннан 3,5 чакрымга көньяктарак.

ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫНДА ТАГЫН НӘРСӘЛӘР КАРАРГА БУЛА?

Чирмешән авылы

Тарихи туган якны өйрәнү музее

Нәкъ менә биредә без хәзерге чикләр территориясенең һәрчак кеше белән мыжлап торуы хакында белдек. Шуңа да Чирмешән авылларының тарихы бик кызыклы. Ивашкинодагы мәктәп урынында XI гасырда болгар ныгытмасы торган (әйтергә кирәк, иске һәм яңа Кама буе ныгыту линияләре нәкъ менә болгар фортификацион корылмалар урынында торгызылган). Казанка авылында галимнәр бакыр дәвере мәдәнияте калдыклары тапкан. Сотников хуторы янында кайчандыр монгол яуларына кадәрге болгар җирлекләре булган… Ә бу төбәкнең нинди күпмиллэтле булуы турында әйтеп торасы да юк! Татар, рус, мордва, чуваш мәдәниятләре җирле тарихта үз эзен калдырган. Шулай ук – музей экспозициясендә дә. Чирмешән төбәгендә хәтта французлар да яшәгән… Марилар да. Әйтергә кирәк, «Чирмешән» үзе үк «чирмеш» («черемис») сүзеннән килеп чыккан – урта гасырларда мариларны шулай атап йөрткәннәр. Дөрес, бүген марилар район территориясендә яшәми диярлек. Чирмешәнгә исем бирүчеләр кая киткәннәр соң? Әлеге һәм башка җирле тарихи серләр турында музей экспозицияләрен карап йөри-йөри шактый баш ваттык.

Матрос Михаил Титовка һәйкәле

Чирмешәннең уң ярында үзенчәлекле һәйкәл бар – аның постаментында портрет һәм диңгез якоре урнашкан. Әлеге стела 1906 елның гыйнварында Владивостокта кораллы матрослар фетнәсен оештырган һәм хәрби транспорт матросы булган Михаил Титовка багышланган. 11 ел буена сөргендә эшләгәннән соң, ул ирекка җибәрелә һәм 1918 елда Бөгелмә өяз башкарма комитеты Советына крестьян депутатлардан әгъза булып алына. 1919 елның апрелендә Колчак армиясе тарафдарлары аны кулга ала һәм атып үтерә. Һәйкәл ул һәлак булган урынга куелган.

Күтәмә авылы

Богоявление чиркәве

Агачтан корылган Богоявление чиркәве – төбәкнең йөзек кашы. Удл 100 ел элек Казан епархия архитекторы Николай Андреев

Күтәмә авылындагы Богоявление чиркәве.



Ныгытма тавы (Шешма ныгытмасы).





Иске Үтәмеш авылындагы Җәмигъ мәчете.

проекты буенча төзелгән. Кайчандыр ул оригиналь композициясе белән күзгә ташланып торган – хачсыман рәвештә булган. Өске яруслары һәм чаңы җуелган.

Иске Үтәмеш авылы

Җәмигъ мәчете

Мәчетне төзү (1876–1877 еллар) Гыйрфан мулла һәм авыл халкы акчасына башкарылган. Бүгенге урынына мәчет бурасы күчереп салынган. Мәчет ачылган көненнән башлап бер генә көнгә дә ябылып тормаган. Түбәнең уртасында – сигез кырлы манара, аның арка формасындагы сигез тәрәзәсе бар, манара чатырсыман түбә белән очлана. Бинаның кәрнизе геометрик бизәк белән нәкышьләнгән, тәрәзәләрнең йөзлекләре кисеп ясалган. Авыл мәчетенең менә дигән һәм яхшы сакланган үрнәге.

Шешма ныгытмасы авылы

Шешма ныгытмасы

Әлеге балчык ныгытма – XVIII гасырның хәрби-саклану төзелеш сәнгате үрнәге. Инде аңа кадәр булган форпостның нигезендә ныгытылган пункт буларак торгызылган. Төзү эшләренә Россия губерналарыннан 3 меңнән алып 30 меңгәчә крестьянны җәлеп иткәннәр. Ныгытма өлешләп кенә сакланып калган. Зурлыгы һәм планировкасы буенча ул Чирмешән ныгытмасына тәңгәл, бары тик урнашуы буенча гына аннан көньяк-көнчыгышта 15 чакрым ераклыкта утыра. Алар арасында булган саклану валы исән. Дөрес, урыны-урыны белән ул инде, өстеннән грунтлы юл салынып, җимерелгән.

7

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НЕҢ ЭФФЕКТЫ:

БЕР ЯБЫГУ ТАРИХЫ

Ябыгырга хыяллана башлавыма җиде еллап бардыр. Юк, мин алай бик тиз калынаймадым, артык килограммнарны акрынлап, еллар үтә барган саен җыйдым. Бервакыт үлчәү угы түгәрәк санга җиткәнче шулай барды да барды. Шул чакта психикам түзмәде. Инде киемнәремнең күбесенә сыя алмавымны һәм алга таба әле теге, әле бу җирдә җыерчыкланып торган кием киеп йөриячәгемне аңладым. Чөнки мөстәкыйль рәвештә 10 килограмм авырлыктан котылу бөтенләй чынга ашмас хәлгә әйләнде, җитмәсә, ач торудан кәефем начараюын тоя башладым.

Күрәсең, минем газаплануларымны күкләрдә ишеткәннәрдер һәм миңа «Салават күпере» шифаханәсеннән кайткан ахирәтем сыйфатында «фәрештә» җибәргәннәрдер. «Барып, ял итеп кайт», – дип үгетләде ул мине. Чираттагы отпускым җитә иде, бәяләрнең сикерүе нәтиҗәсендә мин бара алырлык Төркиягә сәяхәт яхшы гына евротурга охшап калды, җитмәсә, гаилә белән ял итүне дә күздә тотсаң...

Һәм мин, Интернетка кереп, «Салават күпере» шифаханәсе белән танышырга булдым. Бигрәк тә «Авырлыкны коррекцияләү» программасы кызыксындырды. 10 көн эчендә 7 үзгәреш гарантияләнә: матдәләр алмашы процессларын нормальләштерү һәм интенсивлаштыру, холестерин дәрәҗәсен киметү; организмнан авыр металл тозларын, шлакларны һәм токсиннарны чыгару; су-тоз балансын, углевод, аксым һәм май алмашын нормальләштерү; гәүдә авырлыгын киметү һәм фигураны коррекцияләү; мускулларны ныгыту, эшләү сәләтен һәм гомуми чыдамлылыкны арттыру; кәефне яхшырту; организмның саклану көчләрен уяту һәм рухи яктан савыктыру. Боларның яртысы гына эшләнсә дә, акчам бушка китми икән, дигән фикергә килеп, чемоданымны тутыра башладым.

«Салават күпере» мине нарат урманының искиткеч саф һавасы белән каршы алды. Шифаханә атаклы якташ рәссамыбыз Иван Шишкин сурәтләгән урман тынлыгында урнашкан, ул «Түбән Кама» Милли паркы территориясенә керә. Монда табигый минераль су чыганагы бар, ял итүчеләр краннан рәхәтләнеп шул суны эчә. Янәшәдә генә Кама елгасы ага – аңа кадәр йөз метрлар чамасы бардыр. Ярында пляж ясалган, елга төбе даими чистартылып тора.

Беренче көнне үк мин табиб-диетолог белән очраштым. Ул минем өчен шифаханәдә булу вакытымны күздә тоткан, туклану үзенчәлекләрем исәпкә алынган махсус рацион гына эшләп калмыйча, ризык кабул итү буенча индивидуаль киңәшләрен дә билгеләде. Минем өчен аерым пешерделәр, кайчак миңа кителгән төрледән-төрле ашлар гомуми өстәлнекенә караганда аппетитлырак та күренә кебек тоелды. Мин ач торырга туры килер дип уйлаган идем, юк, мине тәмле һәм туклыклы итеп ашаттылар.

Ябыгу алай кыен кебек түгел, киресенчә, рәхәт тоелды. Көнем минутына кадәр диярлек язылып куелган: иртәнге аштан соң ябыктыра торган чәй эчәргә фитобарга барам, аннан соң – 20 минутлык интенсив дәвалау физкультурасы. Ул спорт залында бер сәгатьлек шөгыльләнүне алыштыра. Алга таба мине Шарко душы яисә су асты душы көтә. Прессотерапия – әкияти процедура. Бу проблемалы зоналарга аппарат массажы ясый – лимфаның организм буйлап циркуляциясен тәэмин итә. Процедурадан соң гәүдә күләмнәре чыннан да бер размерга кими, бу күңелне бик күтәрә. Тозга төренүләрдән соң, килограммнар гына эреп юкка чыкмый, тән тиресе бәрхет кебек йомшара, шомара.

Бер көннән соң мине кедр мичкәсендә парландырдылар. Халык медицинасының әлеге уникаль һәм бик тәэсирле ысулы төрле авыруларны дәвалап кына калмый, мәкерле целлюлитны да юкка чыгара. Аромафитобальзам составына кергән кедр мае тирән һәм вак җыерчыкларны шомарта, тирене тукландыра һәм яшәртә. Әлеге рәхәтлекләрдән соң, «Похудейка» дип аталган хуш исле чәй эчкәндә үземне яңадан тугандай хис итәсең.

Озонотерапия дә гаҗәеп нәтиҗә бирә, ул күптәнге авыруларны дәвалап кына калмый, матурлык һәм яшьлекне дә сакларга булыша. Бу липоксация белән чагыштырырга мөмкин булган бердәнбер процедура. Озон һәм май күзәнәкләре бер-берсе белән яраша алмый, озон инъекцияләре майны шлаклар һәм токсиннар белән бергә кысрыклап чыгара, шуннан соң тире яшәреп, матураеп кала. Бу эффектны гомуми массаж сеансы тәмамлый: бер сәгать буена баштан алып аяк бармагына кадәр синең һәр мускулыңны һәм сөягеңне язалар. Ә нәтиҗәне ныгыту өчен – аквааэробика яисә бассейнда йөзү, сауна, озонлаштырылган һәм минераль су эчү, спелеокамерада релакс сеансы, даими кичке терренкур.

Инде берничә көннән соң мин ике ел кия алмаган чалбарыма сыйдым. Гомуми нәтиҗә – минус 3 кг – тыйнак сан кебек, әмма бер размерга кечерәю бөтенесен дә аклый. Һәм иң мөһиме, коллегаларым билгеләп үткәнчә, гәүдәм тартылды, тирем тыгызланды, фигурам матурайды. Ә иң гаҗәбе – мин, артык көч куймыйча, бары тик диетолог тәкъдим иткән рационны саклап кына, акрынлап ябыгуны дәвам итәм. Минем татлы ризыклар һәм конфетлар ашыйсым килми, ашханәдә төшке ашка да файдалы ашамлыклар сайлыйм, өйдә дә әлеге режимны сакларга тырышам. «Салават күпере»нә кышкы каникулларда тагын бер тапкыр барырга ниятлим – ял итәргә, үз-үзем турында кайгыртырга.





радуга

САНАТОРИЙ ТАТАРСТАНА

Татарстан, Яр Чаллы ш., Наратлык, «Түбән Кама» Милли паркы

Элемтә өчен:
8 (8552) 20-56-26

Веб-сайт:
www.lokraduga.ru

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Фотолар «Санаторий Радуга» ЯАҖ нән алынды. Реклама.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанда җәйне **НИЧЕК** үткәрәләр

Гаяз Исхакыйны **НИЧЕК** хәтерлиләр

Татарстан киносында **КЕМНЕҢ** уйныйсы килә

Иске Имән имәненә **НИЧӘ** яшь



Фото: Александр Ефремов, Алина Әхмәдишина

2018 елның җәен мин ничек үткәрдем

Үзенең йөз еллык әһәмиятле юбилеена якынлашып килгән «Татарстан» журналы җәйге вакыйгалар елъязмасы белән уртаклашырга бер дә онытмый. Аның исеме дә үзгәрми, һаман да шул ук – «Мин җәйне ничек үткәрдем» булып кала. Яңа уку елы башында, һәр сентябрь саен, хәрефләр, сүзләр, фотосурәтләр, уйлар, йөрәккә уелган хатирәләр белән бергә, без, мәктәп елларындагыча, әнә шундый «инша» язабыз... Шулай булган, хәзер дә шулай, һәм шулай булачак та. Җәйдән яхшырак нәрсәне уйлап табучы юк бит әле. Һәрхәлдә, соңгы 98 елда «Татарстан» моңа дәлил. 2018 елның күркәм җәе исә татарстанлылар хәтеренә менә нинди вакыйгалары белән уелды

ТАТАРСТАНДА НИЧЕК ҖАН АТАЛАР

48 бит

ТАТАРСТАНДА НИЧЕК ОЧАЛАР

50 бит

ТАТАРСТАНДА НИЧЕК КҮҢЕЛ АЧАЛАР

52 бит

PRESSA

Безнең йорт янында ук футбол буенча дөнья чемпионаты-2018! Искиткеч куәт һәм энергетика, безгә Россиядән һәм бөтен дөньядан кунаклар килде!!! Шәһәребездә шундый зур бөтендөнья бәйрәме булуына ышанырлык та түгел! Үзеңне бөтен җиһанның үзәге итеп тоясың!!! Ничек йоклап ятасың ди инде? Таулар күчерәсе килә! #дөньячемпионатыказан #кукушкиннаргаиләсе #казанфутбол #җанатарларказан

natalia_klinker

Бөтен дөньяны һәм планета халкын берләштерә торган бәйрәмнәр бармы? Бар икән! Ни гаҗәп – футбол буенча дөнья чемпионаты бөтен җиһан бәйрәме икән бит! Шулкадәр кеше! Халыкның шулкадәр берләшүе! Әйтерсең лә футбол түгел, бөтен дөньядагы дуслык бәйрәме! #дөньячемпионатыказан #позитив #искиткечкешеләр #футболказан #искиткечҗәй

natali

ТАТАРСТАНДА ҖАН АТАЛАР

Бу җәйне мин ничек үткәрдемме? Бәхет тулы җәй булды быел. Бию, балалар, ретрит, йога, гитарага кушылып җырлау, кызыклы очрашулар. Яратам бу тормышны. Быелгы җәй миңа бик күп яңа дуслар бүләк итте. Мин бөтен кешегә бәхет һәм рәхәт тормыш телим… Ешрак кочаклашыгыз! #дөньячемпионатыказан #гитарагакушылыпҗырлыйбыз #казантатарстан

toma4doma

Күңелле дә соң! Кремль яр буенда гаҗәеп рәхәт! #казан2018 #казандаяшим #дөньячемпионатыказан

starkaffa

Алар әйләнеп кайтты)))

Aleksey_ugarov

Самолёт күктә элмәк ясый, уктай аска атыла, акчарлаклар оча, балыклар йөзә, балалар таганда атына, әти-әниләр селфи ясый. Һәм барысы да күккә төбәлгән…#күк #самолётлар #казан #татарстан

kronsazon

Авиашоуны карауччылар булдымы? #авиашоуказан

Matbugat

ТАТАРСТАНДА НИЧЕК ОЧАЛАР

Үлем элмәге… сөенеч, бәхет #авиашоуказан

Kseniya1592

Нинди #кош бу? Күктә шаяра. Көмештәй балкып, уктай ыргыла! #казандаяшим #татарстан #казан_ татарстан

Larisabokushava

Кәттә шоу!

Zagidullina_dinara

Сихерли… #redbullairrace #минемказаным #татарстан

Liya_akhmetzyan

Самолетларны үлеп яратам! Алар безнең өстән очып үткәндә, тыным кысылды! Минем әле моңарчы беркайчан да мондый шоу күргәнем юк иде! Бик матур! #авиашоу #казан #самолётлар

Cristalikzn

Авиашоу һәм МӘХӘББӘТ. Очраклы гына үтеп барышым иде бит юкса… ә монда авиашоу)) #самолётлар #казан #мәхәббәт

Oksana_malugahoto

Казанда яшәүнең тагын бер бонусы) Биредә дөньякүләм чаралар гел булып тора! Һәм аларда катнашу, алар белән хозурлану мөмкинлеге бар!#казан #татарстан #ялкөннәре

Svetikbelik

Бүген аның туган көне! Җирдәге иң шәп шәһәрнең! Казаным, гөрләп үс, төзел, иркенәй! Һәрвакыт шундый кунакчыл булып кал! Бирεдә яшәвебез һәм эшләвебез белән бәхетлебез, горурланабыз!!! #минемказаным #яратамказан

alteraburo.ru

Менә шулай, машинада нибары 5 сәгать барасың да, халкының күпчелеге бөтенләй башка милләттән булган, башка диндәге, башка йолалы республикага килеп эләгәсең. Искиткеч! Казан! #казан #татарстан

Marykuznetsova

Менә бу ял, ичмасам! Казан шәһәре бик матур. Без әле бирегә тагын күп тапкырлар килербез. #казан #шәһәркөне #кыскаял #хыялдагышәһәр

Alina_1996b

ТАТАРСТАНДА НИЧЕК КҮҢЕЛ АЧАЛАР

«Бу шәһәрнең Россиядә Мәскәүдән соң иң күркәм кала булуы бәхәссез… Казанның зур патшалык башкаласы булуы әллә кайдан күренеп тора». 1767 елда язган хатларының берсендә Екатерина II шәһәребезгә шундый бәя биргән.

Ул хаклы. Искиткеч шәһәр, биредә искиткеч кешеләр яши. Яраткан Казаным, синең көнең белән! Татарстан, синең көнең белән! Яратыгыз туган җирегезне! #казаным #казан #татарстан #минемяраткашәһәрем

mazitova.rr

Әсир итә…
#redbullairrace #минемказаным
#татарстан

Liya_akhmetzyan

Бәйрәм белән, Казан! Бу шәһәргә
көннән-көн күбрәк гашыйк була
барам! #казан #казаншәһәрекөне
#мәхәббәт

nastiafedotova

Туган көнең белән, яраткан
шәһәребез! Бәйрәм белән,
Казан-гүзәлкәй! #минемказаным
#казаншәһәрекөне #матурказан

Zakirova_karina

АЛТЫН УРДА: «БӨЕК БОЛА» ҺӘМ ТУКТАМЫШ ХАН

Алтын Урда белән Үзбәк хан (1312–1342 еллар) һәм аның улы Җанибәк (1342–1357 еллар) идарә иткән чорда Җучилар дәүләте дөньяның иң көчле дәүләте буларак таныла, дигән идек алдагы язмабызда. Дәүләт белән бергә аерым олыслар, ерак төбәкләр белән идарә итүче бәкләре, мирзалары, әмирләре дә куәтләнә. Аларның кайберләре даими гаскәр тота, биләмәләрен Алтын Урдадан аерып алып, мөстәкыйль дәүләт итеп ясау, хәтта Сарай тәхетен яулап алу турында да хыяллана башлыйлар. Хыялларын тормышка ашыру юнәлешендә практик чараларга да тотыналар. Бу исә илдә сәяси тотрыксызлык китереп чыгара.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Алтын Урдада сәяси тотрыксызлык Җанибәк ханның улы Бәрдебәк вакытында ук башлана. Кайбер тарихи чыганакларга караганда, ул тәхеткә 1357 елда әтисен үтертеп килә (хуш, әтисе дә бит ике бертуган энесен үтереп тәхет хуҗасы булган иде) һәм, алга таба да тәхет өчен көрәштә теләсә кайчан килеп чыгарга мөмкин фетнә-заговорлардан куркып, Батый хан нәселенә караган барлык ир-туганнарын теге дөньяга озата. Ике ел чамасы вакыт ыгы-зыгылар арасында узып китә. Ханның дошманнары көннән-көн күбәя. 1359 елда алар Бәрдебәккә каршы заговор оештыралар. Аның үлемен Сарай аристократиясе эчке бер канәгатьләнү белән кабул итә.

20 ЕЛГА СУЗЫЛГАН КӨРӘШ

«Бөек бола» – «великая замятня» – Алтын Урда тәхете өчен 1359 елдан башлап 1380 елга кадәр дәвам иткән егерме еллык көрәш чорын рус елъязмачылары шулай атаган. Минемчә, бу билгеләмә илдә барган сәяси вакыйгаларның, ыгы-зыгыларның, чуалышларның асылын дөрес ачып бирә. Уйлап карагыз: кыска гына шул дәвер эчендә тәхеттә егермедән артык хан утырган (кайберләре икешәр тапкыр)! Рус елъязмачылары кайвакыт, киләчәк буыннар өчен дип, ул ханнарның исемнәрен дә теркәп калырга өлгермәгән хәтта. Ярый әле, чираттагы хан, тәхеткә утыру белән, үз исемен куеп бакыр, кайберләре исә көмеш акчалар чыгарган. Аларның исемнәрен, идарә итү вакытын галимнәр бары тик шул акчаларны өйрәнеп кенә, анда да әле кайбер очракларда якынча гына, ачыклый алдылар.

Мөнә Күлпә хан (аны Күлнә дип тә йөртәләр), ул 1359 елда, ягъни Бәрдебәктән соң бары тик 5–6 ай чамасы гына идарә итеп кала. Аның урынына Нәүруз хан килә. Шул ук 1359 елда сарай әһелләре аның үзен дә, улы Тимурны да үтереп, тәхеткә Шибанилар ыруыннан чыккан Хызыр ханны утырталар. Ил хуҗасы сыйфатында ул да озак идарә итә алмый. Олы улы Тимер Хуҗа «тырышлыгы» белән аны тәхеттән куалар һәм теге дөньяга озаталар. Тимер Хуҗа үзен чын хуҗа итеп тоярга да өлгерми, сәяси горизонтта Бәрдебәк ханның кияве, бәкләрибәк (бәкләр бәге), атаклы Мамай мирзаның көчле фигурасы пәйда була. Дөрес, Чыңгызлар нәселеннән чыкмагач, аның тәхеткә утырырга хокукы булмый, әмма ул үзенең якын тарафдарлары – әмирләр һәм бәкләр аркылы кыю эш йөртә. Шуларның берсе, Абдуллаһ исемлесе, 1360 елда хан тәхетенә утыртыла. Ул бер ел чамасы гына идарә итеп ала (чынлыкта хакимлек Мамай кулында була). Көндәшләре Абдуллаһ ханны да, Мамай мирзаны да Сарайдан куып чыгаралар. Тәхеткә 1361 елда Котлык Тимер менә. Идарә итүе эпизодик характерда гына була – аңа каршы булган көндәшләр төркеме Котлыктан тиз котыла һәм туганлык җепләре Күк Урда ханнарына барып тоташкан Урда Маликны (Урда Шәехне) ханлыкка чакы-

Мамай хан.

ра. Аны да идарәче сыйфатында озак тотмыйлар. Хан тәхетенә үзен Җанибәкнең улы итеп таныткан (гәрчә бу уйдырмага ышанучылар аз булса да) Килдебәкне утырталар. Ул 1362 елда Күк Урда гаскәрләре белән сугышта үтерелә, Сарай тәхетен кыска гына вакытка Күк Урда ханы Чимтайның туганы Мөрид (Мурад) яулап ала. Әмма аңа тәкәббер һәм үзен киләчәктә хаким итеп күрергә хыялланган Мамай мирза тынгылык бирми. Мөрид хан белән сугышта ул җиңүгә ирешә һәм тәхет тирәсендәге күп санлы тарафдарлары Алтын Урда ханы итеп яңадан Абдуллаһны раслыйлар. Аннан соң Мирбулат, Газиз Шәех, Толынбәк ханым, Мөхәммәд Буләк, Ырыс, Чиркәсбәк, Каганбәк, Туктакыя, Тимер Малик, Гарәбшаһ кебек эреле-ваклы ханнар тәхет биләп торалар. Арада бер-ике ел, берничә ай, хәтта берничә көн генә идарә итеп калганнары да бар.

УРДАЛАР БҮЛЕНЕШЕ

Әлбәттә, мондый бола, ягъни егерме елга сузылган тәхет чуалышлары, Алтын Урданың нык көчсезләнүенә китерә. Һөнәрчелектә, авыл хуҗалыгында, бигрәк тә игенчелектә торгынлык күзәтелә, чит илләрдән шәһәр базарларына товарлар килү сизелерлек дәрәҗәдә кими, дәүләт казнасы еш булып торучы сугышлар нәтиҗәсендә саегып кала. Икътисадый һәм сәяси кризисның кискенләшүендә табигый сәбәпләр дә билгеле күләмдә тискәре роль уйный, әлбәттә. Берничә елга сузылган корылык, илнең күп кенә төбәкләренә таралган куркыныч чума авыруы Алтын Урда халкының, бигрәк тә хезмәткә, сугышэшенә яраклы ирләрнең күпләп үлүенә, тууучылар санының кимүенә китерә.

Шушы шартларда, әлбәттә, Алтын Урданың бердәмлегенә дә зур куркыныч яный. Әле Җучи Олысының оешу чорында ук, күчмән төрки һәм монгол дәүләтләренә хас булганча, ул административ яктан уң (Ак Урда – башлыча Батый һәм Субәдәй яулап алган көнбатыш кыпчак җирләре) һәм сул канатларга (Күк Урда – Урал-Иртыш, Арал һәм Җидесу өлкәләре) бүленгән була, әмма бу бүленеш илнең бердәмлегенә һич тә комачауламый. Ә менә Килдебәк хан идарә иткән чорда Алтын Урда Идел һәм Җаек (Урал) елгалары арасындагы чик белән ике өлешкә таркала. Шул вакыттан башлап Ак һәм Күк Урда ханнары арасында Сарай тәхете өчен көрәш туктамый. Чимтай хан һәм аның улы Ырыс хан заманнарында Күк Урда мөстәкыйльлек ала, ягъни Сарай ханнарына буйсынудан бөтенләй баш тарта.

1361 елда Арал диңгезеннән көньяктарак урнашкан Хәрәзем Олысы да (башкаласы – Үргәнеч) чынлыкта мөстәкыйль дәүләткә әверелә. Биредә Коңгырат ыруыннан чыккан Суфилар династиясе идарә итә. Хәрәзем ханнары, хәрби көч кулланып, күрше төбәкләр исәбенә үз җирләрен киңәйтүгә

Туктамыш хан.

Алтын Урданың җәяүле яугире.

ирешәләр. Бу хәлдән куркып калган Сәмәрканд әмире Тимур (Аксак Тимер) Хәрәземгә берничә мәртәбә яу чаба, әмма сизелерлек уңышка ирешә алмый.

Идел белән Дунай елгалары арасындагы җирләр рус елъязмаларында «Мамай Урдасы» дип йөртелә башлый, чөнки ул төбәкләр, шул исәптән безнең Болгар Олысы да, тулысынча Мамай хакимлегенә буйсына. 1360 нчы еллар уртасыннан башлап Мамай Ак Урданың чын хакименә әверелә. Әмма 1370 нче еллар башында аңа каршы көчләр нык активлаша. Бу очракта икътисадый яктан ныгып килгән рус кенәзлекләренең дә уңай йогынтысын да билгеләп үтәргә кирәктер, минемчә. Мәскәү кенәзе Дмитрий Иванович рус җирләрендә Мамай хакимлеген танудан баш тарта. Моңа җавап йөзеннән, Мамай Рязань һәм Түбән Новгород кенәзлекләренә яу чаба, алардан элеккеге күләмдә салым түләүләрен таләп итә. Әмма уңышка ирешә алмый. Мамай гаскәрләренең 1380 елгы Куликово сугышында җиңелүе, аның белән бергә сугышкан бәкләрнең Туктамыш ягына күчүе авантюрист «ханның» ике дистә ел буена алып барган хәрби-сәяси эшчәнлегенә нокта куя.

Алтын Урданың көньяк-көнбатыш олысы Крым да Сарай ханнарын санга сукмый башлый. Таулы Кырымның Кафа, Феодоро, Судак, Чембало кебек шәһәрләрдә яшәүче Генуя һәм Венеция сәүдәгәрләре актив рәвештә Азов буйларына күтәреләләр, Азак шәһәрен һәм аның тирә-юнендә урнашкан авылларны үзләренә буйсындыралар.

Тәхет чуалышлары чорында Алтын Урда составына кергән хәзерге Мордовия җирләренә Сикез бәй исемле монгол идарәчесе килеп урнаша. Аны Азактан 1361 елда Сарайны ташлап китәргә мәҗбүр ителгән Мамай белән Абуллаһ хан куып чыгарган була. Сикез бәй биредә көчле кала (крепость) төзетә. Бераздан үзәге Наровчат-Мукша булган бу җирләр Тагай бәк кулына эләгә һәм беркавым мөстәкыйль кенәзлек рәвешендә яшәп ала.

Алтын Урданың иң бай төньяк төбәкләреннән саналган Болгар Олысы шул ук 1361 елда Булат Тимер кулына эләгә. Биш ел буена Болгар халкы Сарай ханнарына буйсынмыйча яши. Булат Тимер үз исеменнән акча суктыра. Акчаларның алгы ягына – «Солтан, мәрхүм Җанибәк хан, аның патшалыгын Ходай сакласын!», икенче ягына «Булат Тимер Тугла би улы» дип язылган.

1367 елда Болгарның югары катлам вәкилләре, Булат Тимердән читләшеп, Хәсән бәк ягына авышалар. Булат Тимернең Мамай йогынтысында булган күрше Городец кенәзлегенә оештырган яулары да уңышсыз тәмамлана. Ул исән калган гаскәре белән Түбән Идел якларына китеп котылмакчы була, ләкин Газиз хан сугышчылары белән бәрелештә һәлак була. Шулай итеп, Болгарның мөстәкыйльлегенә чик куела.

Югарыда китерелгән фактларның барысы да Алтын Урда дәүләтенең тәхет чуалышлары нәтиҗәсендә әкренләп зәгыйфьләнә, элеккеге бердәмлеген югалтып, таркала һәм бүлгәләнә башлавына ачык мисалдыр. Көчсезләнгән дәүләтне, әлбәттә, күршеләре тынычлыкта калдырмыйлар. 1360, 1366, 1374, 1375 рус ушкуйниклары Идел буйлап урнашкан болгар шәһәрләрен талыйлар, яндыралар, соңгы очракта хәтта Әстерханга кадәр төшеп җитәләр. Алтын Урда үзенең элеккеге данын, халыкара абруен югалта.



Аксак Тимер.

ТУКТАМЫШ ҺӘМ АКСАК ТИМЕР

Туктамыш – заманында Мангыстауда (Мангышлакта) әмир булып торган һәм Күк Урда ханы Ырыс тарафыннан буйсынырга теләмәгәне өчен җәзалап үтерелгән Туйхуҗаның улы. Ул яшьлеге аркасында гына җәзадан котылып кала, әмма Ырыс хан кулы астында яшәүнең куркыныч булуын аңлый. Форсаттан файдаланып, Сәмәрканд әмире Тамерлан – Аксак Тимер янына качып китә.

Аксак Тимер Туктамышны үз хозурына ала, аңа төрле яклап ярдәм кулы суза: кыйммәтле бүләкләр бирә, Отрар һәм Сыгнак кебек зур калалары булган Сауран өлкәсенең ханы итеп куя. Моны ишетеп, Ырыс хан Туктамышка каршы сугыш ача һәм аның гаскәрләрен

тулысынча тар-мар итә. Туктамыш, Сауранны калдырып, Аксак Тимер янына кайтып егыла. Тегесе бу хәлне тыныч кабул итә, уңышсызлыкка очраган егетнең күңелен күтәреп, янәдән Сауранга озата. Бу хәл Ырыс ханның ачуын чыгара, ул, шундук зур гаскәр туплап, үзенең улы Туктакыяны Туктамышка каршы җибәрә. Бу сугыш та Туктамыш файдасына булмый, ул Сәмәркандка яраланып кайта, әмма Аксак Тимер аны хөкем итми, уңышсызлыкларының сәбәбен егетнең тәҗрибәсезлеге белән аңлата, киләчәккә өмет баглый. Чыннан да, Ырыс ханның икенче улы Тимер Малик башлап җибәргән сугышта, ниһаять, Аксак Тимер һәм Туктамыш гаскәрләре олы җиңүгә ирешә.

Аксак Тимернең Туктамышны, җитди уңышсызлыкларына да карамастан, үз канаты астына алуы җиңел аңлашыла: егет – Чыңгызлар нәселеннән, киләчәктә Алтын Урда җирләрен үзенең биләмәләренә кушуда аның ярдәменә ышанырга мөмкин булачак.

Туктамыш хан 1380 елның язында, гаскәр туплап, Түбән Иделгә юнәлә. Максаты – Алтын Урданың (Ак Урданың) үзәк биләмәләрен басып алып, хан тәхетенә утыру. Вакыйгалар – Туктамыш файдасына. Ырыс хан һәм аның уллары сәяси тормыштан төшеп калалалар, юк ителәләр, тәхеттә – Туктамыш яклы Гарәбшаһ хан – җитди көндәш түгел. Төп көндәше – Мамайның язмышы Куликово сугышында ахыргача хәл ителә. Тәхеткә юл ачыла, дияргә була, өстәвенә, әле хәрбиләр һәм югары катлау әһелләре арасында аның яклылар көннән-көн күбәя бара. Иң мөһиме – ул әле һаман Аксак Тимер канаты астында.

ТУКТАМЫШ – АЛТЫН УРДА ХАНЫ

Тәхеткә ул 1380 елда утыра. Төп максаты – таркалып бара торган дәүләтне бер хан кулына берләштерү, Алтын Урданың хәрби көчен, икътисадый куәтен арттырып, чит дәүләтләр алдында нык какшаган абруен яңадан торгызу. Һәм шушы программаны тормышка ашыру өчен, Туктамыш кулган килгәннең барысын да эшли. Төрле юллар белән Литва һәм Польшаның Алтын Урда җирләренә экспансиясен туктатуга ирешә. Алтын Урда җирләре элеккеге чикләренә кайта. Кырымдагы Генуя һәм Венеция колонияләре яңа ханның таләпләрен берсүзсез кабул итә.

Рус кенәзләре белән эш бераз катлаулырак бара, чөнки Куликово кырындагы җиңүдән соң алар үзләрен бик горур һәм бәйсез тота башлый. 1382 елда Мәскәүгә оештырылган яудан соң барысы да тәртипкә салына – кенәзләр Сарай казнасына элеккегә караганда да күбрәк салым түләргә мәҗбүр ителәләр.

Туктамыш илнең эчке хәлен, беренче чиратта, иктисадын тотрыклыландыру буенча да зур эш алып бара. Ул тиз арада акча реформасы үткәрә, бөтен ил күләмендә бердәм акча һәм үлчәү системасы кертелә. Чит илләр белән сәүдә яңадан күзгә күренеп җанлана башлый. Төркия, Мисыр һәм башка күп кенә илләр белән дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштырыла.

Әмма Сәмәрканд әмире белән мөнәсәбәтләр бозылуга бара. Туктамыш Аксак Тимернең күрше дәүләтләрне буйсындыруга юнәлдерелгән, Алтын Урдага куркыныч янаган тышкы сәясәтен хуплый алмый, мөһим сәүдә юллары үтә торган Көньяк Кавказ, Азәрбайҗан һәм Иран җирләре өчен Аксак Тимер белән сугышырга мәҗбүр була. 1385 елгы сугышта Аксак Тимер гаскәрләре өстенлеккә ирешә, алар хәтта Алтын Урда җирләренә дә үтеп керә. Аксак Тимернең Алтын Урда биләмәләренә кергән Хәрәзем җирләрен басып алуы да ике як арасында тирән каршылыклар, ризасызлыклар китереп чыгара. Туктамыш белән Аксак Тимер арасында озак елларга сузылган сугыш башланып китә.

Алтын Урданы нык көчсезләндергән сугышларның берсе 1391 елның 18 июнендә Урта Иделдә, Кондырча елгасы буенда (бу җирләр хәзер Самара өлкәсенә керә) Аксак Тимер гаскәрләренең җиңүе белән тәмамлана. Мондый каты бәрелешне көтмәгән Туктамыш киләчәктә Аксак Тимер белән сугышка кермәскә карар бирә. Әмма тегесе башкача уйлый: Алтын Урданы тулысынча тар-мар итмичә, Урта Азиядә, Днепрдан башлап Урал буйларына кадәр сузылган кыпчак далаларын да кертеп, көчле дәүләт төзеп булмаячак.

Җучиләр Олысын һәлакәт алдына куйган соңгы сугыш 1395 елның апрель аенда башлана. 300 меңләп гаскәре белән Аксак Тимер Алтын Урданың үзәк районнарына юнәлә. Күп кенә эре шәһәрләр, шул исәптән Сарай, Хаҗитархан, Азак, Маҗар җир белән тигезләнә, хәрабәгә әйләнә, дистәләрчә мең кеше үтерелә, коллыкка төшә. Алтын Урда яңадан торгызып булмаслык дәрәҗәдә талана.

Аксак Тимер Сәмәркандка кайтып китә, ә Туктамышның сәяси хаталары аркасында төзәлмәслек яра алган Алтын Урдада төрле феодаль төркемнәр арасында тәхет өчен көрәш дәвам итә.

Туктамыш 1406 елда Себердә, Төмән тирәсендә, Шадибәк хан тарафыннан үтерелә. Бу вакытта аңа 60 яшьләр чамасы була.

Бередә 1391 елда Алтын Урда ханы Туктамышка каршы яу чапкан Аксак Тимернең хәрби лагере урнашкан була.

ЗАМАНДАШЛАРЫ **ИСХАКЫЙНЫ** НИЧЕК ХӘТЕРЛИ?

Гаяз Исхакыйның шәхесе һәм иҗаты турында бик күп сөйләнде һәм язылды. Кискен борылышларга нигезләнгән детективны хәтерләтә ул. Җитмәсә, географик колачы һәм иҗтимагый резонансы да гаять киң вә зур. Без бу юлы, Исхакыйга ияреп, кече ватанны глобаль яссылыкка күчердек – Чистай, Казан, Петербург, Финляндия, Франция, Германия, Маньчжурия, Япония, Төркия… Бигрәк тә бу шәхеснең эмиграциядән соңгы елларына җентеклəбрәк күз салырга булдык. Сүзне нигездә Исхакыйны читтә белгән һәм күреп калган затларга, кызына бирәсе килде.

Әзерләде:
Луиза Янсуар

1878 елның 23 февралендә (иске стиль белән – 10 февральдә) Казан губернасы Чистай өязенә кергән Яуширмә авылында зыялы гаиләдә дөньяга килә ул. Замандашлары әйтүенчә, әтисе Гыйләҗетдин «Чистай тарафларында гыйлеме белән шөһрәт тапкан» мулла, әнисе Камәрия исә ул якларда шулай ук белеме һәм азатлык идеяләре белән танылган Морат мулла улларының берсе – Мөслимвәли хәзрәт кызы була. Кайбер балалары дөньядан иртә китү сәбәпле, Гыйләҗетдин белән Камәрия бөтен өметләрен кечкенә Гаязга баглый: аңа гыйлем һәм тәрбия бирүне приоритет итеп куя. Гаяз үзе дә бик зирәк булып чыга, яшьли үзе кебек балалар арасында үткенлеге белән аерылып тора. Инде биш яшендә өйләрендә укырга-язарга өйрәнеп, әбисе Мәхфүзә остазбикәдән «Иман шарты»ннан сабак ала һәм гарәп китапларыннан ул вакытта танылган «Кырык хәдис»кә җитә. 1890 елда Чистайның «Камалия» мәдрәсәсенә укырга керә, 1893 елда Казандагы Күл буе мәдрәсәсенә күчә. Тиз арада мәдрәсәдәге иң яхшы укучы шәкертләрнең берсе булып танылa. Ул һич тә мәдрәсә программасы белән канәгатьләнми, үзлегеннән белемен күтәрү белән шөгыльләнә. Төрки дөньяда танылган «Тәрҗеман» газетасын даими укып бара, төрек телендәге әсәрләр белән таныша. 1897 елда, остазы Һади Максудига ияреп, Печән базары мәхәлләсенә, аннары Яңа бистәдә Фатих Әмирханның әтисе Зариф хәзрәт ачкан мәдрәсәгә күчә, анда бераз акча эшләү нияте белән хәлфәлек тә итә башлый.

Казан төрмәсендә. 1907 ел.

Шул чакта аңарда рус һәм Көнбатыш әдәбиятлары белән танышу ихтыяҗы туа. Ә моның өчен рус телен әйбәт белергә кирәк була. 1898 елда ул рус мәктәбенә укырга керә. Татарлар арасында миссионерлык итү нияте белән ачылган Татарская учительская школа алдынгы карашлы татар яшьләрен үзенә җыйган уку йорты буларак билгеле. Гаяз Исхакый белән бергә анда Һади Максуди, Хөсәен Ямашев, Гафур Колахмәтов һ.б. татар дөньясының әйдәп баручы көчләренә әвереләчәк шәхесләр укый. Бирелә Гаяз үзенең белем алу даирәсен киңәйтә бара. Рус һәм Көнбатыш әдәбиятлары белән ныклап кызыксынып китеп, Иван Тургенев, Лев Толстой, Ги де Мопассан, Оскар Уайльд кебек күренекле әдипләрне үзләштерә. Алар аның рухи дөньясын, эстетик зәвыгын баетып, үстереп кенә калмый, әдәби иҗат белән шөгыльләнү теләген дә тудыра. Ул яза башлый. Нәтиҗәдә, әлеге мәктәптә укыган елларында булачак әдипнең беренче иҗат җимешләре – «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1899), «Кәләпүшче кыз» (1900), «Бай углы» (1903) повестьлары, «Өч хатын берлә тормыш» (1900) пьесасы дөнья күрә.

1902 елда Исхакый Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә мөгаллим булып килә.

Фотолар Гаяз Исхакыйның архив материалларыннан

ӘДӘБИЯТ ИНСТИТУТЫ ЫСУЛЫНДА ЭШЛӘДЕМ...

«Мәдрәсәдә бер-ике атнадан соң дәресләр башланды һәм мөгаллимнәр дәресләрне үзләренә бүлеп алып, калганнарын миңа бирделәр. Бөтен сыйныфларда хисап, һәндәсә, гомуми тарих, табигать, әдәбият дәресләре – һәммәсе миңа эләкте. Башка мөгаллимнәрнең дәресләре көн дә өч, бик күп булса, дүрт сәгать булса һәм атнаның бер көне буш булса, миңа атнаның бөтен көннәренә алтышар сәгать дәрес туры килә һәм бөтен көннәрем иртәдән ахшамга кадәр мәдрәсәдә мәшгуль иде (өйләгә кадәр дүрт, өйләдән соң ике дәресем бар иде). Моннан башка атнаның ике көнендә, нәүбәтче буларак, кичләрен дә мәктәптә калмакта идем.

Бу программа аз кеби, әүвәлге мәдрәсәнең бер почмагына өелгән китапханәне тәртипкә салып кулыма алдым һәм югары сыйныф укучылары белән әдәбият институты ысулында эшли башладым».

Гаяз Исхакый истәлекләреннән.

Киеренке мөгаллимлек эше белән бергә, Исхакый мәдрәсәнең җәмәгать тормышында да актив катнаша. Ашханәдә, йокы бүлмәләрендә тәртип урнаштыра. Шәкертләрнең аң-белемен арттыру максаты белән яңа фәннәр укытуны кертә, атна саен әдәби кичәләр уздыра. «Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салган Әхмәт Хөсәеновның васыятьнамәсен раслау комиссиясе әгъзасы буларак, әлеге бай васыять итеп калдырган ярты миллион сум акчаны мәгариф эшләрендә файдалануда катнаша.

Аның һәр нәрсәдә гаделлеккә, хакыйкатькә омтылуы шәкертләргә бик нык тәэсир итә. Актив һәм инициативалы шәхес буларак, Исхакый үз тормышыннан канәгать булып, йокымсыраганрак хәлдә яшәгән мәдрәсәне уятып җибәрә һәм аның яшәешенә заман рухы өрә. Үз җайларына яшәргә күнеккән мөгаллимнәргә Исхакыйның мәдрәсә тормышын болай «болгатып» җибәрүе, аларның тынычлыгын алуы ошамый, әлбәттә. Һәм алар үзе дә тынгысыз, башкаларга да тынгы бирмәгән бу «ала карга» мөгаллимнән тизрәк котылу ягын карыйлар. Исхакый мәдрәсәдән чыгарыла, кабат эшсез кала. Шушы арада ул «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен тәгәлли һәм аны дөньяга чыгару эшенә керешә.

1903 елның җәендә Исхакый Казанга кайта һәм университетка керергә әзерләнә башлый. Әмма аның бу теләгенә әти-әнисе каршы чыга һәм аны көчләп диярлек авылга алып кайтып китәләр. 1904 елда ул кабат Казанга китә һәм көчәеп киткән революцион хәрәкәттә катнаша башлый. Шул ук елны Чистайдан сайланган мөселман делегатлар составында Петербургка бара. 1905 елның октябрендә Исхакыйны «Казан мөхбире» газетасына эшкә чакыралар. Әмма ул газетаның мәсләге белән килешеп бетми. Үз мәсләгендә, үзе теләгәнчә язар өчен фикердәшләре белән үз газеталарын чыгару ниятенә килә. Башта «Хөррият» исемле яшерен газета чыгаралар, әмма ул бераздан ябыла. Аннары «Таң» исемле газета чыгару теләге туа. Аңа рөхсәт сорап хакимияткә мөрәҗәгать итәләр. Ике айдан соң рөхсәт бирелмәве турында кәгазь алалар. Шуннан соң Гали Путиляков дигән танышлары нәширлегендә «Таң йолдызы» исемле газета чыгаруга рөхсәт сорыйлар. Бу юлы аларның үтенече канәгатьләндерелә. «Таң йолдызы» исеме алса да, газетаны көндәлек тормышта «Таң» гына дип йөрткәннәр, ә аны чыгаручы социалист-революционерлар тарихка «таңчылар» булып кереп калалар. Газетаның рәсми мөхәррире Сәгыйть Рәмиев була. Исхакыйга исә бу вакытта полициядән качып яшәргә туры килә. Нәкъ менә ул газетаның төп юнәлешен һәм эчтәлеген билгели. «Таң йолдызы» 1906 елның 18 маенда чыга башлый. Аның битләрендә Исхакый үзенең иҗтимагый-сәяси омтылышларын чагылдырып килә.

«Таң йолдызы» киң яктырткан «Мөселман иттифакы» съездында әйдәп йөрүчеләрнең берсе дә Исхакый була. Берничә мәртәбә чыгыш ясап, ул үзен хезмәт халкы мәнфәгатьләрен кыю яклаучы итеп күрсәтә. Матбугат битләрендә, һәртөрле җыелышларда, митингларда патша хакимиятенә каршы чыгышлар ясый. Хакимият аны эзәрлекли башлый. 1906 елның 30 октябрендә Исхакый дусты Сәгыйть Рәмиев фатирында кулга алынып төрмәгә ябыла. 1907 елның октябрендә ул Архангель губернасына өч еллык сөргенгә җибәрелә. 1908 елның урталарында сөргендәге ике яһүд белән көймәдә Пинегадан качып Петербургка юл тота. Тиз арада «Теләнче кызы»ның икенче өлешен яза, Пинегада языла башлаган «Кыямәт» комедиясен тәгәлли һәм «Җәмгыять» комедиясен иҗат итә.

УНӨЧЕНЧЕ ДӘРӘҖӘ

Җәйге бер көндә (Исхакый бик авыру иде инде ул чакта) аңа манка пешереп бирдем, чөнки ашказаны фәкать йомшак ризыкларны гына сеңдерә ала иде. Ашаганнан соң, «ашказаным авырта» дип, караватка ятты. Мин аңа ашказанына тигән ризык ашатканыма бик борчылдым. Шуны әйткәч: «Борчылма, кызым, минем авыртуларым аннан түгел», дип, мине юатты. Сөргеннән качканнан соң тормышында булган бер вакыйганы сөйләде: «Рус төрмәләрендә сәяси тоткыннар унөченче дәрәҗәдә иде. Алардан алда мошенниклар, караклар, кеше үтерүчеләр килә иде. Аш-су таратканда башта аларга бирәләр, шулай итеп, унөченче чиратка җиткәндә, инде һәр табактан унике кеше ашаган, һәр кашык унике авызга кереп чыккан була. Табигый ки, һич тә юылмаган килеш... Төрмә ашлары бик тә рәтсез булуга карамастан, ашказаныбызга җылы берәр нәрсә ашарга мәҗбүр идек. Мин төрмәгә эләккәннең беренче өч көнендә табак-кашыклардан җирәнеп ашамадым. Аннан соң инде чарасызлыктан ашарга мәҗбүр булдым».

Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт Чагатай истәлекләреннән.

1909 елның язында Исхакый яшерен рәвештә Төркиягә барып чыга. Истанбулда «Тормышмы бу?» романын яза. 1909 елның көзендә яшерен рәвештә Төркиядән Петербургка кайта. Хакимияттән качып яшәргә мәҗбүр булуы белән бергә аның матди хәле дә авырлаша. Язылган әсәрләрен бастырып чыгара алмый. Рус әдәбияты һәм мәдәнияте белән ныклап кызыксынып китә. Рус язучыларының әсәрләрен күпләп укый, аларның һәртөрле җыелышларына йөри, конференцияләрдә катнаша, вольный университетларда үзен кызыксындырган фәннәр, бигрәк тә юриспруденция һәм фәлсәфә буенча лекцияләр тыңлый. Болар аның рухи культурасын тагын да үстерә. 1910 елның язында ул шулай ук яшерен рәвештә Финляндиягә чыга һәм анда җәен уздыра. Финляндиядәге милләттәшләренең җылы мөнәсәбәте аның күңелен



Истанбулда Йосыф Акчура белән. 1931 ел.

Берлинда кызы Сәгадәт һәм кияве Таһир Чагатай белән. 1933 ел.

Архангельскида сөргендә. 1907–1908 еллар.

Танылган япон тюркологы Кочи Окубо белән. Токио. 1934 ел.

күтәреп җибәрә. Һәм монда ул тагын дәртләнеп иҗат эшенә керешә, нәтиҗәдә, кыска гына вакыт эчендә «Мулла бабай» романы, «Фамилия сәгадәте» исемле хикәяләр циклы языла.

Финляндиядәге милләттәшләренең үзенә бик җылы һәм кайгыртучан мөнәсәбәтләреннән дәртләнеп, Исхакый анда чакта язылган әсәрләрен бастыруны оештыру белән дә шөгыльләнә. Аерым алганда, ул Казандагы «Гасыр» нәшрияте белән эшлекле мөнәсәбәт урнаштыра һәм әлеге нәшрият хуҗалары аның «Сайланма әсәрләр»ен чыгарырга алына. 1910 елның көзендә Исхакый янә Истанбулга килә һәм анда бер-бер артлы «Сөннәтче бабай», «Кияү» повестьларын, «Шәкерт абый» хикәясен яза. Исхакыйның Истанбулдагы кыска вакытлы, әмма шактый нәтиҗәле иҗатының йөзек кашы «Зөләйха» трагедиясе була.

1913 елның мартында Россиядә Романовлар хакимиятенә 300 ел тулу уңаеннан сәяси тоткыннарга амнистия игълан ителә. Шушы амнистиягә эләгеп, 4 апрельдә Исхакый да азат ителә. Бу хактагы хәбәр тиз арада киң таралыш ала һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан шатланып кабул ителә.

«УЛ ПЕТЕРБУРГТА БУЛЫРГА ТИЕШ...»

«Амнистиянең файдасы аңа да тия, бары тик Петербургта яшәү шарты белән ул сөргеннән азат ителә. Казанга кайтыр өчен әле 7–8 ел көтәргә кирәк була. Шуңа да карамастан, беренче эше итеп, качып-посып булса да, туган ягына кайту мөмкинлегенә таба. Казанда аны туганнары һәм танышбелешләре шатланып каршы алып, шәһәр буйлап ябык арбаларда йөрткәләр, ябык пәрдәләр артында кунак итәләр. Кичләрнең берсендә театрда аның пьесасы куела. Казан мөселманнары Гаязның шәһәргә килүен һәм кич театрда булачагын ничектер белеп алалар. Тамаша башланыр алдыннан, залда утлар сүндерелеп, Исхакыйны яшертен генә ложага алып керәләр.

Килгән халык моны күреп-белеп ала да бик каты кул чаба башлый. Әлбәттә, рус полициясенең спектакль башланмас борын ук алкыш кубудан шикләнәчәге билгеле. Шуны истә тотып, режиссер Габдулла Карый ложага йөгереп керә дә Гаязга: «Тизрәк халыкка сәлам бир, юкса жандармнарның шиге тагы да артачак», – ди. Исхакый ложаның пәрдәсен бераз ача төшә дә халыкны сәламли. Тамашачылар аягүрә басалар, кул чабулар көчәя. Ул арада спектакль башланып та китә. Жандармнар бу кадәр алкышланган кешенең, һичшиксез, Гаяз Исхакыйдан башкасы булмавын тәмам аңлыйлар. Габдулла Карый, янә Гаяз янына килеп, театр бинасын полиция камап алганын, мөмкин кадәр тизрәк качарга кирәклеген әйтә.

Спектакль тәмамлана, әмма тамашачылар язучының кайдалыгын, полициядән кача алмавын белмиләр бит әле. Даһи режиссер Габдулла Карый артистларга, яңадан сәхнәгә чыгып, ни булса да уйнарга, тамашачыларга исә таралмаска куша. Исхакыйны мең бәла белән сәхнә артына алып чыгалар һәм, өй түбәләреннән йөреп, ышанычлы фатирга яшерәләр. Гаязның театрдан исән-имин китә алу хәбәре килә, һәм халык тарала башлый. Полиция, залга кереп, «Исхаков, Исхаков» дип күпме эзләсәләр дә, билгеле, аны таба алмыйлар. Габдулла Карыйдан сорау алалар, ул исә, Гаяз Исхакыйны күрмәдем, хәзерге вакытта ул Петербургта булырга тиеш, дип, тыныч кына җавап бирә».

Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт Чагатай истәлекләреннән.

1917 елгы Февраль революциясен Исхакый зур өметләр белән хуплап каршы ала. Һәм аның бу өметләре аклана да башлый. Барыннан да элек, ул күптән хыялланган сүз ирегенә бирелә, матбугатка цензура бетерелә. Революция биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, Исхакый ике ел элек хакимият тарафыннан тыелган «Ил» газетасын кабат чыгара башлый. Һәм, ниһаять, моңа кадәр рәсми рәвештә тыелып килгән «Зөләйха» пьесасына да сәхнәгә юл ачыла. Ул беренче тапкыр «Сәйяр» труппасы тарафыннан күренекле артист һәм режиссер Габдулла Кариев бенефисы рәвешендә 1917 елның 17 мартында Казанның Зур драма театры сәхнәсендә күрсәтелә. Җәмәгатьчелек бик җылы кабул иткән бу спектакль матбугатның да игътибарын бик тиз җәлеп итә.

Исхакый Казанга «Зөләйха» спектаклен карарга Мәскәү «Мөселман комитеты» рәисе сыйфатында Россия мөселманнарының беренче съездын әзерләү белән шөгыльләнгәндә килә. Россиядә Февраль революциясе тудырган шартларда татар милләтенең алга барыр юлларын билгеләячәк бу съезд эшендә ул үзенең иҗаты белән катнаша һәм аңа күтәренке рух бирә. Икенче съезд шул ук елның августына кадәр үткәрелергә тиеш була. Һәм ул июнь аенда Казанда үткәрелә. Әмма илдә иҗтимагый-сәяси хәлнең киеренке һәм катлаулы булуы аркасында, анда Урта Азия, Кавказ һәм Кырым вәкилләре катнаша алмый. Шунлыктан икенче съезд Идел-Урал төбәге мөселманнарын, ягъни татарлар белән башкортларны күздә тотып эш итә.

Икенче съезд белән бер үк вакытта Казанда мөселман руханилары җыены һәм Бөтенроссия мөселманнарының хәрби съезды да эшли. Һәркайсы үз мәсьәләләрен тикшергәннән соң, өч съезд бергә берләшеп, Идел-Урал өчен милли-мәдәни мөхтәрият игълан итәләр. Аның төп кануннарын билгеләү өчен Милли Мәҗлес чакыру турында карар кылына.

Милли мәҗлес инде бөтенләй яңа иҗтимагый-сәяси шартларда, илдә Октябрь революциясе булып, хакимият большевиклар кулына күчкәч үткәрелә. Ул Уфада 1917 елның 22 ноябреннән 1918 елның 11 гыйнварына кадәр эшли. Анда тикшерелгән күпсанлы мәсьәләләр арасында иң мөһиме ничек итеп милли дәүләтчелекне төзүгә кагылышлысы була.

Әмма большевиклар татарларның милли азатлык һәм мөстәкыйльлек хәрәкәтенә чик куялар. Милли мәҗлес белән Милли идарәнең качып котыла алган депутатлары һәм әгъзалары Себердәге Кызылъяр (Петропавел) шәһәренә барып чыгып, анда кече Милли мәҗлес оештыралар, Милли идарәнең эшен дәвам итәләр. Бирездә Исхакый «Маяк» исемле милли газета чыгара башлый. Шушы шәһәрдә әдип үзе туган илендәге соңгы әдәби әсәре дип исәпләнгән «Юлсызлар» пьесасын яза.

Кызылъяр шәһәреннән китеп, ул большевиклар кулыннан котыла алган татар милләтчеләре белән бергә 1918 елда Ерак Көнчыгыштагы чикне үтеп чыга. Шуннан инде аңа ватанына үзе исәндә кире әйләнеп кайту насыйп булмый...

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

«Берлинда яшәгән чакта илдәш шәкертләр катнашы белән узган җыелышта «Олы кешенең олы көне» дигән хикәясен укыды ул. Һичшиксез, әсәрнең төп каһарманы – Гаяз Исхакый үзе. Сюжет буенча, танылган бер язучы зур бер чакырулы мәҗлестә катнаша. Анда җыелган кешеләр аны алкышлыйлар, зурлыйлар. Һәммә кеше язучыны үз өстәлләренә килеп утыруын сорап әйтерсең бер-берсе белән ярышалар, һәр өстәлдә чәй белән сыйларга атлыгып торалар. Ләкин язучы берничә көн ашамаган булса да, бу чәйдән бик тиз туя. Ахыр килеп, өенә кайткач, караваты астындагы буш шешәләрне чыгара, боларны кибетчегә биргәч, күпмерәк акчага тиячәген хисаплый. Һәм сөенә, чөнки ул акчага, ичмасам, бер көнлек ризык ала алачагын белә. Һәрхәлдә, хикәянең төп сюжеты Исхакыйның шәһәрдән шәһәргә ялган паспорт белән каңгырап йөрүе фактларына нигезле булса кирәк. Мәсәлән, Петербургта ул айларча шундый шартларда яшәгән».

Сәгадәт Чагатай истәлекләреннән.

«1934 елда Гаяз Исхакыйның Харбин шәһәренә килүен халкыбыз көтеп тора. Мин бишьеллык башлангыч татар мәктәбенең соң сыйныфында укыйм. Яшем – уникe. Безнең кебек мәктәп яшендәге балаларга Исхакыйның әсәрләре хакында әдәбият дәресләрендә мәгълүмат бирелгән булса да, балалык бит, безгә кызыклысы Исхакыйның нинди булуы иде.
Әхмәт Лаиш, озын буйлы, эре гәүдәле, шәһәрдә танылган спортчы булганга, Исхакыйның шәхси сакчысы итеп билгеләнгән иде. Чөнки Исхакыйның фикерләренә каршы булган рус монархистлары аңар каршы хәрәкәт итәләр иде. Рус монархистлары «бер бүленмәс» Россия фикерләрендә иделәр вә Исхакыйны Руссияне бүләргә теләүче бер кеше итеп күрәләр иде. Автомобильләр килеп җитте. Исхакый да автомобильдән чыкты. Халык бертавыштан: «Хуш килдегез, хуш килдегез, исән-саумысыз!» – дип әйтте. Соңра халык бинага керде. Шунда ярты сәгать калып, халык белән күрешкәч, Исхакый шәһәрнең иң яхшы отеле «Модерн»га оешманың картлары белән бергә китте. Балалар күңелендә исә чәчләре агарып бара торган, көләч йөзле, урта буйдан озынрак, тулы гына гәүдәле Исхакый хатирә булып калды.
Оешма бинасының зур залында җыелышлар була башлады. Исхакый җыелган халыкка тарихыбызның борынгы вә шанлы булуын, бүгенге хәлебезнең сәбәпләрен, киләчәктә нинди юлдан барырга тиешлекне аңлатты. Ул һәркем аңлый алырлык татар телендә, кайбер вакыт арага кызыклы сүзләр дә кыстырып, ике-өч сәгать һичбер язуга карамыйча сөйли, вә бу сөйләүләр тыңлаучыларны һич арытмый иде».

Садри Максудиның кызы, Төркия дипломаты, тарихчы Гадилә Айдә истәлекләреннән.

«Берлинда яшәгән бик мәшәкатьле, михнәтле көннәрдән берсендә мин аңа: «Син нәкыш сәнгатен аңлыйсың бит, бар музейга, ачылып китәрсең», – дип әйтеп карадым. Әмма ул минем тәкъдимемне кире какты: «Юк, кызым. Мин бик күп музейларны карадым. Луврда да бик күп сәнгать шаһ әсәрләрен күрдем-күзәттем. Хәзер ул музей дигән нәрсә газапларыма (нервларыма) тия. Алга киткән милләтләр иске-москы чүпрәкләрен, тишекле-тошыклы башмакларын да күргәзмәгә куя, шулай итеп мәдәни үзенчәлекләрен саклый. Без исә һәртөрле хокуктан мәхрүм, хәтта җаныбызны да саклый алмыйбыз».
Гаяз Исхакыйның бик аз билгеле якларыннан берсе – рәсем сәнгате белән кызыксынуы. Ул бу сәнгатьне бик яхшы аңлый иде. Зур калаларда ачлы-туклы яшәп, урамда күренеп, полиция күзәтүенә һәм эзәрлекләвенә дучар булудан курыккан качак әдип бераз юану-тынычлану максаты белән музейларга еш кергәләгәндер».

Сәгадәт Чагатай истәлекләреннән.

«Берлиндагы татарлар һәр якшәмбе көнне безнең өйдә җыелыша иде. Иң азы 20–25 кеше була иде. Минем әнием Камилә ханым өйлә ашы өчен егерме кешелек итле, кишерле пылау пешерә, тау кебек пылау өстәлгә килә иде.
Аш ашау вакыты бик күңелле була иде. Моның шулай булуында Гаяз Исхакыйның роле зур иде. Чөнки иң күп сөйләшкән кеше ул. Өй иясе булган әтием күп сөйләшми, башкаларны тыңлый. Гаяз әфәнде исә, җыелышның рәисе кебек, анекдотлар сөйли, көлдерә иде. Күп еллардан бирле күрмәгән кызы белән кавышу да Гаяз әфәндене ул вакыт шат вә кәефле иткән булыр.
Тагын бер хатирәм Истанбул белән бәйле. Бей углы кварталында ничектер Гаяз Исхакыйны очраттым. Кулында савыт белән катык. «Моны кая алып барасыз?» – дигән соравыма каршы: «Сихәтем өчен докторлар катык тәүсыя иттеләр, – диде. – Көн саен катык ашыйм». Бу 1951–1952 еллар булгандыр. Ашказаны авыруы инде башланган иде. Моны ул әтиемә Япония белән Кытайдагы ашлардан дип аңлаткан иде.
Тагын моны да әйтим. Гаяз әфәнде балаларны бик ярата, алар белән сөйләшә белә иде. Әтиемнең: «Гаязга турун күрергә насыйп булмады. Шуңа күрә балаларны сөя», – дигән сүзләре хәтеремдә калган».

Маһирә Байчура истәлекләреннән.

ТАТАРСТАНДАГЫ КИНОБУМ. ДӘВАМЫ БУЛАЧАКМЫ?

Казанда уза торган мөселман кинофестивале инде күптән мөселман илләрен генә түгел, ә Европа белән АКШ кинематографистларын да берләштереп өлгерде. Ә безнең Татарстан киносы өчен мөселман кинофестивале – ел саен уза торган сынау да ул. Кайсы юнәлештә үсәбез, кая юл тотабыз без? Быелгы кинофорумда да тестны уза алдыкмы?

Автор:
Ольга Туманская

«МИҢА ИҖАТ ИТҮ ОШЫЙ»

Кулында буяу тутырылган баллон. Кара тамчылар, чәчрәп, ак фонны каплый. «Мин моны ни өчен эшлимме? – дип сорый үзгәртелгән кадр артындагы тавыш. Һәм шунда ук җавап та бирә: Дөресен генә әйткәндә, миңа иҗат итү ошый…» Өч минутка сузылган кыска гына вакыт эчендә безгә шәһәр рәссамының соклангыч һәм үзенчәлекле сәнгать әсәрләре тудыруы, аларны шәһәргә бүләк итүе турындагы гаҗәеп тарихны күрсәтәләр. Картиналар турында сүз бара, дип уйларсыз, билгеле. Әмма юк, ялгышасыз, сүз чүп-чар савытлары турында! Соңгы кадрлар: камера Казанның түбәләре буйлап йөзеп бара. Берсендә кемдер басып тора. Йөзен күрергә тырышам, әмма аның урынында – битлек. «Минем исемем Алеша», – ди ул. Тавышы хатын-кызныкы. Интрига шул урында иң югары ноктасына җитә. Пәрдә төшә.

Шәхсән минем өчен «Мин моны нәрсә өчен эшлим» фильмы XIV Халыкара мөселман киносы фестиваленең иң гаҗәеп һәм көтелмәгән призеры булды. Картина иң яхшы милли документаль фильм номинациясендә бүләк алды. Ләкин бу шаянкинаяле лента ни рәвешле форум концепциясенә туры килә соң? Менә шул сорау ачык калды… Бары тик Татарстанда эшләнгән булуы беләнме?

Фестивальнең программа директоры Сергей Лаврентьевның фикере буенча, республикада чыгарылган барлык фильмнар да, һичшиксез, Казан кинофестивалендә күрсәтелергә тиешләр. Бары тик шулай гына без, әйтергә кирәк, сыгылмалы һәм мәҗбүриятне эшкә җикмәгән рәвештә, кино төшерүне эшләтеп җибәрә алабыз. Фестивальнең 14 еллык тәҗрибәсе моны инде раслады.

Бу көздә Татарстан фестивальгә 40 ка якын картина тәкъдим итте! Шуларның уналтысы конкурс программасына кертелде. Төп номинацияләрдә җиңү яулар өчен тулы метражлы уен фильмнарыннан Рамил Фазлыев һәм Әмир Галиәскәров режиссерлык тандемында иҗат ителгән «Мулла» көрәште. Шул ук Әмир Галиәскаровның һәм Насыйр Юрушбаевның кыска метражлы «Ата йорты» лентасы «Россия молодая» номинациясенә кертелде. Форматы һәм жанры буенча гаять төрле булган ундүрт фильм гомуми милли конкурс өчен берләштерелде. Тагын ике дистәгә якын лента халыкара фестивальнең конкурстан тыш кысаларындагы секцияләрдә тәкъдим ителде. Әмма моның белән генә дә төгәлләнмәде. «Казан премьералары» проекты тамашачыга әле яңа гына әзерләнеп беткән (әзерләнеп җитеп килгән) картиналарның бер өлешен күрсәтергә кирәк тапты. Бу ленталарның күбесе әле җитештерүнең соңгы этапларында, ягъни постпродакшн халәтендә. Бу ленталар арасында «Кире», «Остазбикә», «Әпипә», «Су анасы» һ.б. бар.

– Сезгә күпләр көнләшеп карый, эшегез эш кенә түгел, ә чып-чын хыял! – дип сәламлим мин Сергей Лаврентьевны. Абруйлы Россия кино белгече һәм тәнкыйтьчесенә гадәттә көненә берничә фильм карау бәхете тәтеп кенә тора.

– Китереп күрсәтегез миңа ул көнләшүчеләрне, бер-икесен генә булса да, ә аннары, көчләре калса, караган кинолар турында фикер алышырбыз, – дип, елмая ул.

– Татарстан фильмнары арасында кире кагылганнары күпме? – дип сорыйм.

– Юк, күп түгел. Без бөтенләй ярамаслыкларын гына кире бордык, ә менә картина күпмедер дәрәҗәдә җыелган, мантыйкка сыярлык икән, без аны, һичшиксез, алырга кирәк таптык. Күпчелек ленталарның профессионалларча төшерелүе куандырды. Бәхеткә, инде жанрның нәрсә икәнлеген аңлау барлыкка килде. Мәсәлән, элегрәк Татарстан режиссерлары еш кына документаль кино дип асылда репортаж жанрына караган продуктны тәкъдим итәләр иде. Хәзер мондый очраклар күзгә күренеп кимеде.

ЯШЕРЕН БӘЙЛӘНЕШЛӘР

– Мондый мулланы – япь-яшь һәм гашыйк руханины – миңа әле кинода күрергә туры килмәде, – дип, соклануын яшерми кемдер. – Ул балалар белән футбол уйный, аның белән шаярасы килә, көләсе… Ул шундый тормышчан! Минемчә, бу Көнчыгыш кинематографы өчен дә яңа күренеш.

«Мулла» фильмы күрсәтелгән көнне мөселман кинофестивалендә ике кинозал да шыгрым тулды. Аны төшерүчеләр белән очрашуга да халык шулай ук агылып килде. Төшерүчеләр командасы белән бергә сәхнәгә Марат Бәшәров

Фото: Ната Смирнова

та күтәрелде, ул фильмда эпизодик рольне уйнаган иде.

– Мин бу лентага, аңлашыла инде, әшнәлек буенча эләктем, – дип шаяртырга кереште ул. – Ә дөресен генә әйткәндә, шунда ук ризалаштым – Татарстан киносында төшәргә күптән хыялланам чөнки. Төшкәндә мин нибары ике көн генә эшләдем. Шулай килеп чыкты, бүген миңа, сезнең белән бергә, әлеге фильмның даһи финалын карау бәхете тәтеде. Залдагы тамашачылар елап утырды. Миңа калса, бу фильмны караганнан соң, кешеләр мәчетләргә бөтенләй башка төрле мөнәсәбәт белән барыр һәм иманга булган карашлары да үзгәрер.

Сүз уңаеннан, җирле кинога башкала кино йолдызын җәлеп итү – бүгенге көндә иң популяр алымнарның берсе. Шулай, Камил Ларин «Кире» картинасында төште, ә Владимир Вдовиченков – «Байгал»да. Яңгыравык исемнәр фильмның танылуына һәм киң массага таралуына ярдәм итә. Шуның белән бергә, безнең Татарстан актерларының уены башкаларныкылар даны астында күмелеп калмый – бу да зур сөенеч. Башка фильмнар турында әле кистереп кенә әйтә алмыйм, әмма «Мулла»да, минемчә, бу шулай. Рамил Фазлыев – төп рольне уйнаучы һәм, бер үк вакытта, режиссер да – ул бик нечкә образ тудыра алган. Аның мулласы, иң беренче чиратта, кеше. Ул гасабилана, икеләнә, әмма хакыйкатьне эзләүдән туктамый. «Син Аллаһка ышанасыңмы?» – дип сорый аңардан Налимә. Әмма бу сорауга аның анык кына җавабы юк. Шуның белән беррәттән, ул кешеләргә ышануын дәвам итә, һәм нәкъ менә бу ышану аның миссиясендә иң әһәмиятлеседер дә, мөгаен.

Шулай итеп, Татарстан кинематографы үсештә дип әйтә алабыз, бу хәзер хәтта гадәти тамашачының да күзенә ташлана. Бездә бүген бик җитди тәкъдимнәр бар икән, без аларны инкарь итә алмыйбыз инде. Сергей Лаврентьев елдан-ел кабатлап килә: фестивальнең булуы үзе үк кино үсешенә зур этәргеч булып тора. Төшерү индустриясе белән бәйге арасында турыдан-туры элемтә булмаса да, аның күзгә күренмәгән, яшерен тәэсире үзен сиздерә.

– Үзенең махсус фонды булган фестивальләр бар – ул фондлар кинога финанслар белән ярдәм күрсәтә ала. Казанда әлегә андый мөмкинлек юк. Әмма мондагы мохиттә кино белән бәйле дәртле бер «кайнау» барлыкка килде. Халыкара фестивальгә дөньяның барлык почмакларыннан кешеләр килә икән, бу, һичшиксез, зур стимуляция диган сүз! Әгәр без тиешле биеклекләргә инде күтәрелдек, дисәм, бу хакыйкатькә хилафлык китерү булыр иде. Юк әле! Тик шулай да дүрт тулы метрдагы картинабыз бар һәм алар инде сәнгати үзешчәнлек өлгесе генә түгел, ә чын профессиональ кино үрнәкләре. Мәскәүдә яки Питерда төшерелмәгәннәр, дип, ташлама ясауга да мохтаҗ түгелләр.

Сүз уңаеннан, Татарстан фавориты «Байгал» белән Лаврентьев Россиянең ачык кинофестивале «Кинотавр»да эшләгән вакытында таныша.

– Кызганыгыз, зинһар, миңа 81 Россия фильмын карарга туры килде! – ди ул. – Экранны тотып ватасы килмәгән бишенче лента «Байгал» булды. Минем карашка, әйбәт кино килеп чыккан. Нәкъ менә татарстанныкы. Сюжет буенча, ул теләсә кайда була ала – Люксембургтамы, Улан-Батордамы – тулаем интернациональ. Ә менә бирелеше! Баштарак, карый башлаган мәлдә, уйлыйсың: «Никтер бик салмак...» Әмма торабара бу темп үзенә җәлеп тә, әсир дә итә. Син аның нәкъ менә шулай булырга тиеш икәнлеген аңлыйсың – картинаның бөтен мәгънәсе дә шунда. Фильм, Көнчыгыш рухына хас булганча, медитатив килеп чыккан. Әмма ясалма рәвештә түгел, әйтерсең, ул туфракның, тормышның үзеннән...

Мөселман киносы фестивалендә «Байгал» конкурс программасына кермәде, аның каравы, махсус күрсәтүләр программасына эләкте. Әмма үзенең лаеклы таҗын картина сентябрьдә барыбер алды – Анапада, «Киношок» фестивалендә. Тулы метражлы фильмнар конкурсында аңа Зур жюри тарафыннан махсус диплом тапшырылды – «Милли традицияләргә сакчыл мөнәсәбәт өчен».

«Байгал»ның прокатта да потенциалы бар, дип исәпли Лаврентьев. Казанда режиссура өчен төп призларны алган «Мулла» фильмы да киң экранга чыгарга җыена. Миләүшә Айтуганова ике лентаның да продюсеры («Байгал»да әле тагын роль дә уйнады). Аның сүзләре буенча, «Мулла»ны, беренче чиратта, Татарстан белән Башкортостан кинотеатрларында прокатка чыгарырга җыеналар. Шулай ук татарлар яши торган аерым локаль урыннарда да.

– Кинотеатрларга, анда блокбастерлар барганга күрә, керүе бик авыр, – ди ул. – Әмма без моны барыбер эшләячәкбез, бирсен Ходай, киң прокатта сез дә аны карый алачаксыз. Октябрь яки ноябрь азагында.

Әлеге чараның азагындагы нәтиҗә нинди булачак, әлегә прогнозлау читенрәк. Әмма, бәхеткә каршы, без башка республикаларның тәҗрибәсенә күз сала алабыз. Әйтик, шул ук якутларның. Уртача алганда, кино икътисады анда болайрак иде: картинаны төшерү өчен якынча ике йөз мең доллар кирәк булса, җирле кинотеатрларда лента дүрт йөз меңләп акча җыя алды. Ә алга таба инде телевидение белән интернетта чиста керем алу мөмкинлеге турында сүз алып барырга мөмкин.

Ике эре Татарстан картинасы да – «Мулла» һәм «Байгал» турында әйтүем – Россия үлчәмнәре буенча әллә ни күләмле түгел, якутныкылар



белән чыгыштыра торган. Аларның чыгымнары да әнә шулай ук әйләнеп кайтыр, дигән өметкә урын бар. Шулай итеп, татарстанлыларны туган кинематографыбызга ярдәм күрсәтергә чакырабыз. Моның юлы бик гади – киносеанска билет сатып алу.

– Татарстан Президентының бизнесны гына түгел, ә мәдәниятне дә үстерергә, аңа ярдәм итәргә кирәк булуын аңлавы сөендерә, – дип өсти Сергей Лаврентьев. – Сездә төшерелгән берничә фильмның титрларында аларның Рөстәм Миңнехановярдәме белән төшерелүе турында күрсәтелгән иде. Әгәр шулай дәвам итсә, Татарстан яхшы кинолар җитештерелә торган төбәк булачак.

Исегездәме икән, берничә ел элек мәдәният әһелләре үз җирле киноиндустриябезне булдыру турында сүз алып барган иде. Әмма бу еллар эчендә сүздән гамәлгә күчәргә җыенулары сизелмәде. Белгечебез әйтүенчә, бу фикергә төгәллек кертү кирәк. Асылда, зур студияләр заманы артта калып бара. Бүген яхшы кино төшерер өчен әллә ни зур корылмалар кирәкми дә. Алар бер ун ел элек кирәк иде. Хәер, бу фестивальдәге Татарстан премьералары – әнә шуңа дәлил булып тора.

МОГҖИЗА БУЛЫШАЧАК!

«Без фестивалебездә балалар өчен фильмнар номинациясен киңәйтергә җыенабыз. Россиядә бу проблема хәзер гаять актуаль. Минем уемча, балалар киносын булдыру – безнең илебез кино җитештерүенең иң өстенлекле бурычларыннан берсе булырга тиеш». Бу сүзләр һәм вәгъдәләр Миләүшә Айтуганова авызыннан яңгырады. Ул «Татаркино» җитәкчесе – мөгаен, аны республиканың төп кино компаниясе дисәк тә, ялгышмабыз.

– Әлбәттә, фестивальдә балалар киносы – әлегә конкурска кертелә торган продукт түгел, – дип исәпли Сергей Лаврентьев. Шул ук вакытта программа директоры бу секциягә кинолар сайлауда бернинди дә проблема күрми. Аның әйтүенчә, бүген бу өлкәдә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, Иранда бик күп картиналар төшерелә... Анда акчалар бар чөнки. Балалар киносын төшерү арзанлы була алмый – могҗиза тудыру өчен мөмкинлек кирәк. Шул ук вакытта әлеге секциягә ихтыяҗ да зур – цифра дәвере булуга карамастан, балалар могҗизадан башка яши алмый!

Татарстанда бу өлкәдәге беренче карлыгач – Алексей Барыкин төшергән «Су анасы» булды. Мөселман киносы фестивалендә әлеге проектның тәкъдир ителеше каралган иде. «Без, махсус эффектлар кулланып, асылда беренче Татарстан блокбастерын төшердек», – диде режиссер җыелган тамашачыга.

Сергей Лаврентьев фикеренчә, «Су анасы» – бу Татарстанның ыргылышы, тырышып каравы, аны хупларга кирәк. Әмма эре уңыш турында сөйләргә әле иртәрәк дип саный белгечебез. Ләкин аны прокатка чыгару зарури, ди ул. Республикада аның ничек кабул ителүен һичшиксез күрергә кирәк, аның чикләрендә дә...

– Татарстаннан читтә картинаның прокатта шанслары күбрәк тә, минемчә, шулай сизәм, – ди Сергей Александрович. – Сезнең үзегез өчен гадәти булган татар авылы, мисал өчен, Томскида яки Омскида яшәүче малайларга, кызларга бик тә үзенчәлекле булып тоелырга мөмкин. Экзотика! Бары прокатны дөрес оештырырга гына кирәк.

«Су анасы» Россия экраннарына агымдагы елның көзендә яки киләсе елның язында чыгачак, дип фаразлана. Аны Калининградтан алып Владивостокка кадәр территориядә яшәүче барлык кешеләр дә күрә алачак. Төшерүчеләр фикеренчә, картина 12 яшьтән алып аннан да зурракларга кызыклы булачак, һәркем анда үзе өчен нидер табар, дип ышана алар. Сүз уңаеннан, Барыкин өчен беренче булу – тәүге сынау түгел. Нәкъ менә ул киң экранга «Гаилә мәшәкатьләре» комедиясен чыгарды. Фильм Татарстан кинозалларында биш уикэнд дәвамында гөрләп барды. Җирле прокатта гына чыгымнарын каплау мөмкин булмады, билгеле, ләкин монысы гына куркыныч түгел, дип исәпли режиссер, чөнки замана картиналары бу рәвешле бары тик бюджетның бер өлешен генә кире кайтара ала, гадәттә.

НЕЧКӘ МАТЕРИЯЛӘРНЕҢ КЫТЫРШЛЫГЫ ХАКЫНДА

Быелгы кинофестивальдә төрләр режиссерлардан да күбрәк иде, дип шаяртты кайберәүләр. Хәер, моны аклый да алдылар: вакыйга кысаларында Фестивальнең директорлар форумы да узды. Әйтергә кирәк, тәүге мәртәбә. Миләүшә Айтуганова белдергәнчә, директорлар форумы – эшнең яңача формасы, дигән сүз ул.

– Идея узган елда барлыкка килде. Ул чакта берничә кинофестиваль җитәкчеләре белән аралаштык та безгә фестиваль тәҗрибәсе белән уртаклаша, үзара фикер алыша, аралаша торган мәйдан җитеп бетмәгәнлеген аңладык, – диде ул.

Нәтиҗәдә форум көннәрендә Казан кинофестивале дирекциясе күп кенә башка кинофестивальләр белән килешүләргә кул куйды. Шарм-эль-Шейхтагы гарәпләр белән Европаныкы, Казахстандагы «Евразия», Италиянең дини кино, «Төркия дөньясы» дип аталган документаль кино фестивальләре һ.б. белән. Моңа сөенергәме? Вакыт күрсәтер. Әлеге килешүләр гамәли яктан да тормышка ашса, ул чакта бар да ачыкланыр. Әлегә дә баягы Лаврентьев сүзләренә караганда, дөнья практикасында мондый хәл еш очрамый.

Әйтергә кирәк, директорлар форумы фестивальнең төп халыкара рекордына әверелмәде. Аның гаризаларының статистикасы миңгә якынлашты, шул рәвешле ул бөтен

Фото: Александр Ефремов

җир шарын колачлый, дисәк тә була. Дөрес, фестивальнең программа директоры бу мәсьәләдә әллә ни куанычларны уртаклашырга ашыкмый. Аргументациясе мондый: бүген азмы-күпме юньле фильм төшерер өчен камерадан кала берни дә кирәкми. Талантың булса инде, билгеле! Әмма практика шуны күрсәтә: шуңа да карамастан, юньле фильм меңгә берәү генә төшерелә. Димәк, прокатка чыкан 999 картинаны, берәү дә алмаячак, дигән сүз бу. Фестивальләрдән кала!

– Фильмнарны фестивальләргә җибәрү белән шөгыльләнә торган махсус фирмалар бар, – дип сөйләде безгә Лаврентьев. – Купринның «Яма» әсәренә нигезләнеп, вакыйгалар безнең көннәрдә фәхешханәдә бара торган итеп төшерелгән лентаны мөселман кинофестиваленә җибәргәндә алар нәрсә уйлыйлардыр, миңа караңгы. Менә шулай итеп, без 967 гаризадан 902 сен кире кагарга мәҗбүрбез. Соклану белдерергә ашыкмаска кирәк, чөнки атаклы кинофестивальләргә картиналар нигездә гариза буенча сайланмый – сайлап алучылар аларны бөтен дөнья буйлап үзләре эзли. Мин дә күптәннән моңа өндим.

Кино белгеченең сүзләренә карагандa, безгә әле кинофестиваль төшенчәсе нәрсә ул – әнә шуны тулаем аңлауга килергә кирәк. Ә бу – бик нечкә материя. Татарстанның шул ук «Мулла» лентасын гына алыйк. Ул төп номинациядәге призга дәгъва кылды, уйлап карасаң, Казан кинофорумының ачышы буларак бәяләнергә хокуклы иде. Әмма… Оренбургныкында гына ачыш була алды. «Восток&Запад. Классика и Авангард» фестивалендә ул берьюлы ике приз алды – «Иң яхшы фильм» һәм «Иң яхшы актер» номинацияләрендә (мулла ролен уйнаган Рамил Фазлыев лаек дип табылды).

– Мин бу хакта ишеткәч, бик нык гаҗәпләндем, – дип, уфтанып куйды Сергей Лаврентьев. – Татарстан кинематографистларына үз фестивальләрен үстерү турында уйларга, аны кайгыртырга кирәк! Булган очрак аның өчен дөрес булмаган пиар-адым. Алар шулай итеп «шаулап алдык» дип уйлый. Әмма бу «шаулау» түгел. Менә Венециядә «шауласаң» – ул чакта әле аңлашыла, ләкин Оренбург фестивале – ул әле, бик нык хөрмәт итеп искә алсам да, халыкара дәрәҗә түгел. Икенче бер момент. Россия кинофестивальләрен оештыручылар ни өчендер әле һаман да бу чараның иң әһәмиятле мизгеле – кызыл келәмнән узу церемониясе дип исәпли. Шуңа күрә ачылу белән ябылу тантанасы өчәр сәгать дәвам итә – мондый хәл дөньяда инде күптән юк. Яисә Марат Бәшәров сәхнәгә чыга һәм жюрига мөрәҗәгать итә: янәсе, мин бу фильмда төштем, сез инде аңа игътибар итми калмагыз… Син нинди генә дәрәҗәдәге йолдыз булсаң да, болай шаяру килешми! Сез Джонатан Риз Майерсның Венециядә шундый чыгыш ясавын күз алдына китерә аласызмы?! Андый нәрсәләрне алдан уйлап сөйләргә кирәк. Әйе, бу аерым бер вак әйберләр булып тоелырга мөмкин, ләкин бит дөнья күләмендә атаклы кинофестивальләрнең «йөзе» әнә шундый принципиаль моментлар белән билгеләнә.

ТАТАРСТАН ФЕНОМЕНЫ

Моннан берничә ел элек без әлеге дә баягы Сергей Лаврентьев белән нәкъ менә шушылай милли кинематографның проблемалары һәм үсеш юллары турында гәпләшкән идек. Ул чакта атаклы кино белгече онытылып, әсәренеп якут феномены турында сөйләде – Саха Республикасы Россия милли киносының лидерына әверелгән вакытлар иде ул. Хәер, ул әле шул чакта ук Татарстан феномены турында да искә алды. Безнең кинематографның торышы бик нык гаҗәпләндерә иде аны – бөтен нәрсәдә алдынгы, лидер булырга омтылган һәм ияләшкән республика ни өчен кино сәнгате өлкәсендә ыргылыш ясый алмый соң?!

– Шуннан бирле нидер үзгәрдеме? – дип төпченәм Лаврентьевтан.

– Ниһаять, Татарстан киносы да… пәйда булды! Сүз инде аерым бер кыска метражлы продукт турында гына бармый, ә эре тулы метр хакында бара! «Мулла», «Байгал», «Су анасы», «Яу»… Бу инде үзешчән сәнгать түгел, ә чын мәгънәсендә кино сәнгате.

Республиканың илдәге кинематографта тоткан урыны да үзгәрде, дип исәпли кино белгече. Әгәр якут кинематографы сүлпәнәебрәк торса (ә бу тенденция күзәтелә), Татарстан асылда кино сәнгате билгеле бер эзлеклелектә үскән бердәнбер төбәк булып әвереләчәк – мондагы кебек адымнар башка төбәкләрдә әле юк.

– Бурятлар белән чувашлар эре картиналар төшерә башлады, әмма аларның эшләре әле Татарстан режиссерлары тәкъдим иткән дәрәҗәдә түгел. Хакаслар аз төшерә, ә менә башкортларда ярыйсы гына фильмнар бар. Тик алар кыска метрда. Марилар белән мордваларда берни дә юк диярлек… Татарстан кинематографы, ниһаять, республика Россия киңлегендә үзе тоткан абруйлы дәрәҗәгә юнәлеш алып җитеп килә. Сезнең кино турында хәзер «ул бар» дип әйтергә була. Һәм бу – инде горурланырлык сәбәп.

– Әйдәгез, бала белән паралельләр үткәрик, – дип тәкъдим ясыйм Сергей Лаврентьевка. – Ничек уйлыйсыз, бүгенге көндә Татарстан кинематографы – нарасыймы, әллә инде үсмерлек чорына кердеме?

– Минем карашка, 10 яшьләр тирәсендәге кече сыйныфлар укучысы әлегә, – дип елмая әңгәмәмдәшем. – Бик шәп яшь! Күпне вәгъдә итә торган, талантлы! Аның киләчәктә нинди булып әвереләчәген күзәтү гаять кызыклы. Аның алдында гаять күп офыклар һәм мөмкинлекләр. Теләсә, бик зур уңышларга да ирешә алачак ул, шул ук вакытта, начар йогынтыга бирелеп, кыек юл белән китәргә дә бик мөмкин… Без аңа карап торабыз һәм, тын калып, көтәбез. Бер-ике елдан аның кайсы юлны сайлавы инде анык билгеле булачак!

«МИН ҺӘР ЯЗУЧЫ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ»

Иҗат кешеләре – үзенә бер категория шәхесләр. Бу категориядә фикердәш, аркадаш, бәхәстәш булырга мөмкин. Ә менә алар белән һәм иҗат процессының үзе белән идарә итү... монысы, бүгенге күзлектән караганда бигрәк тә, абсурд белән бер чиктә тора торган төшенчә, дияргә була. Зур нарративлар юкка чыгып, идеологиягә хезмәт итү вазыйфасыннан арынгач, сәнгатькә, аның бер өлеше булган әдәбиятка, кайчандыр Дәрдеменд сурәтләгән «кораб»тай, давылларга каршы «җилкәнен киреп», ориентирларсыз йөзәргә генә калды. Әдәбият корабының башында, рәсми рәвештә яшәп, эшләп килгән оешма буларак, Язучылар берлеге тора. 60 яшьлек юбилеен тутырган көннәрендә без аның капитаны – драматург Данил Салихов белән әңгәмә корырга булдык.

Әңгәмәдәш:
Луиза Янсуар

– Данил абый, 300дән артык Язучылар берлеге әгъзасы арасында булу, берлекнең Идарәсе составында торып, әдәбиятка кагылышлы нинди дә булса мәсьәләләрне хәл итү – бер нәрсә, ә бер гасырлык тарихы булган «кораб»ның руленә алыну – бөтенләй башка җаваплылык...

– Мин Язучылар берлеген җитәкләргә телим дигән карарга бик озаклап һәм тирәннән уйлап килдем. Карарым нык иде. Корылтай вакытында, сайланганда да, шуңа нык тордым, чөнки мин кая, нәрсә өчен килгәнемне яхшы белә идем. Тәкъдим иткән программамда акка кара белән барысы да анык язылып куелган, язучыларның шуңа да миңа ышанычы зур булгандыр дип фаразлыйм. Буш сүз сөйләп, томанлы вәгъдәләр биреп утыру – минем характерымда түгел, үз көчемнән килердәйне тәгаенләп, билгеләп куям да, эшлим. Бу эшкә алынганда курыкмадым, шикләнмәдем дип әйтмим, шикләр дә, борчу да бар иде. Чөнки бу – гади генә үз эшен хезмәт хакына башкарып утыручы хезмәткәрләрдән торган оешма түгел. Һәрберсе үзе бер дөнья, олпат шәхес булган, иректә фикер йөрткән акыллы, белемле затлардан гыйбарәт команда. Мин бу команда белән идарә итәргә түгел, ә, беренче чиратта, язучыларның тормышяшәеш шартларын яхшыртырга килдем. Администратор буларак килдем. Язучылар берлеге рәисенең иң төп вазыйфасы, минемчә, бүгенге көндә шул. Ул капиталистик шартларда иҗади лидер, юлбашчы булып утыра алмый.

– Әмма лидерлар, каһарманнар кирәк бит халыкка, аңа юл күрсәтүчеләр, нәрсәнең дөрес, нәрсәнең ялгыш икәнен вәемлаучылар, аңлатучылар... Җитмәсә, бүгенге җәмгыятьтә үзләрен үзләре игълан иткән ялган лидерлар да – җитәрлек...

– Бүгенге әдәбиятны әйдәп барыр өчен аның кая барганын белү мөһим – мин шулай уйлыйм. Әмма идеологиясез заманда моны тоемлау бик авыр. Теге елларда бит тәгаен күрсәтмәләр бар иде: совет язучысы менә боларны язарга тиеш, ә менә боларын язарга ярамый... Каһарманнар белән дә шулай – совет системасына хезмәт итә, аны үстерүгә үзеннән өлеш кертә торган затлар – каһарман. Шуларга өстәп, аңарда кешелек сыйфатлары, әдәп-әхлак критерийлары да асыллардан булырга тиеш. Ә хәзер, дөньяда нәрсәнең дөрес, нәрсәнең юк икәнлеге югалган бер чорда, мин дә, башка язучылар да анык кына бер магистраль линия билдыра алмый. Анык кына нәрсәгәдер өнди дә алмый. Әмма кеше булып калу – бик мөһим нәрсә.

– Нәрсә сагында тора булып чыга соң алайса бүгенге язучы? Кем ул? Ни өчен кирәк җәмгыятькә?

– Мин аны чорына диагноз куючы дияр идем. Кайчандыр ул диагноз куйганнан соң, дәвалау да булган. Ысулларның шактый кискеннәре дә булган. Без бүген үзебезгә мондый кискенлекне рөхсәт итә алмыйбыз. Әйтик, тел мәсьәләсендә бөтен язучылар дәррәү күтәрелеп чыгарга, нык торырга тиеш иде, дип, берлекне кайта-кайта гаепләделәр. Имеш, аның бу мәсьәләдә анык позициясе, сәяси стратегиясе юк. Әмма язучының, аерым бер шәхес буларак, бу мәсьәләдә позиция белдерүе – бер нәрсә, ә дәүләт оешмасының күтәрелеп бәрелүе – икенче. Бу мәсьәләдә төп карарны без чыгармыйбыз. Әмма башбаштаклык сәбәпчесенә әверелергә бик тә мөмкинбез. Язучылар берлеге тел һәм милли мәгариф мәсьәләсендә республика буенча һәм чит төбәкләрдә күпме очрашулар оештыра, моны да күрергә кирәк. Ә бу – безнең көндәлек гадәти эшебез. Язучылар берлегендә берәр чара узмаган, йә булмаса безнең очрашуларга чыгып китмәгән бер генә көнебез дә юк.

– Яшерен-батырын түгел, бүгенге язучының хәле шактый мөшкел. Аның басылган китабыннан алынган гонорары да элеккегечә бер җирдә дә эшләмичә, профессиональ язучы булып кына еллар буе яшәргә мөмкинлек бирми, хәтта тамагын туйдырырлык та килеп чыкмый.

– Язучылар берлеге әгъзасы булган һәр язучының иҗатын гына түгел, ә тормыш-көнкүреш хәлләрен белеп тору да мөһим. Өендә нинди вазгыять, гаиләсендә иминлекме? Эшендә ничек? Боларны белеп тору – минем, җитәкче буларак, бурычым. Ул-бу була калса, әлеге язучы өчен мин җавап бирәм. Тәүлекнең 24 сәгатендә уяу булмыйча ярамый. Төрле хәлләр бар бит. Өлкән әдипләребез бар, авырганнары да аз түгел. Өлкән яшьтәге язучыларыбыз, гомумән, күпчелекне тәшкил итә. Авырый-нитә калса – хастаханәгә салырга, шифаханәгә җибәрергә, сәламәтлекләрен кайгыртырга кирәк.

Фотолар язучының шәхси архивыннан алынды

Кайчакта бары аларның зарын тыңлап кына утырсаң да, күңелләрен бушатып кайтып китәләр. Язучыларның килергә, ярдәм сорарга йортлары бар. Һәм бирердә ишекләр һәрчак ачык. Ә инде китаплар чыгаруга килгәндә, «Татарстан китап нәшрияты» да, без дә бүген кулыбыздан килгән кадәресен эшлибез. Әйе, китапның һәм язучы хезмәтенең бәясе төште. Анысы заманга бәйле һәм без генә үзгәртә торган вазгыять түгел ул.

– Ни өчен төште дип уйлыйсыз аның дәрәҗәсен? Һәм ничек күтәреп була аны?

– Сәнгать яшәү ихтыяҗлары арасында беренчел урында тормый шул хәзер. Үзгәртеп кору елларында, яшәү дәрәҗәсе түбән тәгәрәгәч, халык иң беренче чиратта тамагын туйдыру, өс-башын бөтен итү турында уйлый башлады. Ул чакта язучыларның хәле дә бик авырайды. Аңа кадәр бит безнең Әдәби фонд гөрләп эшли иде. Миңа аны җитәкләү насыйп булды. Язучыларны ял йортларына җибәрүләр, дисеңме, фатирлар белән тәэмин итү, хастаханәгә урнаштыру, санаторийларда хәлен ныгыту мөмкинлегенә бирү… Переделкино, Пицунда, Ялта, Сочиларда рәхәтләнеп ял да итеп, иҗат та итеп кайта иделәр, отпуск акчасына да кинәнеп яшәргә була иде… Үзгәртеп кору чорында, кызганыч, ул йортларны язучылар өчен саклап кала алмадылар.

– Безнең буын, бездән яшьрәкләр исә, гомумән моның булуы мөмкин түгел, дип исәпли. Утопия кебегрәк кабул итә. Димәк, яшь иҗатчы матди яктан тәэмин ителмәячәген анык аңлагач, билгеле, язучылыкка җитди һөнәр итеп карый алмый. Аңа бит яшәргә кирәк…

– Менә үзең ничә еллар инде әдәбияттан барыбер дә баш тартмыйсың бит. Бер син генә дә түгел… Югыйсә, сез акыллы һәм башка өлкәләрдә дә үзләрен табарга, җир җимертеп эшләргә сәләтле яшьләр, шуңа да карамастан, әллә ни керем китерми торган әдәбият дөньясында кайнашып ятасыз. Заманча, кызыклы проектлар уйлап табасыз, ниләрдер майтарасыз…

– Бездә әле теге чордан килгән идеаллаштыру бардыр, бәлки. Киләсе буыннар инде үзләренә зарарга эшләмәскә дә бик мөмкин…

– Менә шуңа күрә бездә пропаганда бүлеге эшчәнлеген яңартып

– Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булган язучы ничек яши? Тәүлекнең 24 сәгатендә моны белеп тору – минем бурычым ул.

җибәрергә кирәк, бөтенләй башка төрле итеп корырга, оештырырга аны. Бәлки, чынлап та яшьләр эшләргә тиештер, чөнки сезнең дөньяны күзаллавыгыз безнекенә караганда җетерәк, тоемыгыз үткенрәк.

– Конкрет алганда, нинди эшләр күздә тотыла?

Бәйгеләр, әсәрләр бастыруны грантларга тәкъдим итү, иҗади һәм проблемалы темаларга сөйләшү буенча очрашулар – бу формалар элеккечә дәвам итәргә тиеш. Безнең бит әле кеше күзенә бик күренми торган эчке лабораториябез дә бар. Ул нормага салынган, җаена корылган хезмәт – әйтик, иҗади остаханәләр эшчәнлеге (аларда берлеккә килгән кульязмалар, китаплар карала, тикшерелә), коллегия утырышлары (бу орган Язучылар берлегенә кабул ителергә тиешле лаеклы әгъзаларны барлый, карар чыгара), идарә утырышлары (анда Язучылар берлегенең төп стратегиясе, эшчәнлеге тикшерелә, шулай ук халыкта зур шау-шу куптарган премияләргә кандидатлар чыгару, аларны тавыш бирү юлы белән билгеләү дә). Нигездә, Язучылар берлеге бүгенге көндә үзенең традицион эшен башкарып килә. Моңа өстәп, мин язучыларның матди хәлләрен яхшырту буенча тырышам. Спонсорлар эзләп, төрле оешмаларга бару да, конкурсларга акча бүлеп бирүләрен тәэмин итү дә, булган кадәр финансларны каберлекләрне рәтләүгә, язучыларның туган якларындагы чардуганнарны кайгыртуга тоту да – болар барысы да административ эшләр. Мин, әйткәнемчә, аларны башкаруны бурыч итеп куям.

– Язучылар берлеге бүгенге әдәби процессның барышына юнәлеш бирү белән дә шөгыльләнергә тиештер бит? Бәлки, анысы әһәмиятлерәктер дә... Бу хәл ничегрәк тора?

– Без бүгенге көндә язучыга «син моны язарга тиешсең» яисә «менә болай язарга тиешсең» дип юнәлеш бирә алмыйбыз. Асылда, бу элек тә була алмаган! Ничек кенә идеология бар иде дип сөйләшсәк тә, идеологиягә һәм системага «башка күзлектән» карауч әдипләр һәрчак булган. Әйтик, мин заманында остаз санаган Аяз абый Гыйләҗевны гына алыйк. Әмирхан абый Еникины да атарга була, ул да, гыйсъянчыл рәвештә күтәрелеп бәрелә торган әдип булмаса да, әсәрләрендә заманны шактый кискен чагылдырган, тәнкыйтьләгән шәхес. Элек аларның «уңайсыз» әсәрләрен бастырмасалар, үзләрен әдәби процесстан читләштерсәләр, без бүген язучының нәкъ менә үз иркендә булуын күреп торабыз. Берәүгә дә куркыныч янамый – яз рәхәтләнеп ни турында телисең! Адым саен – китап нәшрияты, чыгар рәхәтләнеп китабыңны да тарат укучыга.

– Әйе, без бүген фикер плюрализмы шартларында яшибез. Әмма ул фикерләр укучыны тәрбияли, яхшыга өнди, эстетик яктан үстерә дип әйтә аласызмы? Гомумән, XXI гасырда әдәбият әхлакка, матурлыкка өндәүгә хезмәт итәргә тиешме? Халыкка хезмәт итәргә?

– Минемчә, тиеш! Язучы үз халкы өчен язмаса, кем өчен яза? Менә бүгенге көндә бик зур бәхәсләр уяткан татар темасына бәйле әсәрләрне генә алыйк. Аны рус телендә иҗат итүче авторлар эшли. Исемнәрен атамасам да, кем турында сүз барганын аңлата алганмындыр. Аларның әсәрләре дә, татар темасын кузгаткач, татарга йә хезмәт итә, йә аңа каршы провокация булып тора. Татар язучысы, минемчә, үз укучысына карата балта күтәрергә тиеш түгел...

– Ә аны үзгәрергә өндәгән очракларда? Кискен чаралар кирәк дип тапканда? Без бит, уйлап карасаң, башка милләтләр, халыклар шикелле үк, идеаль гына түгел?

–Андый нәрсәне өеңдә эшләргә кирәк, читкә чыгып кычкырырга түгел. Ә бездә тәнкыйть итә, яки килешсез якларны күрсәтергә теләсәләр, һәрчак читкә чыгып лаф оралар. Иҗатының башында һәрбер каләм әһеле каләмгә яхшы ният белән тотынадыр, дип ышанам. Нигездә, бу бит балачакта, үсмер чорда башлана. Ә баланың әле күңеле чиста, уй-ниятләре якты була. Безнең әдәбиятта, өстәвенә, әхлакый традицияләр дә бик көчле. Сәнгати якны алсак, аны һәр язучы булдыра алганча эшли инде. Безнең әдәбиятта эстетик яктан бик югары әсәрләр дә бар. Дөрес, бүгенге көндә һәркем китап чыгара башлагач, чүпчар да җитәрлек.

– Бәлки, цензураны яңадан кайтарырга кирәктер?

– Язучылар берлеге шул цензура бит инде ул.

– Димәк, без бары тик иң югары дәрәҗәдәге авторларны гына берлеккә кабул итәбез, дип әйтергә урын бар?

– Бөтенләй начар яза торган кешене Язучылар берлегенә алу, билгеле инде, абсурд булыр иде. Әмма без бары тик «менә бу иртәгәге көннең, хәтта бүгеннең үк тере классигы» дигәннәрне генә дә тота алмыйбыз берлектә. Безнең бит читтәге язучыларыбыз да бар, – төбәкләрдәге, районнардагы. Аларның да урыны – берлектә. Без андыйларны берлеккә кабул итеп, үсендереп җибәрәбез, канат куябыз. Димәк, без шулай итеп урыннардагы иҗат процессын стимуллаштырабыз, аңа җан өреп җибәрәбез, дигән сүз.

– Ә менә сез әйткән «тере классиклар»ны дөнья пространствосына чыгару, башка халыкларга таныту буенча Язучылар берлеге ни дәрәҗәдә эшли? Һәм, гомумән, тиешме эшләргә? Әллә без үзебезгә үзебез булсак, шул җитәме?

– Тиеш, әлбәттә. Язучы гомумән дөнья пространствосын күздә тотып эшләргә тиеш инде ул. Әмма үз халкына йөз белән борылып. Безнең, әйткәнемчә, халкыннан йөз чөереп читтә әллә кем булып йөрүче затларыбыз да булды һәм бар. Бүгенге көндә тәрҗемә эшенә игътибарны күп бирәбез. Татар әдипләрен төрки халыкларга күрсәтә алдык. Бу юнәлештә алга таба да эшләргә кирәк. Русчага тәрҗемәләр булырга тиеш, шулай ук русчадан – татарчага да.

– Яхшы әсәрләр дә бар, «тере классиклар» да. Ә ни өчен без көннән-көн укучыбызны югалтарак барабыз соң?

– Бүгенге заман интернетка чумган заман ул. Мәгълүматны шуннан алалар, ата-аналар балаларны кечкенәдән китап культурасына җәлеп итеп тәрбияләми. Безнең өчен бит китап изге нәрсә иде. Шулай да бөтенләй укымыйлар, дип уйламыйм. Менә сез бит укыйсыз, сезнең арттан килгән яшьләр дә укымый түгел.

– Язучылар берлеге берәр нинди мониторинг ясыймы – кемнәр

укыла, кемнәр популяр, нинди әдәбиятка ихтыяҗ бар?

– Безнең эшчәнлек аны күздә тотмый, бу күбрәк нәшрият эшедер, дип уйлыйм. Әмма без бик күп очрашуларга йөрибез. Шунда барысы да күренә инде.

– Дөнья интернетка күчте, дигәннән, ә бәлки яшьләрне кызыксындыра ала торган интернет-контент булдыру зарурдыр? Миңа, мәсәлән, Язучылар берлеге сайтын да яңарту кирәк кебек тоела, нишләп аны олы бер цифралы портал итмәскә? Дөньяның кайсы почмагында яшәсә дә, татар әдәбияты белән кызыксынган кеше кереп карый һәм татар әдәбияты хакында күзаллау булдыра алсын...

– Без, чынлап та, бу өлкәдә арттарак калып барабыз, килешәм. Әле компьютер белән эшләргә дә яңа өйрәнеп килә торган язучыларыбыз бар. Ә замана технологик яктан томырылып алга чаба. Сайтларны, аның эчтәлеген дә заманчалаштырырга кирәк, әйе. Сайт миңа кадәр эшләнгән иде. Анда, дөрес, уңайсызлыклар бар. Берлекнең иң беренче сайты булганлыктан, эшләп карамый гына ничек беләсең. Әлбәттә сайтны яңарту, яшь язучыларны, сайт ясаучы егетләрне чакырып фикерләшергә кирәк. Бу, үз чиратында, зур гына чыгымнар да таләп итәчәк, билгеле. Берлекнең Идарәсендә яшьләр дә бар, Луиза, син дә Идарә әгъзасы. Мин бүген сездән, актив яшь иҗатчылардан тәкъдимнәр көтәм. Сез бит өлкән язучылар тәлинкәгә салып табып китергәнне көтеп утырырга тиешле кешеләр түгел. Менә – бина, менә – ачык ишекләре, менә –Тукай клубы, бакчасы. Кайнатыгыз биредә тормышны. Өлкәннәр өчен узган кичәләргә битараф булып, берни тәкъдим итмәү – батырлык түгел бит.

– Димәк, берлекне кардиналь рәвештә яшәртергә кирәк, дигән фикергә килеп чыгабыз түгелме?

– Баланс булырга тиеш, минемчә. Өлкән буын – традицияләр сагында торып, яшь буын дөньяны яңартканда гына нәрсәгә дә булса ирешеп була. Без яшьләргә йөз тотабыз – анысы хак. Яшь көчләргә йөз тотмаган бер генә оешманың да, ә сәнгатьнең бигрәк тә, киләчәге юк.

– Сез киләчәктә язучы сүзенең, димәк ки Язучылар берлегенең дә, җәмгыятькә кирәге булыр, дип ышанасызмы?

– Ышанам. Миңа йөзләгән Язучының ышанычы тапшырылган икән, димәк бу оешманың яшәешен тәэмин итү бурычы да йөкләнгән, дигән сүз. Бетерү тиз ул. Безгә кадәр берлекне булдырган әдипләр аны без юк итсен дип булдырмаганнар. Ә язучы сүзенең, заман нинди генә булмасын, кирәк булудан туктаганы юк һәм булмаячак та.

– Элегрәк язучыларның юбилейларын олы-олы сәхнәләрдә зурлап үткәрәләр иде. Хәзер бу локаль характер алып килә шикелле – Татар дәүләт опера һәм балет театры, Камал сәхнәләренә алмашка Тукай клубы...

– Тукай клубы – ул Язучылар йортының җаны булырга тиешле урын. Юбилейларның монда узуы – табигый күренеш. Нишләп аны кимсетеп бәялиләрдер, белмим. Ә әдипнең дәрәҗәсенә, финансларны җәлеп итү мөмкинлекләренә бәйле рәвештә, зуррак сәхнәләр дә арендалана. Ә Тукай клубы хакында мин һәрвакыт әйтә киләм: теләсә кайсы язучы килеп, теләгән чарасын уздыра ала бу сәхнәдә. Язучылар бинасы аныкы булган кебек, Тукай клубы сәхнәсе дә – аныкы. Без, Язучылар берлеге хезмәткәрләре, монда эшне оештыручылар, каләм әһелләренә ярдәм итүчеләр генә.

– Юбилейга ничек әзерләнәсез?

– Әзерлек эшләре үз җае белән бара. Гадәти ритмда, нәкъ башка юбилейларныкы кебек. Мине олылап, зурлап килергә торучы кешеләргә рәхмәт. Иң куандырганы – Россиядән 10 га якын театрдан кунаклар киләчәк. Алар – минем иҗатымны күрсәтә алырлар дип ышанам. Мин бит әле, администратор булудан кала, драматург та, ә юбилей ул – язучы өчен нәтиҗәләр ясый торган вакыт.

– Журнал укучылары сезнең юбилейга кайда һәм кайчан килә ала?

– Барыгызны да 15 октябрьдә Кәрим Тинчурин исемендәге театрда көтеп калам. Ул – минем Казанда профессиональ сәнгатькә иң беренче аяк баскан бинам.

– Актерлыктан китеп, язучы булуыгыз өчен үкенгәнегез булдымы?

– Тормыштагы һәр борылыш – яңа мөмкинлек, дигән сүз ул. Үзеңне сынап карар өчен дә, кешегә күрсәтер өчен дә. Минем язучы буларак амбицияләрем көчлерәк булган, күрәсең.

Данил Хәбибрахман улы Салихов 1958 елның 7 октябрендә Татарстанның Актаныш районы Киров исемендәге совхоз бистәсендә дөньяга килә. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан музыка училищесының вокал бүлегенә укырга керә. Өченче курстан соң Казан театр училищесына укырга күчә. 1983 елда аны тәмамлап, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер булып эшли башлый. 1985–1991 елларда – К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында актер.

1993 елдан башлап Данил Салихов матбугат, әдәбият-сәнгать мохитендә кайный башлый. «Салават күпере» журналының баш мөхәррире урынбасары, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шулай ук күп еллар дәвамында – Татарстанның Әдәби фонды җитәкчесе. 1998 елдан алып 2006 елга кадәр Әдәби фонда белән бергә авторларның милек саклау оешмасы директоры вазыйфасын башкара. 2006 елдан 2010 елга кадәр Әлмәт Язучылар оешмасында җаваплы секретарь. 2016 елда Татарстан Язучылар берлегенең XVIII корылтаенда Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып сайланды.

Данил Салихов – Татарстан Язучылар берлеге һәм «Татнефть» оешмасының Саҗидә Сөләйманова, Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге, Гамил Афзал исемендәге әдәби премияләр лауреаты, «Фидакарь хезмәт өчен» медале иясе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Күпсанлы китаплар авторы. Россия театрларында әсәрләре буенча берничә дистә спектакль куелган.

КЫРГЫЙЛЫКНЫҢ ЦИВИЛИЗАЦИЯ ТЕМАСЫНА ВАРИАЦИЯЛӘРЕ

«Йолдызлар гына уйный торган сәер кино». Аның фильмнары турында әнә шундый фикердә торалар. Һәм Голливуд, һәм һәртөрле фестиваль инсайдерлары белән тәнкыйтьчеләре. Чыгышы белән Грециядән булган, хәзерге көндә Англиядә яшәүне кулай күргән 45 яшьлек бу сценарист һәм режиссер чын мәгънәсендә заманча кино сәнгате экстремалына, ул гына да түгел, кино белгечләренең фаворитына әверелде. Аның «Фаворитка» картинасы – быелгы иң көтелгән премьералар исемлегендә. Канны белән Венеция фестивале вәкилләре лентаны инде карау бәхетенә иреште. Ноябрьдә дөньякүләм премьера көтелә. Безгә ул 2019 елның гыйнварында килеп ирешәчәк.

Автор:
Луиза Янсуар

«ЯҢА ГРЕК ДУЛКЫНЫ», ЯКИ «КЕЧЕ ВАТАН» ФЕНОМЕНЫ

Британия королевасы Аннаның XVIII гасырдагы сарае һәм аның эчендә барган сәер хәлләр турындагы «Фаворитка» тизерыннан күренгәнчә, чыннан да ымсындыргыч булырга вәгъдә итә. Моңарчы комедияләр төшермәгән Лантимос ниятләгәнчә, «комедия» дип билгеләнгән жанрын да акларга охшый шикелле. Дөрес, комедия төшенчәсенең чикләре иркен вә киң. Ә гомумән алганда, бу картина безне янә бер мәртәбә жанрлар һәм чикләр юклыгына, бөтен нәрсә дә инде тоташ синтезда булуына ышандырырга мөмкин, дигән тәэсир дә үзен көттерми. Ярый, караганчы фаразламыйк.

Тагын бер көтелмәгән момент – режиссер биредә башка сценаристның материалына нигезләнде. Моңарчы Йоргос Лантимос бары тик үзенең фикердәше, даими автордашы Эфтимис Филиппу материалы белән генә эш итә иде. Әйтүенә караганда, Лантимос «Фаворитка»ны төшерү турында бик күп еллар хыялланган. Һәм аны акыллы-

зирәк, дуамал-җитез, тешләгеч усал итеп төшерү максатын да куйган кайчандыр үз алдына.

Грек киносын төшерүче генә булудан туктаган, дөресрәге, милли лакуна кысаларыннан атлап чыккан мизгелдән башлап, безне виртуозларча «йолдызлы состав» белән куандырып килә Лантимос. «Фаворитка» да искәрмә түгел. Барысы да үз урынында – Оливия Колман, Рэйчел Вайс, Эмма Стоун. Автор киносына хас булган дәвамчанлык, индивидуаль өстенлекләр дә күңелле тәэсир калдыра. Миңа, Ларс фон Триердан соң табигый рәвештә игезәдәй күреп, Лантимоска кучкән караучыга, режиссерның «минекеләр» дип аерып куйган галереясы ошый. Аның камерасы үзенә бер төрле, башкаларныкына охшамаганча итеп күрсәтә белгән Рэйчел Вайс белән Колин Фарреллга тагын да ныграк соклана барам.

Ә әлеге дә баягы «йолдызлы состав»ка, Голливуд дәрәҗәсендәге актерлар белән актрисаларны «эксплуатацияләүгә» килгәнче, Йоргос Лантимос башта фестивальләрдә күренеп, үзенең яңа бер караш белән яшәүче иҗатчы икәнлеген дәлилләде. «Клык» һәм «Альпы» ленталары Канны белән Венеция экспертларында зур кызыксыну уятты. 2009 елда «Клык» Канны кинофестиваленең «Үзенчәлекле караш» программасында икен-

Фотолар: kinopoisk сайтыннан алынды

че дәрәҗә лауреат дип табылды, 2010 елда Slant Magazine онлайн-басмасы аны елның иң шәп фильмы дип атады. 2011 елда исә «Клык» инде «Чит телдәге иң яхшы фильм» номинациясендә «Оскар»га тәкъдим ителде. Лантимосның чираттагы картинасы – «Альпы» – 2011 елда Венециядә үз бүләген тапты. «Иң яхшы сценарий» номинациясендә аны «Алтын Озелла»га лаек дип бәяләделәр. Әлеге бүләк, «Алтын арыслан», «Көмеш арыслан», жюриның Төп призы, Вольпи кубогыннан кала, дәрәҗәсе буенча иң югарылардан исәпләнә.

Бүгенге статусы буенча Йоргос Лантимос, әлбәттә, дөньякүләм дәрәҗәдәге режиссер. Ул инде хәзер беренче картиналарыннан аермалы буларак, дөнья прокатына йөз тотып эшли. Беренче эшелондагы актерлар аңарда төшәр өчен чиратка тезелеп тора. Фильмнары да инглизчә сөйләшә торган киң масса аудиториягә юнәлтелгән.

Шулаен шулай. Әмма менә нәрсәсе гаҗәп һәм үзенчәлекле булып кала бирә: ничек кенә глобализация ташкынына көйләнмәсен, Лантимос фильмнарында «яңа грек дулкынын» тудыручылар булып исәпләнгән режиссер һәм аның командасының үзгә карашы, кабатланмас атмосфера тудыра белүе һәм милли колорит сакланып кала. Кечкенә дә, зур да булган милли микрокосмның герметикасы. Дөньяга да, Голливудка да хәзер әнә шулай «кече ватан»нар, милли прецедентлар, аларның феномены кызыклы була башлады. Узган «Оскар» церемониясе – моның ачык дәлиле. Кайчандыр бу нишада Эмир Кустурица нәтиҗәле эшли иде, хәзер инде ул әле пионер гына булган икән, дип әйтә алабыз.

Шулай итеп, Йоргос Лантимос белән аның аерылгысыз аркадашы, фикердәшләре булган Эфтимис Филиппу һәм Афина Рахель Цангари киноиндустриясе белән әллә ни мактана алмаган Греция вә Румыниянең дә кино сәнгатендә конкурентлыкка ия икәнлеген исбатлый алды. Алар бүген бу өлкәдә, азмы-күпме, үз диктатын куя ала, үз эстетикасын алга сөрә, үз кагыйдәләрен билгели. Һәм туктаусыз экономия шартларында яшәргә, эшләргә мәҗбүр булмыйча, аларның үз иҗатларына, ниһаять, ирек бирә алулары да гаять әһәмиятле. Кайчандыр, әле Грециядә төшерелгән лентадары турында сөйләгәндә, Лантимос бу хакта кат-кат әйтә иде. Реклама төшергәннән кергән акчага гына чын мәгънәсендә сыйфатлы, яхшы кино эшләп булмый – бу көн кебек ачык.

ҮЗ ЭЧЕНДӘГЕ ДӨНЬЯ, ЯКИ ГЛОБАЛЬ ГЕРМЕТИКА

Без бүгенге кино сәнгатендә үз эчке фобияләре (сүз аерым бер кеше заты турында да, система, институтлар, хәтта милли нарративлар турында да бара) аша дөнья моделендәге чатнаган урыннарны күрсәтә алучы шактый уңайсыз, радикаль карашлы режиссерлар белән күзгә-күз очрашабыз. Билгеле, электән үк «баллы» булмаган Хичкок бар иде, Бергман, Феллини, Годар, Висконти, Куросава, Трюффо, Полански... – һәм саный китсәң, бу исемлекне әле тагын да дәвам итәргә мөмкин. 90 нчы елларда һәм аннан соң «уңайсызлар», «радикаллар» нишасында Голливудны туктаусыз шаккатырып торган Линчның булуын да онытырга ярамый. Альмодовар, Кесльевский, Джармуш, Вон Карвай, Триер, Имоу, Занусси, Ангелопулос, Ханеке... – һәм менә без бүген инде акрынлап автор киносының трендка әверелеп баруын күрәбез. Ә алар тәкъдим иткән микрокосм, колориты, буяулары, эстетикасы, стиле белән гаять төрле булса да, карауччысын никтер гел бер башлангычка алып кайтырга омтыла. Месседжы буенча гаять охшаш алар.

Герметик глобальлек, глобаль герметика, дип атарга да буладыр, бәлки моны. Лантимосны карагандa, һәрхәлдә, без цивилизациянең бу баскычында һаман да шул кыргыйлыгыбыз белән күзгә-күз кала бирәбез, дөресрәге, спираль буйлап йөрүне дәвам итәбез, дигән ваемлау үзеннән-үзе өстенлек ала. Соңгы арада шактый зур популярлык казанган бер хезмәт искә килеп төшә ирексездән. Юваль Ной Харариның «Sapiens. Краткая история человечества» китабы. Олы, какшамас нарративлар калмаган бер чорда безне нарративлар яралган гына чорга кайтармакчы була гүя иҗатчылар, галимнәр. Шулай итеп, яңадан бер этәрелеш кичерергә кирәклекне тоемлаудыр бу, бәлки? Ваемлаудыр? Әйтүләренә карагaнда, модерн һәм постмодернга алмашка метамодерн килә бит. Ә метамодерн кире кагуны түгел, ә бөтен плюслары һәм минуслары белән булганны анализлауны һәм, шул анализга нигезләнеп, кабул итүне алга сөрә. Бу үзенә күрә тәүбә дә, ярыш та.

«Сто тысяч лет назад на Земле жили шесть видов человека. Сегодня остался лишь один. Мы. Homo sapiens. Хозяева этой планеты.

Еще совсем недавно наши предки пребывали в состоянии постоянного страха перед хищниками. Им редко удавалось убить крупную дичь, существовали они главным образом за счет растительной пищи, а также ловили насекомых и мелких животных и обгладывали падаль, оставленную более сильными и проворными. Что ж, представьте себе: на ваших глазах стая львов затравила и сожрала жирафа. Вы терпеливо ждете в сторонке. После львов настает черед гиен и шакалов. Они обгладывают кости, и только тогда человеческое племя решается подойти. Люди настороженно оглядываются по сторонам и принимаются за то, что им осталось.

Это ключ к пониманию истории и психологии человека. До недавних пор род Homo занимал не верхнее, а скорее среднее положение в пищевой пирамиде. На протяжении миллионов лет люди старались избегать встреч с крупными хищниками. Лишь 400 тысяч лет назад мы начали охотиться на крупных зверей, и только в последние 100 тысяч лет, с появлением Homo Sapiens, стали верхним звеном этой пирамиды.

Последствия столь стремительного прыжка из промежуточного и зависимого положения на вершину оказались колоссальными. Человек не привык находиться на командной высоте, он к ней не приспособлен. Другие животные, оказавшиеся в итоге на вершине пирамиды – львы, акулы – шли к этому миллионы лет, а человек попал наверх почти мгновенно. Многие исторические катастрофы, в том числе разрушительные войны и насилие над экосистемой, проистекают из нашего слишком поспешного прорыва к власти. Человечество – не стая волков, завладевшая вдруг танками и атомными бомбами, которое в силу непонятной прихоти эволюции научилось делать и пускать в ход танки и ракеты. А вооруженные овцы гораздо опаснее вооруженных волков».

2015 елда экраннарга чыккан һәм Лантимосның беренче интернациональ проекты булган «Лобстер»да режиссер безне, үзенә генә хас почеркын һәм стилен саклаган хәлдә, әнә шул югарыда искә алынган хтоник Хаоска – Урманга кертеп ыргыта. Тамашачысы белән экран арасында аерым бер энергетика тудырырга сәләтле режиссер бер генә мизгелгә дә җиңел суларга ирек бирми. Син экранның бу ягында торганыңны онытасың, үзең дә корбанга яисә эзәрлекләүчегә әверeләсең. Әмма Лантимос тәкъдим иткән каст буенча, соң дәрәҗәдә атрофия, аморфлык күрсәткән геройлардан аермалы буларак, тыныч кала алмыйсың – синең ачыргаланып кычкырасың, котырасың, нидер исбат итәсең, нәрсәнедер төптән үзгәртәсең килә. Берәм-берәм то-



тып селкисең – персонажларны да, хәтта, буең җитсә инде, билгеле, режиссерның үзен дә. Әмма шул ук вакытта син төгәл беләсең: урамга чыгып, автобуска утыруга, метрога керүгә... сине нәкъ менә шушы персонажлар каршы алачак. Лантимос сине алдамый. Лантимос сиңа чынбарлыгыңны бар натурализмында күрсәтә.

Атрофиягә кучеп барган җәмгыять моделен ул шундый салкын, шома, иронияле, абсурд дәрәҗәсендә чагылдыра ки, син аның берара сурәте ягыннан да хайтек булмавына гаҗәпләнеп, тораташ булып торасың. Әйтерсең, салкынлыгы өчен бераз гына гафу үтенгәндәй, режиссер барокко сирпелешен бүләккә калдыра, винтажны, урыны белән XX гасыр азагындагы стильләр буталышын. Музыкаль яктан, антураж-интерьерлар җәһәтеннән дә чын эстет ул, неоклассика, хәтта ки классика тарафдары.

«Лобстер»ның хтоникасына күмелгәндә, безнең колакларны, шаштырыр дәрәҗәгә җиткереп, ау шаукымы һәм кулга төшү шомы белән бергә тагын да ныграк җилдерергә өндәгәндәй, Шостакович, Шнитке аһәңнәре яра башлый, аннан Бетховен белән Стравинскийга кучеп, медитативка көйләп, беразга гына ял бирә режиссер. Ә инде экзотиграк яңгыраган милли аһәңнәрне, яисә, киресенчә, популяр музыка прецедентларын реализм белән җепләр тартылган урыннар – геройларының эчке микрокосмы өчен калдыра.

Сюжет бик гади, ул, әйтерсең, без соңгы елларда инде иялэшеп беткән реалити-шоуларны (әйтик, «Дом-2» һәм аның Көнбатыш вариацияләрен) яисә дәвамлы сагаларны (мәсәлән, «Голодные игры») искә төшерсен өчен сайланган. Махсус кармак салынган, диярсең. Әмма тышкы катлам – алдавыч, Лантимос шартлаткычны иң ерак берәр бүлмәгә яшерә торган режиссер.

Ерак булмаган Киләчәк. Мондагы кануннар таләп иткәнчә, Шәһәр кагыйдәләренә буйсынып, Система кушканча, кешеләр гаиләләп яшәргә тиешләр. Ялгызакларны исә, аулап алып, Отельгә китерәләр, кунакханәдә алар 45 көн дәвамында, нинди дә булса уртак охшашлыкка нигезләнеп, тормыш иптәше табарга тиешләр. 45 көн дәвамында моны булдыра алмасалар, аларны кичекмәстән хайванга әйләндерәчәкләр. Хайваннарны котылгысыз рәвештә Урман көтә. 45 көнлек срокны озайтырга да мөмкин. Моның өчен Отель кунакларын һәр көн урманга ауга җибәрәләр. Урманнан ялгызакны аулап алып үтерсәң, аны өстерәп алып кайтсаң, сиңа тагын бер көн өстәлә. Димәк, бәхетле парлы тормышка шанслар да арта.

Коллин Фаррел герое – Давид – Отельгә этен ияртеп килә. Асылда, бу эт – аның ялгызаклар отрядына кучәргә мәҗбүр булган, парын таба алмыйча, хайванга әверелүгә дучар ителгән абыйсы. Давид исә, уңыш елмаймаган очракта, үзен лобстерга әверелдерүләрен тели. Һәм менә Отельдәге стериль шартларда стериль мөнәсәбәтләр урнаштыру омтылышы башлана. Кино тәнкыйтьчеләре «Лобстер» Инстаграм, Фейсбук, Телеграм, снэпчатлар пәрәвезендә яшәп, чынбарлыкны асылда бик берьяклы гына күзаллаган яшь буынга аеруча карарга киңәш итә. «Бу абсурд, әмма инде янәшәбездә яшәгән абсурд. Без бүген үк яңа буынның хисләрдән тоталь рәвештә баш тартуын, үзара мөнәсәбәтләрне файдага һәм үсеш өчен кирәкле охшашлыкларга йөз тотып кына, теләмичә коруын, һәр кешене җәмгыятьтәге уңыш критерие белән тамгалавын күреп торабыз. Смартфоннардагы иконкалар көннән-көн баш миебезгә ныграк кереп урнаша, ә алар аша дәүләт, аның системасы безнең шәхси мәгълүматларыбызга, тайчанмыйча, кулын тыга», – ди фильм турында «Медuza» блогеры, кино тәнкыйтьчесе Антон Долин.

Әйе, без хәзер, чыннан да, өстәлдәге тәлинкәгә ыспайлап (эстетика шулай куша, блюдо бит Инстаграмда пәйда булырга бик мөмкин!) салып куелган кыздырылган экзотик ризык – лобстер хәлендә. Банклар, кредиторлар да, эш белән тәэмин итүчеләр дә безнең хакта бөтен мәгълүматны белә. Пычак, чәнечкеләр хәстәрләп куелган – иллюзияләрдән арыныйк!

Әмма кешенең психологиясендә барыбер дә яшерен почмаклар кала. Аларына барып җитмәүләренең сәбәбе бер генә – кеше ул «тапларны» үзе дә белмәскә мөмкин. Нәкъ менә Фаррелл герое кебек – табылган яңа пары абыйсына кул күтәргәч, ничек кенә битараф һәм аморф булып күренергә тырышмасын, Давидта яшеренеп яткан (яшереп куелган) тойгылар уяна. Һәм ул ялгызаклар арасына – Урманга ыргыла. Ләкин Отель белән Шәһәргә капма-каршы булган Урманның да үз системасы, үз тоталитаризмы. Урыны-урыны белән хәтта Отельдәгедән дә хәтәррәк һәм аяусызрак. Биредә мәхәббәтен очраткан Давид, әлбәттә инде, моның юньлегә илтмәвен аңлый. Ялгызаклар дөньясында һәркем үзе өчен генә җавап бирергә, ни көткәнен яхшы белгәнгә, баштан ук үзенә кабер казып куеп, язмышына буйсынырга тиеш.

Ялгызаклар көтүе белән идарә иткән, бәйдә алагаем зур кабан дуңгызын иярте йөрткән (ул аның кеме булуын безгә режиссер үзебезгә уйлап бетерергә калдыра) ялгызак хатын-кыз – әлеге маргиналларның башлыгы – Давид белән аның сөйгәненнән үчен алган мизгелдән, гашыйклар гомумән системадан тыш хәлдә калалар. Алар Отельгә дә кайта алмый, Урманнан да куылырга тиеш. Хайванга әверелү ысулына икесе дә әзер түгел. Бу коточкыч кыргый, ерткыч, бары тик хисләр имитациясеннән генә гыйбарәт булган ярымүле дөньяда, шулай итеп, үзәк өзгеч матур, җылы, кешелекле мәхәббәт яралуын күрсәтә безгә Лантимос. Һәм бу мәхәббәт икесенең берсе үзен корбан китерү хакына гына яши алачак.

2015 елда фестивальләрдә күрсәтелгәннән соң картинаны «яңа гасырның кételмәгәнчә аяусыз, әмма иң романтик мәхәббәт драмасы» дип тамгаладылар. Рэйчел Вайс белән Колин Фаррелл героинясын, шулай итеп, киләчәктәге яңа тоталитар дөньяның Ромео белән Джульеттасы, яки, дөресрәге, Адәме белән Хәувасы дия алабыз. Алар – атрофиядән соңгы (димәк, күпмедер дәрәҗәдә постапокалиптик та) дөньяны яңадан үзгәртеп корырга ышаныч тудыручылар.



КОТЫ ОЧКАН КАМЕРА, ЯКИ БЕЗ МОНЫ КАРАР ДӘРӘҖӘДӘ КӨЧЛЕМЕ?

«Убийство священного оленя» фильмы узган сезонда Каннның иң шау-шу куптарган премьераларының берсе булды. Аны «коточкыч», «җирәнгеч» дип кискен кабул итмәүчеләр дә, «Лантимос гение тудырган шедевр» дип күккә чөюючеләр дә булды. Чыннан да, битараф калдырырлык лента түгел. Һәрхәлдә, караганнан соң, озак тынычлана алмый йөрисең. Ул сине кайта-кайта бимазалый, борчый, кадрлары күз алдыңнан китми.

Лантимос һәм Филиппу греклар булгач, фильмнан шунда ук грек мифологиясенә, антик сәнгатькә илтүче тамырларны эзли башладылар. Бу уңайдан Еврипид иҗатының тагы исәпләнгән, аның соңгы һәм иң көчле әсәрләреннән булган «Ифигения в Авлиде» трагедиясе еш искә алынды. Юкса, гадәттә хайваннар символикасы белән эш итәргә бик тә яратучы режиссер фильмында боланга ишарә гомумән юк кебек. Каян килгән ул алайса исеменә?! Менә нәкъ шул чакта тәнкыйтьчеләргә ярдәмгә Еврипид килде дә инде. «Ифигения»нең сюжетында грек мифы ята. Патша Агамемнон бервакыт ялгыш кына Артемиданың изге боланын үтерә. Артемида моңа бик нык ачулана һәм йөрәге үч алу хисе белән яна башлый. Ахыр чиктә, Агамемнон болан өчен тәүбә сорап, Артемидага үзенең кызын корбанга китерә.

Фильмнең фабуласы Еврипид трагедиясенә чыннан да аваздаш. Әмма Еврипидны һәм гомумән грек мифологиясен әллә ни белмәгән, сәнгатьтә интертекстуальлек барлыгы турында баш ватуны кирәк тапмаган караучы, иманым камил, бер 15 минуттан кинозалдан чыгып китәчәк яки «мин бу логикасыз әкәмәтне карамыйм» дип, башка фильмга күчәчәк. Лантимос бездән шушы эффектны көтә дә булса кирәк – «сүндерегез, карамагыз, берни дә булмагандай яши бирегез, әйдә, алга таба да!» Нәкъ безнең шикелле гадәти кешеләрнең экранда абсурд чигенә барып җитүләрен карап торганда, син чыннан да шаша башлагандай буласың: нәрсә соң бу, аңлатыгыз, дип сөрән саласың килә. Әмма акрынлап бу гадәти көндәлек тормыш (аның картинасы) артында упкын кебек ярылып бүгенге иҗтимагый кысаларга да, без үзебезне кертеп урнаштырган системага гына да сыешып бетә алмаган сәбәп-бәйләнешләр челтәре ятуын тоемлап аласың. Кыргыйлыгың, беренчел үзең, ялгызлыгың белән каласың. Ягъни, профан вакыт сакраль вакыт белән алышына – һәм менә без инде нинди дер вазыйфалар башкаручы, кемнеңдер әтисе-әнисе-кызы-улы, ниндидер институтның галиме, салымнар түләүче гражданины булудан туктыйбыз. Без беренчел, әле дөнья яратылган гына вакытларда хөкем сөргән хтоник курку белән күзгә-күз калабыз. Һәм безгә вакыйгалар чылбыры аңлашыла төшә башлый, без фабуланың мантыйгына тирәнрәк күмеләбез.

Музыка искиткеч ярдәм итә. Лантимос бу фильмында да караучысына деликатес әзерләгән – Шуберт, Гобәйдуллина, Бах… Фильмда хор да бар хәтта. Гәрчә, режиссер «мин аны планлаштырмаган идем», дисә дә. Финалның Бах белән тәмамлануы – әгәр бу Лантимос иронияесен дә сыйдырган картина булмаса, купшы һәм моветон буларак кабул ителер иде. Әмма Лантимос аның купшылыгын натурализм һәм кара юмор белән шунда ук сүндереп куя. Тагын бер ярдәмче – статик камера. Камераның хәрәкәтен ваемлап алган мизгелдән син аның да, нәкъ синең кебек үк, коты очкан яки ул бу дәрәҗәдәге хәшәрәтлекне карый алмый тораташка әйләнгән, дип уйлый башлыйсың.

Дөньясы түм-түгәрәк булган Америка кардиохирургы Стивен (Колин Фаррелл) врач хатыны (Николь Кидман), үсмер кызы, кечкенә улы белән шәп йортта яши, яхшы машиналарда йөри. Ул – танылган табиб, аны хөрмәт итәләр, югары бәялиләр. Алар – респектабельле тулы тормыш белән яшәүчеләр, уңыш елмайган затлар. Һәм менә Стивен көн саен диярлек сәер һәм чирканчык тәэсир калдыра торган, әле үсмерләргә хас бетчәләре дә төзәлеп бетмәгән үсмер малай белән очраша. Алар арасында баштарак диалог та бөтенләй юк диярлек. Әмма һәр хәрәкәтләреннән, карашларыннан, ым-сүзләреннән сәер бер сер бөркелә. Син, экранның бу ягыннан торып, андагы стериль-һавасыз атмосферага орынып ук диярлек (ә Лантимос сине, ничек кенә чиркандырмасын, экранга магиясе белән тартып ук китерә), чишелеш эзлисең: кем бу малай аңарга? Сөяркәсеме? Бу һәммәсе дә хөрмәт иткән урта яшьләрдән узып баручы мәһабәт табиб – яшь малайлар белән шаярырга яратучы бозык бәндәме? Аннан икенче уй өтеп ала: бу аның гаиләсеннән читтә туган улыдыр, мөгаен. Күрәсең, шуңа ул аңардан түләү таләп итә. Әмма акрынлап бу фаразлардан да арынасың. Ул арада бу беренче карашка һушны алырдай әдәпсез, оятсыз, мәрхәмәтсез малай аларның тормышларына тулаем үтеп керә, үз кагыйдәләрен билгели, үзенә буйсынуны таләп итә башлый. Ә аннары моның сәбәбе үлем икәнлеге ачыклана…

Менә Стивенның кызы белән улы, бернинди медицина логикасына сыймаганча, йөри алмый башлыйлар. Яңа танышлары кисәтеп куйганча, аннан кечкенә улларының күзләреннән кан ага башлый. «Бу – ахыр, дигән сүз» – вердикты шундый сәер килмешәкнең. Ә Стивен сайларга тиеш: кайсы баласын корбан итәргә әзер ул әлеге малайга. Чөнки алар арасындагы гаделлек тигезләшмәсә, аның бөтен гаиләсе һәлак булачак. Кемне сайларга – кызынмы, улынмы?

> «Убийство священного оленя» – үч һәм гаделлек турындагы картина. Бу тема миңа бик якын. Ә тагын ул безнең эгоизмыбыз, якыннарыбызга карата булган өстән-өстән генә мөнәсәбәтебез, битарафлыгыбыз турында. Ә менә кискен ситуация килеп чыкса, үлем белән хәл ителә торган хәлдә калсак, без сайлый алыр идекме? Карарлар кабул итү механизмы ничек эшли кешедә, мантыйк кайда да, чын-чынлап гаделлек кайда? Кеше яшәешенең төп кыйммәте нәрсәдә? Менә бу сораулар борчый мине. Мин шуларга җавап эзлим. Экстремал ситуациядә без әнә теге борынгы мәгарә-урамнардан килеп чыккан кыргый бәндәләр булып әвереләбез тагын…»
>
> *Йоргос Лантимос белән әңгәмәдән өзек.*

Ә цивилизацияле кешеләр үзләренең аң һәм күңел упкыннарына чумып, аның иң куркыныч, караңгы борылышларына күз салырга, һәм үзендәге үлчәү тәлинкәләрен тигезләргә тиеш, Лантимос фикеренчә. Мин аның белән килешми булдыра алмыйм. ■

Реклама 16+

PRESSA

МАХСУС ПРОЕКТ

— 35нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Ришат Хәбипов, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, октябрьдә үзенең 55 яшьлеген билгеләп үтә.

РИШАТ ХӘБИПОВНЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Ришат Хәбипов – 2013 елдан Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары. «Икътисадчы» белгечлеге буенча Казан финанс-икътисад институтын тәмамлаган. Баулы районы финанс бүлеге мөдире, Казан администрациясе финанс идарәсе башлыгының беренче урынбасары, Нурлат районы һәм Нурлат шәһәре администрациясе башлыгының беренче урынбасары, Татарстанның Мөслим муниципаль районы башлыгы булып эшли. Өйләнгән, ике ул һәм өч кыз үстерә. Октябрь аенда юбилеен – 55 яшьлеген билгеләп үтә.

Миндә традицияләр бик көчле. Безнең авылда шулай кабул ителгән: әгәр турникта тартыла алмыйсың, ат җигә, көрәкне яисә чүкечне дөрес тота белмисең икән – димәк, син безнең нәселдән түгел. Бөтенебез булдырырга тырыша идек! Без апа белән, эти эштән кайтканчы, өйне дә җыештырырга, дәресләрне дә әзерләргә, фермада эшләүче әнигә дә булышырга тиеш идек. Өй тирәсендәге эшләр барыбызга да бүленгән. Тәрбия көчле булды. 8 нче классны бары тик «5» билгеләренә генә тәмамладым. Урта мәктәп күрше авылда урнашкан иде, шуңа күрә җәяү дә, чаңгыда да күп йөрергә туры килде. Классыбыз зур, 37 бала укыды. Кыска гына вакыт эчендә класста да, мәктәптә дә абруй казана алдым – мине мәктәп комсомол оешмасы секретаре итеп сайладылар.

Класс җитәкчем – рус теле һәм әдәбияты укытучысы Камил Галиевичне хөрмәт итә идем. Беренче дәрестә ул бездән «Распрягайте, хлопцы, коней» җырын белүебезне сорады һәм үзе җырны сузып та җибәрде. Без, әлбәттә, бу җырны беренче мәртәбә генә ишетә идек. Ә Камил Галиевич төрле телләрне һәм мәдәниятләрне өйрәнергә тырышырга кирәк диде. Аннан соң укытучыбыз яхшы оештыручы һәм спортчы да булып чыкты. Аның җитәкчелегендә классыбыз чын команда булып тупланды. Ул безне җиңәргә өйрәтте!

Әтием чын белгеч, партия хезмәткәре, идеяле кеше иде. Пенсиягә чыккач та, туган авылың урамы буйлап атлаганда оят булмаслык итеп эшләргә кирәк, дип өйрәтте ул безне. Ә миңа тормышымда берничә мәртәбә оялырга туры килде. Үзгәртеп кору елларында мин Баулы районы финанс бүлеген җитәкли идем. Нефтьчеләр һәм укытучылар айлар буе хезмәт хакы ала алмыйлар иде. Иртән администрациягә киләләр, эшкә килгәндә, туктатып, балаларын ашатырга һәм киендерергә ни өчен акча юклыгын сорыйлар. Мәгариф хезмәткәрләренә кайбер районнарда хезмәт хакын аракы заводлары продукциясе белән түлиләр иде. Без, соңгарак калып булса да, акчалата бирергә тырыштык. Бу вакыт хезмәт юлымда иң катлаулы чор булып хәтергә кереп калды.

Армиядә мин политрук ярдәмчесе булдым, ә сәяси бүлек башлыгының фамилиясе – Ганжа. Без Монголиядә хезмәт иттек. Политрук болай дияргә ярата торган иде: «Иптәш Хәбипов, без үзебезне шундый итеп тәрбияләргә тиеш, әгәр безне чүлгә алып китеп ташлыйлар икән, без 20 минут эчендә үзебезнең тарафдарларыбызны, дөяләрне генә булса да, табып, сәяси җыелыш үткәрергә әзер булыйк!» Бүген төрледән-төрле идарә тренинглары үткәрәләр, ә бит алар күптәннән бар инде. Миңа калса, синең ниндирәк җитәкче булуың, иң беренче чиратта, үзең белән идарә итә белүеңнән тора.

Балачакта хыялым бар иде. Әби безне иртә уята, сәгать алтыда иртәнгене ашаган була идек. Шул вакытта радиодан республика буенча булачак һава торышы белән таныштыралар. Чулпанда – минус утыз, Мөслимдә – минус кырык. Казанда –... «Әби, нинди матур исемнәр! Шунда барсаң иде ул!» – дия идем мин әбиемә. Малай чак теләкләрем кабул булды, «Аллаһы Тәгаләнең амин дигән вакытына туры килгән!» – диләрме әле. Миңа башкалабыз Казанда да, Мөслим районында да эшләргә туры килде. Ә Чулпан – Нурлат районындагы авыл ул. Биредә мин ике елдан артык Нурлат районы һәм Нурлат шәһәре администрациясе башлыгы Фатыйх Сәүбәнович Сибгатуллинның беренче урынбасары булып эшләп, яхшы тормыш мәктәбе уздым. Нәкъ менә шунда, көчле, кырыс җитәкче кул астында эшләп, икмәкне үстерү, һәр юнәлеш буенча югары нәтиҗәләргә ирешү серләренә өйрәндем. Әлеге тәҗрибә миңа Мөслим муниципаль районы башлыгы булып эшләгән елларымда да нык ярдәм итте. Районның табигате бик матур, җирләре уңдырышлы, ә иң мөһиме – монда талантлы һәм хезмәт сөючән халык яши. Алар мине җитәкчеләре буларак кабул иттеләр, һәм мин 12 ел хезмәтемне мөслимлеләргә багышлавым белән бик горурланам. Күңелдә бары тик якты истәлекләр генә саклана.

Баулыда инде пенсиягә чыккан фининспектор әле сугышка кадәр үк шулай ук фининспектор булган бабам белән бергә эшләгән һәм аның турында бик югары фикердә иде. Мин финансист профессиясенә тап төшермәслек итеп эшләргә тырыштым. Финорганда эшләү мине өч нәрсәгә өйрәтте. Беренчедән, җентеклелеккә. Икенчедән, сакчыллыкка. Өченчедән, гаделлеккә. Минем кул аша миллион сумнар үтә, әмма синә ул акчаларга кызыгырга, кагылырга ярамый. Ул – дәүләт акчалары, халык акчалары һәм һәр тиен өчен син хисап тотарга тиешсең.

Кайсы гына вазыйфамны биләсәм дә, нәрсәгә булса да өйрәнерлек кешеләрне очраттым. Алтынчы класстан башлап Ленин ордены кавалеры – Хәйдәр Хәеров – Хәйдәр абыйда комбайнчы ярдәмчесе булып эшләдем. Ул чын хезмәт кешесе иде, аңа ярышу рухы хас, ул һәрвакыт беренчелеккә омтылды! Мине Баулы башкарма комитеты партоешмасы секретаре итеп сайлаганнан соң, коллегаларым белән бергә паркны чистартырга булдык. Башкарма комитет каршында өрәңгеләр куерып үскән, шуларны кисәргә уйладык. Шунда ук канәгатьсезлек белдерергә күрше йортларда яшәүчеләр җыелды. Мин аларның һәрберсенә бу урында Бөек Ватан сугышында катнашучылар хөрмәтенә ачылырга тиешле паркның

Фотолар ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

дәвамы булачагын аңлаттым. Безнең идеяне районның яңа җитәкчесе Зарипов Наил Шамилевич тә хуплап алды. Тирә-якны матурлап-чистартып бетергәч, сугышчан техника үрнәкләрен урнаштырырга булдык, танк, гаубица, БМП-1 китерттек. Постаментын әзерләдек, ә танкны күтәреп куярга кран юк… Агроснаб җитәкчесе, танк гаскәрләрендә хезмәт иткән Равил Хәбипов танкны кабызды һәм блоклар буйлап сугышчан машинаны постаментка менгереп куя алды. Бу Җиңү көне алдындагы кич иде. Тирә-юньгә халык җыелды, алкышлар ишетелде, кешеләрнең йөзендә бәхет балкый иде.

Шундый ук паркны мин Мөслимдә дә яңадан төзедем. Мөслим районыннан сугышка җиде меңнән артык кеше китә, аларның ике меңенә генә кире әйләнеп кайтырга насыйп була. Паркта урнаштырылган стелаларда яу кырларында ятып калганнарның исемнәрен мәңгеләштердек. Советлар Союзы Геройларының һәм Социалистик Хезмәт Геройларының бюстларын, әфган сугышында катнашучыларның барельефларын урнаштырдык, мәңгелек ут кабыздык! Ә 9 май – паркны ачу көнендә һәм сәгатендә кинәт көнә шаулап яңгыр ява башланды. Шунда ветераннарның берсе, бу әйләнеп кайтмаганнарның күз яшьләредер, дип әйтеп куйды… Паркка исемне халык үзе бирде – Җиңү паркы… Бүген дә халык паркка йөри, стелалар һәм геройларның бюстлары янында чәчәкләр куела.

Бервакыт без бассейн төзергә булдык. Мәктәп ачылышы иде, тантанага Минтимер Шәймиев тә килде. Без инсценировка эшләдек – балалар йөзгән хәрәкәтләр ясады. «Без йөзүчеләр! Без йөзүчеләр!» – диләр алар. Ә алып баручы каршы әйтә: «Сез нинди йөзүчеләр буласыз? Сез төзүчеләр! Без яңа мәктәп ачабыз!» Ә балалар: «Юк, без йөзүчеләр!» – дип үзләренекен такмаклый. Минтимер Шәрипович, әлбәттә, барысын да аңлады. Һәм Марат Хөснуллинга (2002–2010 елларда ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры. – **Ред. иск.**) объект төзелешен планга кертергә күрсәтмә бирде. Шулай итеп Мөслимдә 2004 елда республика авыл җирлегендә беренче бассейн барлыкка килде.

Республиканың инфраструктур үсеше Минтимер Шәрипович инициативасы нәтиҗәсендә башланып китте. Ул һәрвакыт авыл тормышын яхшырта торган проектларны хуплап килде. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрипович һәм Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевич – талантлы җитәкчеләр, аларның тәҗрибәсе халыкка хезмәт итүнең менә дигән үрнәге була ала. Газлаштыру, аварияле торактан күчерү программалары – бары тик әлеге ике проектны гамәлгә ашыру гына да меңләгән татарстанлыны бәхетле итте! Бүген республикада 38 программа уңышлы тормышка ашырыла, шуларның 28е авыл хуҗалыгына карый

Татарстан илнең аграр секторында өченчелекне били, һәм бурыч – ел саен процентларның үсешенә ирешү. Марат Готыфович Әхмәтов – шәп җитәкче, вазгыятьне даими контрольдә тота һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү өчен кадрларның никадәр мөһим икәнлеген яхшы аңлый. Безнең АСК коллективы бердәм, көйле эшли, без республика халкын үз авыл хуҗалыгы продукциябез белән тулысынча тәэмин итәргә сәләтле.

Фермерлар – заманыбыз геройлары. Эшеңне ачасың икән, үзеңне 24 сәгатькә шуңа бәйләп куясың. Шул ук вакытта күпме финанс куркынычы яный. Бүген Россия төрледән-төрле сынауларга дучар ителә, шул нәтиҗәләрнең берсе – зур күләмдә коры сөт кертелү. Аңардан түбән сыйфатлы яңадан торгызылган сөт ясыйлар. Бу вакытта бәяләр демпингы барлыкка килә. Күрәсең, халык мал-туарын иткә җибәрер, иген икми башлар дигәнгә өметләнәләр. Татарстан яклау механизмнарын эшләтеп җибәрде: Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов указы белән сөтнең үзкыйммәте һәм сату бәясе арасындагы аерманы түләү өчен 2 млрд сум акча бүленде. Язын минераль ашламалар сатып алуга –1 млрд сум, авыл хуҗалыгы техникасын яңартуга – 1 млрд сум бирелде. Кайбер портларда бер тонна бодайга бәяләрнең – 12 мең сумга, арпага – 11 мең сумга җитүе безне куандыра. Сөтнең бер литры өчен бәя 19–20 сум, ул әле арта бара. Шул ук вакытта республиканың 35 районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерларның баш саны артуы күзәтелә. Бу үзгәрешләрдә күп очракта республика программаларының уңай йогынтысы сизелә.

Минем артта каласым килми. Техник прогресс бара, аны актив кулланырга кирәк. Роботлар – авылда кадрларга кытлыкны алыштыра алырдай ресурс. Биектау районыннан фермер Минсинә Латыйпова беренчеләрдән булып ике сыер савучы робот алу өчен субсидиягә гариза бирде. 30–40 мең хезмәт хакына сыер савасылары килми, чөнки янәшәдәге шәһәрдә шул ук акчаларга җиңелрәк эш табарга була. Бер робот 12 млн сум тора. Без ярты бәяне субсидияләү вариантын карыйбыз. Без шулай ук һәр фермер өчен 1С «Идарә аппараты» программасын урнаштыру юнәлешендә эшлибез. Бу үз бухгалтеры булмаганнар өчен бик уңайлы булачак. Фермер үтә күренмәле хисапларын тиз арада күрсәтә алганда теләсә кайсы кредитны ала алачак. Һәм бу үз продукцияңне онлайн-мәйданчыкларда сата алу юнәлешендә дә зур адым булыр иде. Программага өйрәтү өчен без аналитика үзәге һәм авыл хуҗалыгы кооперацияләрен үстерү буенча компетенцияләр үзәге төзибез.

Һәр кеше теләгәненә өйрәнә ала, иң мөһиме – стимул. Әгәр син гармунда яисә баянда уйный, җырлый һәм бии белмисең икән, безнең мәктәптә син инде шәп егет санала алмый идең. Минем гармунда уйнарга өйрәнергә теләгем бик зур иде. Әтием ягындагы барлык ир туганнарым шикелле үк гармунда да, баянда да уйнарга өйрәндем. Бүгенге көнгә кадәр күңелем тартканда кичләрен рәхәтләнеп яраткан көйләремне уйныйм. Олы кызым музыка мәктәбенең фортепиано классын, уртанчысы гитара классын тәмамлады. Кече кызым скрипкага өйрәнә. «Әтием, нигә мине иң авыр инструментка бирдегез?» – дип зарлангалый ул. «Чөнки, кызым, без сине бик яратабыз. Кеше һәрвакыт югарыга омтылырга тиеш», – дип җавап бирәм мин.

«СОЮЗХИМПРОМПРОЕКТ» ПРОЕКТ ИНСТИТУТЫНА – 65!

Сугыштан соңгы икенче бишьеллык бара. Җимерелгән предприятиеләр, шул исәптән оборона сәнәгатенә караган заводлар инде шактый күләмдә торгызылган. Сугыш тәмам, ләкин дөнья әле тыныч түгел. НАТО блогы төзелә, салкын сугыш көч ала. СССРны потенциаль дошманнарның базалары уратып алган. Тышкы куркыныч янауга каршы торыр өчен, сәнәгатьнең оборона тармакларында куәтле ыргылыш таләп ителә.

Ул вакытта сугыш припаслары һәм махсус химия тармаклары заводларында кул көче күп кергән һәм җитештерүдә имгәнүләр зур булган иске технологияләр өстенлек иткән. Җитештерүләрне модернизацияләү, заманча җиһазларны, яңа технологияләрне гамәлгә кертү, кул хезмәтен кыскарту таләп ителә. СССР хакимиятенең иң югары органнары 1951–1955 елларга илнең үсеш бурычларын билгеләгән директив документларында капиталь төзелешкә, шул исәптән оборона тармаклары предприятиеләрен модернизацияләүгә, рекордлы күләмдәге акчалар бүлеп бирүне билгели.

Проект оешмаларының фундаменталь базасыннан һәм белгеч-проектлаучылардан башка эре масштаблы капиталь төзелеш алып барыла алмый. Бу хәл проект оешмаларының җитештерү-техник базасын киңәйтү һәм ныгытуны, сәнәгать проектлавы өлкәсендә махсуслаша торган проектлаучыларның санын арттыруны таләп итә.

Капиталь төзелеш һәм сугыш припаслары, махсус химия җитештерүе предприятиеләрен модернизацияләү программаларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән бурычларны чишү өчен, СССР Министрлар Кабинетының 1953 елның 8 июнендәге карары белән Казанда Мәскәү дәүләт союз махсус институтының филиалы оештырыла. Шул ук елда яңа ачылган институтның директоры итеп Николай Андреевич Кондратенко билгеләнә, ул институтка 1983 елга кадәр җитәкчелек итә.

Алга таба «Союзхимпромпроект» институты итеп үзгәртелгән филиалның беренче директорын билгеләү көне – 1953 елның 30 сентябре – рәсми рәвештә аның туган көне дип тә исәпләнә. Филиалга эшли башлаганда Казан дары заводы идарәсендә 20 квадрат метрлы бина бирелә, штатында 20 хезмәткәр исәпләнә. 1953–1957 еллар эчендә филиалның төп структурасы формалаша, кирәкле юнәлешләр буенча белгечләр әзерләнә һәм проектлау эшенең тиешле матди-техник базасы булдырыла.

1971 елда Мәскәү проект институтының Казан филиалы мөстәкыйль «Союзхимпромпроект» Химия предприятиеләрен проектлау буенча дәүләт союз махсус институты итеп үзгәртелә. 1977 елга институтта тармакның сәнәгать объектларын комплекслы проектлау өчен кирәкле подразделениеләр составында тулы бер структура оеша һәм проектлау юнәлешләре билгеләнә: пироксилин һәм баллистит дары, хәрби һәм сәнәгать билгеләнешендәге шартлаткыч матдәләр, янып бетүчән гильзалар, артиллерия утлары җитештерүләрен, һәм шулай ук алар белән бәйле предприятиеләрнең инженер инфраструктурасы объектларын проектлау.

1985 елга институт карамагында 12 000 квадрат метрдан артык сәнәгать мәйданы исәпләнә, штатта 800дән артык кеше хезмәт куя, үзенең торак фонды, ике балалар бакчасы, «Аккош күле» урман зонасында балалар өчен дачасы һәм Идел яры буенда ял базасы була, спорт залы эшли. Институтта заманы өчен иң камил саналган ЕС серияле гомумсәнәгать ЭВМнары базасында автоматлаштырылган проектлаштыру актив рәвештә гамәлгә кертелә.

1985 елга институт 26 сәнәгать предприятиесе һәм ФТИ өчен генераль проект оешмасы санала, ә гомумән алганда, ул Машина төзелеше министрлыгының СССР территориясендә урнашкан 50дән артык предприятиесе өчен эшләр башкара.

1990 нчы еллар башында оборона тармаклары предприятиеләрендә капиталь төзелешне финанслауның тәмамлануы һәм проект эшләренә заказларның булмавы сәбәпле, институтның саклап калу мәсьәләсе көн кадагына баса. Башка бик күп предприятиеләр шикелле үк 1991 елдан 1996 елга кадәр институт җитәкчелеге финанс-икътисадый хәлне тотрыклыландыруга юнәлдерелгән кайбер чик чараларны күрергә мәҗбүр була: әйтик, хезмәткәрләрнең санын кыскарту, буш калган җитештерү мәйданнарын арендага бирү, Дәүләт мөлкәте комитеты карары буенча ике җитештерү корпусын – Татарстан Республикасы ЭЭМ карамагына, торак һәм социаль билгелә-

Фото «Союзхимпромпроект» проект институтыннан алынды
Реклама



нештәге барлык объектларны шәһәр балансына тапшыру.

Шулай да әлеге чаралар институтны карап тоту, аның хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү, башка чыгымнарны каплау өчен акча эшләү мөмкинлеге бирми. Мондый вазгыятьтә институтны һәм аның кадрлар потенциалын саклап калуга юнәлдерелгән бердәнбер дөрес карар эшчәнлекне диверсификацияләүгә һәм юнәлешен үзгәртүгә юл алу, шулай ук профильле фәнни-тикшеренү эшчәнлеге алып барган структуралар белән кушылу ихтималын кабул итү була. Соңгысы 1997 елда Россия Хөкүмәте карары белән Казан химия-технология университеты составына кушылу аша тормышка ашырыла.

1990 нчы елларда Россиядә билгеле бер үсеш потенциалын саклап кала алган сәнәгать тармакларыннан нефть һәм газ табуны, һәм алар белән бәйле нефть-газ эшкәртү һәм нефть химиясе өлкәләрен атарга була. Татарстан Республикасы территориясендә эре нефть химиясе предприятиеләре урнашу сәбәпле, институтның киләчәккә үзенең нинди төп үсеш юнәлешен сайлавы көн кебек ачык була. Институтка үз проектларында катнашуны ышанып тапшырган иң беренче предприятиеләр Татарстан Республикасы нефть химиясе тармагына карый, алар арасында «Түбән Кама Нефтехим» ААҖ төп хезмәттәшкә әверелә. Әйтик, институтның иң беренче мөһим проектлары арасында «Түбән Кама Нефтехим» ААҖндә бер стадияле технология буенча мономер изопрен җитештерүне төзелеше өчен документацияләрне әзерләү бар.

Шуннан бирле институт әкренләп үз эшчәнлеге кырын киңәйтә, кадрлар потенциалын торгыза, проектлау технологияләрен камилләштерә һәм даими заказчылары даирәсен арттыра бара. Институтка Татарстан Республикасы һәм башка төбәк икътисадларының флагман предприятиеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күп миллиардлы инвестицияле проектларда катнашуны ышанып тапшыралар. Атап әйткәндә, институт тарафыннан «Түбән Кама Нефтехим» ААҖндә синтетик каучук һәм полимерларның кайбер күп тоннажлы җитештерүләрен төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан кораллландыру өчен документация әзерләү башкарыла.

2007–2014 елларда институт Татарстан Республикасында мөһим инвестицияле проектларны гамәлгә ашыруда катнаша, алар арасында – Менделеевскида аммиак, метанол һәм карбамид җитештерү комплексы, «Түбән Кама Нефтехим» ААҖ өчен йөк автомобильләренә тоташ металл кордлы шиннар җитештерү заводы, «Казан май заводы» ААҖ өчен кетчуп, майонез һәм соуслар җитештерү заводы, «Химград» технопаркы, «ТАНЕКО» ААҖ инженер инфраструктурасы объектлары, «ТАИФ-НК» ААҖнең авыр нефть калдыкларын тирәнтен эшкәртү комплексы.

Төбәктән читтә институт эшләгән документация буенча гамәлгә ашырылган эре проектлар арасында «Сибур» компаниясенә керүче «Воронежсинтезкаучук» ААҖндә еллык куәте 50 мең тонна булган термоэластопластлар җитештерүен атарга кирәк.

2018 елда институт җитештерүне еллык куәте 100 мең тонналык итеп үзгәртүне күздә тоткан документация эшләүгә керешә.

2016 елда институт Түбән Камадагы «СафПЭТ» ҖЧҖ өчен еллык куәте 210 мең тонналык терефталь кислотасы һәм еллык куәте 250 мең тонна булган полиэтилентерефталат җитештерүе инженерлык инфраструктурасы объектлары төзелеше өчен документация әзерләүгә подряд ала.

Институт эшчәнлегенең төп юнәлеше Россия икътисадының гомуми тенденциясенә туры килә. Төп өстенлекләрнең берсе – чи нефть һәм газны читкә чыгарудан аларны эшкәртү аша югары өстәмә кыйммәткә ия продуктлар җитештерүгә күчү. Нефть химиясе тармагы актив үсә, гамәлдәге предприятиеләр реконструкцияләнә һәм яңартыла, яңалары төзелә. Институт өчен әлеге тармак өстенлекле санала һәм эшчәнлегенең шактый зур өлеше синтетик каучук һәм полимерлар җитештерүләрен төзүгә караган инвестицияле проектларда катнашуга бәйле.

Институтның икенче төп өстенлекле эш юнәлеше – үз эшчәнлегенең күп профильле булуын саклап калу һәм киңәйтү, моңа бәйле рәвештә эш планнарында үсемлекләрне саклауның химик чараларын, синтетик юуу матдәләрен, пластмассаны эшкәртү, махсус химия җитештерүләре объектлары, инфраструктура объектлары кебекләр даими позицияләрне алып тора.

Институтта төрле белгечлекләргә ия югары квалификацияле хезмәткәрләр эшли, кадрлар составы Казан вузларын тәмамлаган яшь белгечләр хисабына яңартылып һәм тулыландырылып килә. Институтның матди-техник базасы проектлауның иң прогрессив технологияләрен куллануны тәэмин итә, шул исәптән өч үлчәнешле проектлауны, инвестицияле проектларда катнашучылар белән видеоконференция элемтәләрен оештыруларны да үз эченә алып.

Оешуларының 65 еллыгын билгеләп, хезмәт җиңүләрен һәм артта калган авыр көннәрне искә алып, институт коллективы киләчәккә, шул исәптән республика киләчәгенә дә зур ышаныч белән карый!

Ышанычлылыкны дәлилләп...

Азат Бикмурзин,
«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Павел Владимирович! «Союзхимпромпроект» институтының барлык хезмәткәрләрен дә күркәм юбилей белән тәбрикләргә рөхсәт итегез! Сәнәгать проектлаштыруы өлкәсендә шактый зур ресурсларга ия һәм даими үсештәге институт менә инде 65 ел дәвамында химия сәнәгатенә караган иң эре объектларны проектлый.

Татарстан Республикасы нефть химиясе предприятиеләре, шул исәптән «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, «Союзхимпромпроект»ка үзләренең үсеш программаларында катнашуны ышанып тапшырган беренче заказчылар булып торалар. Шунысын әйтергә кирәк: безнең озак елларга сузылган хезмәттәшлегебез нәтиҗәле һәм үзара файдалы булды.

Бүген проект предприятиеләренә яңа белемнәрдән, югары квалификацияле кадрлардан, проектлауның заманча технологияләреннән, даими заказчылар даирәсен тотрыклы арттыра барудан башка көндәшлекле булу мөмкин түгел. Бу аларның уңышлы эшчәнлеге нигезе. «Союзхимпромпроект» җитәкчелеге һәм хезмәткәрләре заманыбызның барлык таләпләренә җавап бирә, институтка Татарстанда гына түгел, аннан читтә дә гамәлгә ашырыла торган иң әһәмиятле инвестицияле проектларда катнашуны хаклы рәвештә ышанып тапшырулары да очраклы хәл түгел.

Профессиональлек, тотрыклылык һәм партнерларның ышанычы – СХППның уңышлы киләчәгенә өмет уятучы төп нигез. Республика нефть химиясе сәнәгате элеккегечә үк актив үсештә, гамәлдәге предприятиеләр реконструкцияләнә һәм яңартыла, яңа җитештерүләр сафка баса. Шуңа күрә проект институтын, һичшиксез, яңа проектлар һәм заказлар көтә! Юбилеегыз белән сезне!

Фото «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ матбугат хезмәтеннән алынды

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН
TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:
тел: (843) 222-06-05

Реклама 16+

Сез иң катлаулы бурычларны да чишәргә сәләтле

Хөрмәтле Павел Владимирович, «Союзхимпромпроект» проект институтындагы коллегаларым!

«Казан Гипронииавиапромы» Компанияләр төркеме исеменнән Сезне институтыгызга нигез салынуның 65 еллыгы белән тәбрик итәм!

Үз эшчәнлегегезне алып барган еллар эчендә Сезнең коллектив илебез химия сәнәгате – төп органик һәм органик булмаган синтез, нитроэфирлар, сәнәгать билгеләнешендәге шартлаткыч матдәләр, дары, нитроцеллюлоза, этил спирты, диэтил эфиры һ.б. җитештерүләрне төзү, саклау һәм модернизацияләү буенча гаять зур эш башкарды. Сез Украина, Казахстан, Үзбәкстан, Таҗикстан территорияләрендәге эре комбинат һәм заводларны, һәм шулай ук Гыйрак, Сүрия, Чехословакия, Болгария кебек илләрдәге сәнәгать җитештерүләрен генераль проектлауда катнаштыгыз.

Бүген дә Сез АКШ, Италия, Германия, Швеция, Швейцария җиһазлары нигезендә нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводларының иң эре комплексларын, социаль-мәдәни һәм гражданлык төзелеше, энергия белән тәэмин итү һәм инженер корылмалары объектларын проектлауны уңышлы башкарасыз.

«Системалы проектлауга» сәләтле, эшнең югары сыйфатын тәэмин итүче, теләсә кайсы катлаулылыктагы бурычларны заманча дәрәҗәдә хәл итә белүче коллективыгыз Татарстан Республикасы һәм Россия төзелеш комплексы җитәкчелеге һәм белгечләре тарафыннан һәрвакыт югары бәяләнә.

Безнең институтларны закончалыклы рәвештә уңышлы уртак иҗади эш бәйли: Көнбатыш Елга аръягы ПДП, Буа спирт заводы, «Идея» технопаркы, «Иннополис» киләчәк IT-паркы һ.б.лар.

Институтыгызның 65 еллыгы кебек күркәм юбилей көннәрендә Сезгә зур иҗади уңышлар, алга таба да иминлек һәм муллык телибез!

Борис Тихомиров, «Казан Гипронииавиапром» АҖ генераль директоры



Фото «Казан Гипронииавиапромы» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды
Реклама

КАЗАН ДӘҮЛӘТ ЭНЕРГЕТИКА УНИВЕРСИТЕТЫНА – *50 яшь!*

Казан дәүләт энергетика университеты, Идел буе һәм Урал төбәгендәге бердәнбер энергетика вузы, үзенең 50 еллык юбилеен билгеләп үтә. Республика энергетикасының һәм сәнәгатенең көчле үсеше елларында оештырылган вуз энергетика тармагы өчен кадрлар әзерләү буенча җитди мәгариф һәм фән үзәгенә әверелде. Университет составына 4 институт керә, анда 33 кафедра эшли. Биредә 470 укытучы мөгаллимлек итә, 10 меңгә якын студент укый. Студентларга белем алу һәм яшәү өчен лаеклы шартлар, җитештерү белән интеграция, заманча фәнни-тикшеренү лабораторияләре һәм җиһазлары, уку-өйрәнү полигоны, илебез һәм чит илләрдәге компанияләр белән актив хезмәттәшлек – болар барысы да бүгенге Казан дәүләт энергетика университеты.

Тотрыклы киләчәге һәм бүгенгесе булган вуз

Борис Тихомиров,
«Казан Гипрониавиапромы» АҖ генераль директоры

– 50 ел зур срок түгел кебек. Ләкин үткәне вакыйгаларга һәм күренекле шәхесләргә бай вуз өчен бу аз вакыт түгел. Казан энергетика университеты – тотрыклы бүгенгесе һәм киләчәге булган перспективалы вуз.

Бүген республикабызның динамик үсештәге энергетика тармагы заман таләпләренә җавап бирүче квалификацияле кадрларга ихтыяҗ кичерә. Аларны әзерләү өчен университетта барлык шартлар да тудырылган: заманча фәнни-тикшеренү лабораторияләре, уку-өйрәнү полигоны, төрледән-төрле белем бирү проектлары, инновацияле уку кирәк-яраклары, студентларның укуы һәм көнкүреше өчен лаеклы шартлар. Белем алу этабында ук студентларны производствога җәлеп итү оештырыла һәм иң мөһиме вузның югары һөнәри дәрәҗәдәге мөгаллимнәр составы бар. Вуз үз һөнәренә тугры, акыллы, булдыклы, максатчан яшьләрнең бер генә буынын укытып-тәрбияләп чыгармады. Аларның күбесе бүген «Казан Гипрониавиапромы» АҖндә хезмәт итә.

Уку йортының уңышларында аның күп меңле хезмәткәрләре, студентлары, аспирантлары һәм белгечләре коллективының гаять зур һәм тырыш хезмәте ятканын билгеләп үтми мөмкин түгел.

Партнер предприятиеләр буларак, без бер генә ел уңышлы хезмәттәшлек итмибез, һәм алга таба да бу нәтиҗәле аралашуның дәвам итәчәгенә ныклы ышаныч бар.

Эдвард Юнысович! Сезне һәм сез җитәкләгән Казан энергетика университетының студентлар, аспирантлар, укытучылар һәм хезмәткәрләр коллективын уку йортына нигез салынуның 50 еллыгы белән ихлас котлыйм! Сезнең командагыз әле озак еллар дәвамында меңләгән иң яхшы студентлар белән тулыланып торсын. Барыгызга да ныклы сәламәтлек, бәхет, иҗади уңышлар һәм бары тик алга гына хәрәкәт итәргә насыйп булсын!

Реклама Фото «Казан Гипрониавиапромы» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Иң кыю идеяләрне һәм проектларны гамәлгә ашыру насыйп булсын!

Рифнур Сөләйманов,
«Татэнергосбыт» АҖ директоры

Хөрмәтле Эдвард Юнысович!
Хөрмәтле Казан дәүләт энергетика университеты студентлары, вузны тәмамлаган белгечләр, педагоглар һәм хезмәткәрләр!

Үз исемемнән һәм «Татэнергосбыт» АҖ коллективы исеменнән КДЭУның 50 еллык юбилее белән Сезне ихлас тәбрик итәм!

Сезнең миссия – энергетика тармагында Татарстан һәм Россия предприятиеләренең сыйфатлы, иң яхшы кадрларга булган ихтыяҗын тәэмин итү. Шуны күздә тотып, республика һәм гомумән илнең энергетика сферасындагы төп вуз менә инде ярты гасыр һөнәри әзерлекләре югары булган белгечләр әзерли. Ә бит энергетикада, башка бер генә өлкәдә булмаганча, күп нәрсә хезмәткәрләренең компетенциясеннән тора. КДЭУны һичшиксез инженер кадрлар әзерләүнең алдынгы мәктәбе дип атарга мөмкин. Шушы еллар эчендә әлеге вуз безнең өчен чын-чынлап үзебезнекенә әверелде! «Татэнергосбыт» АҖндә бүгенге көндә университетны тәмамлаган 270тән артык белгеч эшли. Һәм ел саен коллективыбызга яңа дипломантларны кабул итә барабыз. Вуз аларга белем биреп кенә калмый, дөрес тормыш омтылышлары да тәрбияли: яшь белгечләр актив, барлык яңалыкка ачык, республика иминлеге хакына тырышып эшләргә әзер торалар, аларның профессияләренә ихтирам рухында тәрбияләнгән булуын күрү дә сөендерә.

Без университет белән җылы, дустанә мөнәсәбәтләр урнашканга бик шат. Бу шулай ук Татарстан Республикасында энергияне һәм ресурсларны саклау технологияләрен куллануны алга этәрү юлында гамәли бурычларны чишү максатында 2014 елда өч як – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Казан дәүләт энергетика университеты һәм «Татэнергосбыт» АҖ – катнашлыгында төзелгән Энергия нәтиҗәлелеге һәм энергияне саклау технологияләре һәм компетенцияләренең инновацияле фәнни-белем бирү үзәге дә. Студентларның производство һәм диплом алды практикаларын оештыру да. Гамәли һәм фундаменталь тикшеренүләрдәге уңышлары өчен иң яхшы студентларга «Татэнергосбыт» АҖ стипендияләрен һәм Ф.З.Тинчурин исемендәге стипендияләрне тапшыру да. Без алга таба да предприятие белән вуз өчен уртак булган юнәлешләрдә хезмәттәшлек итәргә җыенабыз. Алай гына да түгел, әлеге элемтәләрнең Татарстан һәм Россия энергетика тармагы иминлеге хакына алга таба тагын да ныграк булачагына ышанабыз!

Тагын бер кат КДЭУ коллективын университетның 50 еллыгы белән котлавыма ихлас шатланам һәм әлеге уңайдан сезнең профессионализмыгыз нәтиҗәсендә ике арада урнашкан эшлекле хезмәттәшлегебез өчен рәхмәтемне белдерәсем килә. Университетта тупланган бай тәҗрибә, белем бирү инновацияләре, җиһазландырылуның заманча дәрәҗәсе, вузның база предприятиеләре белән тыгыз элемтәләре көткән нәтиҗәләрне бирми калмас дип ышанам. Иҗади уңышлар сезгә, иң кыю идеяләрегезнең һәм проектларыгызның тормышка ашуын телим!

Реклама
Фото «Татэнергосбыт» АҖнән алынды

Иске Имәннең карт имәненә йөз генә яшь түгел инде...

АК ӘБИЛӘР АВЫЛЫ

Менә ул мәгърур имән, горур булып, ботакларын киң җәеп утыра. Яфракларында ара-тирә сары төс тә күренә. Көз җитүен сизәнә, күрәсең. Аңа ничә ел булуын биредә төгәл генә берәү дә белми. Әмма шунысы хак: Иске Имәннең карт имәненә йөз генә яшь түгел инде...

Автор:
Руфия Фазылова

БЕРҮЗЕНӘ – ӨЧ ИСЕМ

Бу имән нәкъ авыл уртасында – мәктәп бинасы ишегалдында күкрәп утыра. Белем учагы гомергә шушы нигездә булганын исәпкә алып, мөгаен, аны берәр шәкерт яки мөгаллим утырткандыр, дип уйлап куйдым.

Иске Имән авыл җирлеге башлыгы Раушания Исламова исә:

– Авылның элеккеге исеме Катысаз (Иман) булган, Октябрь революциясе елларында ул Иске Имән исемен алган. Бәлки, бабайларыбыз аны шул хөрмәткә утырткандыр. Авылыбыздагы бердәнбер имән агачы ул, – диде.

– Чынлап та, бик мөмкин бит, дип куйдым мин дә. Мәгърур имәннең юан-юан кәүсәләре, киң ябалдашы шомлы, серле тарихны саклый кебек тоелды. Моңсу да кебек ул: чөнки гомере буена мәктәп балаларын каршы алган, бүген исә инде андый бәхеттән мәхрүм калган. Иске Имәндә мәктәп ябылганга өч ел икән. Сәбәбе – әлегә дә баягы оптимизация. 28 укучы калгач, бала саны аз, дип, укучыларны Нөркәй урта мәктәбенә күчергәннәр. Әле ярый балалар бакчасы эшләп калган.

Иске Имәндә бүген 260 кеше яши, мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны – 12. 110 хуҗалык бар. Авыл төзек, күп йортлар яңа капка, койма белән әйләндереп алынган. Халык аралашучан, гади биредә. Каршыңа очраган һәркем елмаеп сәламли.

Без исә кешеләрнең бәрәңге бакчаларын күреп таң калдык: туфрак кап-кара! Мин аны хәтта учка алып, тотып та, иснәп тә карадым: «ярмаланып» тора. Җирнең йомшаклыгы... «Бер су сипмичә дә монда яшелчә үсәдер», – дип үзара сөйләштек.

– Чынлап та, уңдырышлы туфрак бездә, – ди Раушания Исламова. – Ирем Рөстәм КФХ булып теркәлде. Мөгезле эре терлек үрчетәбез, җирләребез дә бар. Быел иген уңышы да әйбәт, бәрәңге дә...

Иске Имән электән үк уңдырышлы җирләре белән дан казанган. Революциягә кадәр Казан байларының монда килеп, иген игүләре билгеле. Авылда яшәүче әби-бабайлар сөйләвенә караганда, үз вакытында биредә шәһәр төзелә икән дигән сүзләр дә йөргән.

Гел күзәтәм: авылда йортлар төзек икән, димәк, тырыш халык яши. Иске Имән кешеләре үз көчләре белән көн итә: мал-туар, кош-корт асрый. Җирлектә ике эре фермер теркәлгән, йөзәр баш умартасы булган умартачылар бар. Фермер булып теркәлмичә, дәүләттән ярдәм алмыйча, унар баш мөгезле эре терлек асраучылар байтак.

АЛЛАҺ БИРГӘН ГОМЕР

Иске Имәнне чын мәгънәсендә «Ак әбиләр авылы» дип атарга була. Биредә туксан дистәне тутырган берничә әби бар. Аларның һәркайсы турында аерым язма әзерләрлек. Әлбәттә, барысы белән дә таныша алмадык.

Иң беренче булып авылның иң өлкән кешесе – агымдагы елның июль аенда йөз яшен тутырган Шакирова Миясәрә әби янына бардык. Без килгәндә ул газета укып утыра иде.

– Әби, ә син анда нәрсә язылганны аңлыйсыңмы? – дигән соравыма:

– Ничек инде аңламыйм?! Аңламаган урыннарын өчәр кат укыйм, – дип куйды.

Бу сораудан үземә үк уңайсыз булып китте. Кем уйлаган йөз яшьлек кешенең шулай егәрен, акыл-зиһенен саклаган дип!

Бүген әби улы Фәннур, килене Ләйлә тәрбиясендә яши икән. Туксан сигез яшенә кадәр исә үз йортында, ялгызы яшәгән һәм мөстәкыйль тормыш алып барган. Бәрәңгесен утырткан, үстергән, аны казыган, ашарына әзерләгән һәм башка шуның кебек көндәлек мәшәкатьләрне башкарган.

– Бик киләсе килмәсә дә, әнине үзебезгә алып килдек, – диде Фәннур абый. – Аягында йөрсә дә, йөз яшь үзенекен итә: картайды әни. Ут-күздән дә куркыныч.

Әбинең язмышы шактый катлаулы: егерме җиде яшендә

Фото: Александр Ефремов

өч улы белән тол кала ул. Иң кече баласына бер яшь кенә тулган була. Гомер буе колхоз эшендә эшләп, йорт салып, үрнәк, тәртипле гомер юлы уза.

– Әни кырыс та, акыллы да булды, – дип сөйли Фәннур абый. – Безгә бик яхшы тәрбия бирде. Әтисез үссәк тә, беребез дә кеше теленә кермәдек, барыбызның да тормышлары матур, көйле.

– Улларым яхшы булды, – диде Миясәрә әби. – Мин аларга бик рәхмәтле. Киленем Ләйләдән дә уңдым. Нәрсә ашыйсым килсә, шуны пешерә. Бөтен җирдә чисталык, пөхтәлек. Миңа утырып, ятып кына торырга кушалар. Тик ятасы килми шул. Менә иң авыры шул…

– Егылып берәр җирен имгәтмәсен, дип куркабыз, – дип сүзгә кушыла Ләйлә апа. – Башлары әйләнеп китә. Әни гомере буена аралашучан булды. Урамга бер чыгып китсә, тиз генә кайтып кермәде. Менә шул чакларын сагына ул. «Хәзер син аралашкан кешеләрнең берсе дә юк, чыгып йөрмә», – дип тә карыйм. Үпкәли.

Әбидән озак яшәүнең серен сорадым.

– Аллаһ биргән гомер, – диде ул гади генә.

Нәселләрендә йөзгә җиткән кеше юк икән. Хәер, Иске Имән тарихында да ун дистәне тутырган кешеләр әле булмаган. Миясәрә әбинең аягы җиңел булсын!

ГАРМУНЧЫ ФАТЫЙМА

Иске Имәннең тагын бер үзенчәлекле, соклангыч кешесе – Фатыйма апа Гайнанова. Тиздән, октябрь аенда, туксан биш яшьне тутыра. Өздереп гармун уйнавы, тәмле теле, кунакчыллыгы сокландырды да, гаҗәпләндерде дә.

– Алты бала үстек, үземнең дә балаларым алтау иде, – диде Фатыйма апа. – Туганнар инде үлеп бетте, мин генә калдым. Бер улым белән бер кызымны да югалттым. Бик тату гомер иткән иремне дә җирләдем. Тик барыбер кайгыларга бирешмәдем, Аллаһы Тәгалә ярдәм итә, күрәсең. Якыннарымны бик сагынган вакытларда гармун алам да яртышар сәгать уйныйм. Бөтен гомер күз алдыннан уза…

Фатыйма апа кулына гармунын ала. Җырлый да, уйный да. Татар халык җырлары, бию көйләре – берсе дә калмады.

– Арыгансыңдыр инде, – дибез.

– Өч сәгать тә уйный алам, – диде әбиебез.

Фатыйма апа төрле җирләрдә эшли. Ун класс белем алганнан соң колхозга учетчик булып урнаша. Тракторларның күпме ашлык алып кайтканын, алып киткәнен санап тора. Нәкъ шул вакытта булачак ире белән дә таныша.

– Бикмөхәммәт йөзгә әллә ни матур түгел иде, – ди әби, яшьлек елларын искә алып. – Башта күзем төшмәде. Берсендә карыйм: амбарда җырлап йөри, тавышы матур. «Ай-яй, бу егет бигрәк моңлы җырлый. Күңеле әйбәт булырга охшаган», – дип уйлап куйдым. Күпмедер вакыттан соң тракторына утырып, эш буенча күрше авылга барырга туры килде. Шунда сөйләшеп киттек. Аннан аерылышмадык та. Килен булып шушы нигезгә килдем. Бик тату яшәдек. Районда узган төрле кичә, конкурсларга чыгыш ясарга йөрдек. Матур пар идек, бик матур. Иртә китеп барды шул, утыз елдан артты инде. Алдынгы комбайнер, сугыш ветераны иде.

Фатыйма апа умартачы да. Әле кортларны бетергәнгә ике генә ел икән.

– Корт оясын кырга эшкә баргач табып алып кайткан идем, гомер буе асрадык, – диде. – Нинди авыр вакытларда да өстәлдән сөт, каймак, бал өзелмәде.

Фатыйма апа гел шулай үткен булган. Шуңа күрә аңа Иске Имәндә балалар бакчасы ачуны да, колхоз ашханәсен оештыруны да йөкләгәннәр.

– Авылга җитәкчеләр, артистлар килсә дә, безгә кертәләр иде, – ди гармунчы әби. – Аларны сыйлап, мунчалар кертеп чыгара идем. Кешеләр белән аралашырга хәзер дә яратам.

Сыйлау дигәннән, Фатыйма апа бүген дә үзе генә чәйләргә яратмый икән.

1. Бүген Миясәрә әби улы Фәннур, килене Ләйлә тәрбиясендә яши икән.

2. – Өч сәгать тә гармунда уйный алам, – диде Фатыйма апа Гайнанова.

3. Гармунчы әбинең үзенчәлекле тәрәзә төбе.

1

2

3

1. – Зур файдалар турында әйтергә иртәрәктер, – ди Рушания Газизова.

2. Чын хуҗаларча Райнур килеп чыкты.

3. Газизовлар хуҗалыгында 100 башка якын үгез бар.

– Берәр тәмле ризык пешерсәм, капка төбенә чыгып китәм, – ди. – Урамнан кеше узганны көтеп торам. Мәҗбүриләп булса да өйгә алып керәм, чәй эчәргә. Каршы килмиләр үзе, рәхмәт яугыры...

Фатыйма апа безне дә кыстый-кыстый чәй белән сыйлады. Колмактан ипи пешергән. (Чүпрә урынына колмак үләне суын сала икән). Миче бар. Күз алдына китерегез: әбинең өстәле буйлап тезелешеп утырдык. Фатыйма апа исә гел йөреп тора: әле кайнатмасын алга төртә, әле маен. Ә үзенең йөзе кояш кебек балкый, сабый бала кебек сөенә. Шулвакыт күңел сандыгыннан бер вакыйганы тартып чыгардым: кечкенә чакта күршедә Ганҗамал әбием бар иде. Кайчан гына күрсә дә, өенә чәй эчәргә алып керә. Ипигә бал, май ягып бирә, чәчкәле чынаякка чәй ясый. Һәм каршыңа килеп утырып, шулай ризыкны алга төртә-төртә чын күңелдән сыйлый. Фатыйма апа да шулай... Бүген, мул заманда, кеше килә башласа, кунакларны шаккатырырга тырышып, яки гаеп итеп китмәсеннәр, дип, ят ризыклар әзерлибез. Ә табынның җылысы юк... Бу әбинең өстәлендә әллә нинди нигъмәтләр дә тормый, ә гаҗәеп затлы ризык ашагандай булдык. Менә шушыдыр инде күңел җылысын бирү. Ни кызганыч, бүген ул кыйммәтләр югалып бара.

Форсаттан файдаланып, Иске Имәннең гармунчы ак әбиен 95 яшьлеге белән котлыйсы килә. Фатыйма апа, тагын дистә еллар авылга моң, яктылык чыганагы булып торыгыз. Сезнең кебек кешеләр, безгә, яшьләргә, үрнәк тә, шатлык өләшүче дә.

«ҮГЕЗ ҮСТЕРҮ ФАЙДАЛЫ»

Авылның иң эре фермер гаиләсендә дә булдык. Газизовлар хуҗалыгында 100 башка якын үгез, дүрт савым сыеры, 150 баш каз, тавык-чеби бар. Йөз гектардан артык чәчү җирләре дә алар карамагында. 2016 елда 2 миллионлык грант отып, йөз башка исәпләнгән ферма салганнар.

– Грант акчасы гына җитмәде, үзебезнең 1 600 мең сум акчаны да салдык, – диде Рушания Газизова.

– Ничек соң, файдасын күрә башладыгызмы әле? – дим.

– Зур файдалар турында әйтергә иртәрәктер. Үзебезнең көндәлек чыгымнарны капларга җитә инде.

– Малларны кем карый?

– Нигездә ирем белән улым. Мин балалар бакчасында кече тәрбияче булып эшлим, вакыт та калмый...

Газизовлар гаиләсендә эш бүленгән: ир-атлар үгезләрне карага, Рушания ханым өстендә савым сыерлары, кош-кортлар икән.

Ир-атлар үгезләр караудан тыш, җир эшкәртү, иген, печән үстерү белән дә шөгыльләнә. Бу эш белән 2004 елдан бирле шөгыльләнәләр, әйтүләре буенча.

– Пай җирләре, нигездә, туганнарныкы, ике генә чит кеше, – диде хуҗабикә. – Җир өчен печән, иген бирәбез. Бездә бер пай җиренә 7,2 сутый туры килә. Район башлыгы тарафыннан шулай куелды: печән, иген алмаган кешеләргә өч мең сум акча бирәбез.

Газизовларның өч балалары бар. Олы кызлары Казан дәүләт медицина университетында белем ала, уллары Сарман авыл хуҗалыгы көллияте студенты, ә бәләкәй кызлары бакчага йөри. Зур, тәзек ихаталары, чәчәккә кү-

мелгән бакчалары, биредә нинди тырыш кешеләр яшәгәнлеген әйтеп тора.

Рушания ханым белән сөйләшеп торган арада уллары Райнур килеп чыкты. Чын хуҗаларча үгезләр яшәгән ферманың ишекләрен ачты ул. Шуннан бәйнә-бәйнә сөйләргә кереште.

– Кечкенә үгезләрне бәйләмичә тотабыз, үсә төшкәч, аерып куябыз. Бер үгезне якынча ел ярым асрыйбыз. Суйгач, 3 центнер ите чыга...

– Райнур, авылда калырга җыенасыңмы? – дим.

– Авылда калдырасым килми шул, – дип, ана кеше улы өчен җавап бирде.

– Ә моның кадәр хуҗалыкны кемгә калдырасыз? – дим.

– Үзебез бар бит, әле без карт түгел. Авылда яшь гаиләләр өчен мөмкинлекләр юк. Мәктәп ябылды, бакча да соңгы елларын эшлидер, яңа туган сабыйлар юк дияргә була. Күп балалы гаилә буларак Сарманнан җир биргәннәр иде. Өйләнсә, шунда йорт салсак, дип тә уйлыйбыз. Теләге булса, монда килеп эшләп йөрер. Район үзәге безгә ерак түгел, әле кечкенә кызыбызны биюгә дә Сарманга йөртәбез.

Сүзебез янә ферма, маллар тирәсенә кайтты. Иткә сорау бар икән, айга кимендә ике-өч үгез суялар. Күпләп сатканда килосы 250 сумнан, берәр бот булса, 270–280 сумнан бирәләр. Үзләренең даими сатып алучылары бар, итне килеп алалар, үгезләрне дә китереп бирәләр.

– Сыерларга караганда үгез асрау файдалырак, – ди хуҗабикә. – Бер сыер ашаган ризыкка ике үгез асрап була. Аннан мәшәкате дә азрак, савасы юк, сөтен урнаштырасы, дигәндәй. Иртән алларына печән салып калдырсаң, көн буе үз эшләрең белән йөреп кайтырга була. Ә сыерларны алай калдырып чыгып китә алмыйсың. Сыерның сөте бик арзан: 10 гына сум бит. Кимендә 20 сум булса уйлап карарга булыр иде.

Рушания ханым белгечлеге буенча хисапчы булмаса да, гел саннар телендә сөйләшә. Янә бер кызык та, кызганыч та мисал китерде ул:

– Бүген солярканың бәясе 38–40 сум, ашлыкныкы – 6–7 сум. 2004 елда, җирләрне арендага алган вакытта, ягулыкның бәясе 3 сум, ашлыкныкы да 3 сум иде. Ягъни бер литр ягулыкка бер кило ашлык туры килә. Гап-гади арифметика, исәпләп баш катырасы түгел. Менә шуннан бүген җир кешесенең бөтен бәясе күренә. Әле моңа салымнарны да өстәсәң...

...Иске Имән авылы турындагы язмага шушы урында нокта куябыз. Сарман районы башлыгы урынбасары Гүзәл Гәрәева: «Иске Имән җирлегендә гаҗәеп кешеләр яши. Җәен авыл көнен үткәрделәр. Зурлап чишмә ачтылар. Тырыш, эчке дөньялары бай халык анда», – дигән иде. Гүзәл ханымның сүзләренә җавап итеп: «Әйе, күрдек. Нәкъ шулай икән», – диясе генә килә.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Иске Имән – Сарман районындагы иң борынгы авылларның берсе. Ул 1917 елга кадәр ике исем белән аталган: Катысаз һәм Иман. Соңгысы XVIII-XIX гасыр рәсми кәгазьләрендә җәя эчендә күрсәтелгән. 1917 елдан соң Иске Имән атамасын ала.

Авылның иң беренче исеме – Катысыз, янәшәдә аккан шул исемдәге елга белән бәйле. Башкортостан үзәк дәүләт архивында авылга кагылышлы бер документ саклана. Шуннан күренгәнчә, 1798 елның 13 июлендә Катысыз (Иман) авылында яшәүче Тимеркәй Йосыпов губерна җитәкчесенә гариза белән мөрәҗәгать итә. Ул нәсел җепләренең башкорт сословиясенә карaганлыгын раслый. Нәсел җебе – Бәйрәмхуҗадан башлана. Тимеркәй ерак бабасына 1596–1597 елда бирелгән грамоталарны әле дә саклавын яза. Исем шәҗәрәнең җиде буыннан торган ботагында Бәйрәмхуҗаның оныгы Иман да бар. Авылга Иман исеме кушылу да шуннан башланган дигән фараз йөри.

Аңлашылганча, Катысаз (Иман) да, татарлардан тыш, башкортлар да яшәгән. Бишенче ревизия (1795 ел) материалларыннан күренгәнчә, авылда 31 хуҗалыкта 104 ир-ат һәм 99 хатын-кыз исәпләнә. Ир-атларның 66 сын ясаклы татарлар, 36 сын башкортлар, 2 сен типтәрләр тәшкил иткән. (Россия борынгы актлар дәүләт архивы, 1355 нче фонд, 1нче тасв., 128 нче б.)

XIX гасыр азагыннан алып XX гасыр башына чаклы авылда яшәүчеләр саны акрынлап кими. 1897 елда анда даими рәвештә 480 ир-ат һәм 434 хатын-кыз яшәсә, 1906 елда исә 360 һәм 340 кала.

1906 елда, 1870 ел белән чагыштырганда, халык саны кимрәк булса да, йортлар саны 15 кә арткан. Ул вакытта авылда өч бакалея лавкасы, тимерчелек, икмәк запасы саклана торган кибет эшләгән.

1913 нче елгы җанисәп вакытында авылда 208 хуҗалык, 572 ир-ат һәм 586 хатын-кыз исәпкә алына. Авылда бер мәчет, бер мәктәп бар дип тә теркәлеп куелган.

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

Реклама 16+

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Бәрәңгеле сентябрь.
Мәхәббәт белән – Татарстаннан.

Фото: Александр Ефремов

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Мәхәббәт ул – бәрәңге түгел-түгелен.
Тик мәхәббәтсез бәрәңге дә юк, шунысын онытмагыз!

Фото «Татарстан» журналы архивыннан

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ